1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
2020 МАРТ № 3

# СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398



*Эльмира* КӘЛИМУЛЛИНА
*бәхетле ирнең бәхетле хатыны*

БӘЙРӘМЧӘ *табын*
*тутырылган карп балыгы*

*хушлашмыйк,* ЯШЬЛЕК
*яшь калу серләре*

*Гөлнара* ГЫЙЛЬМАНОВА:
*«Хатын-кыз булган җирдә тормыш гөрли!»*

75 ПОБЕДА! 1945–2020

# Хәтер – мәңгелек...

**Бөек Җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егетләре, татар кызлары да байтак. Минем бабам, синеке, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш ишек шакымаган капка, гаилә калды микән? Җиңү таңы безгә шуңа да кадерле... Инде бу хакта бүгенге яшьләребезгә дә аңлатасы, төшендерәсе, күңелләрендә горурлык хисләре уятасы килә. Бу проект – шул хакта. Мондый ядкарьләр, бәлки, сезнең гаиләләрдә дә сакланадыр. Юк икән, аларны шушы сайттан табып алырга мөмкин: https://pamyat-naroda.ru. Бабаларыгызга орден-медальләр ни өчен бирелде икән? Балалар, оныклар белән бергә утырып эзләп карагыз әле. Әлеге тарихи документларны үз күзләре белән күргәч, Җиңү сүзенә алар инде берничек тә битараф калалмас... Табышларыгызны безнең белән дә уртаклашыгыз. Хатларыгызны көтәбез.**



Әниемнең апасы Шейх-Али Динора Әскәр кызы – ТАССРның атказанган табибы, сәламәтлек саклау отличнигы. Ә аңа кадәр ул Бөек Ватан сугышы узган кеше. Апам 1910 елда Казанда туа. Казан дәүләт медицина институтын тәмамлаганнан соң Саба бистәсенең район хастаханәсендә терапевт булып эшли. Соңыннан Мәскәү өлкәсендәге Истра шәһәренә күченеп китә. Сугыш башланганның икенче көнендә үк Кызыл Армия сафларына алына һәм Җиңү яулаганчы 48 нче армиянең 1869 нчы кыр госпиталендә хирургия бүлегендә хезмәт итә. Япония белән сугыш вакытында алар госпитален Ерак Көнчыгышка күчерәләр. Медицина хезмәте капитаны дәрәҗәсенә җитеп, 1945 елда демобилизацияләнгәннән соң, Мәскәү өлкәсе Пушкин районында артиллерия полигонының фәнни-тикшеренү амбулаториясе мөдире була. Казанга күченеп кайткач, травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү институтында лаеклы ялга чыкканчы терапевт булып эшли.

Динора апабыз Кызыл Йолдыз, II дәрәҗәдәге Ватан сугышы ордены, «Хәрби казанышлары өчен», «1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Ул – гаиләбезнең горурлыгы!

Әскәр ХЛОПУШИН. Казан.

Редакциядән: Динора ханым Шейх-Али язмышы турында язманы киләсе саннарыбызның берсендә укый аласыз.

НАГРАДНОЙ ЛИСТ.
1. Фамилия, имя и отчество Шейх-Али Динора Аскаровна
2. Звание Капитан м/служб. 3. Должность и часть ординатор...

Наградной лист

1. Фамилия, имя и отчество Шейх-Али Динора Аскоровна
2. Звание В/врач 3 ранга 3. Должность, часть Нач. хирургического отделения АПГ – 1869

Представляется к ордену „Красной Звезды"

4. Год рождения 1910 5. Национальность татарка 6. Партийность б/п
7. Участие в гражданской войне и в последующих боевых действиях по защите СССР Не участвовала
8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне Не имеет
9. С какого времени в Красной Армии с 1941 10. Каким РВК призван Казанским горвоенкоматом
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) Наград не имеет
12. Постоянный домашний адрес (представляемого к награде или его семьи).

Краткое изложение личного боевого подвига или заслуг.

Т. Шейх-Али – весьма опытный врач с многолетним практическим стажем. Начальник хирургического отделения госпиталя с момента формирования его. Благодаря неустанной заботы и огромному вниманию к лечению раненых т. Шейх-Али обеспечила излечение и возвращение в строй многих сотен командиров и бойцов. Только за последний месяц госпиталем выписано в часть более 1000 выздоровевших раненых. За время последней боевой операции, когда через госпиталь прошло много тысяч раненых т. Шейх-Али сутками проводила в перевязочной и отделении, лично проделала тысячи сложнейших перевязок, обеспечивала полноценную хирургическую обработку и отличный уход за ранеными, чем способствует излечению и возвращению в строй тысяч бойцов и командиров.

Т. Шейх-Али патриот своей родины, предана делу партии Ленина-Сталина. Достойна правительственной награды орденом „Красная Звезда"

Нач. Упр. ГЭП-156
26 марта 1943 В/врач 1 ранга [подпись] (Хитеев)

# Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019




Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

**Баш мөхәррир**
Л. Н. Маликова

**Редколлегия:**
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

**Редакциянең гомуми телефоны** 222-09-77

**Җитәкче урынбасары** 222-09-78
Рәмзия Кашапова
**Баш мөхәррир урынбасары** 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
**Җаваплы сәркатип**
Лариса Маликова
**Әдәби мөхәррир**
Эльмира Закирова
**Сайт мөхәррирләре:**
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

**Тышлыкта:**
Гөлнара Гыйльманова
Фото: Анна Арахамия

**Верстка:**
Резеда Галиуллина
**Бүлек мөхәррирләре:**
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
**Корректор**
Фирдәвес Исмәгыйлева
**Фотокорреспондент**
Анна Арахамия
**Гамәли хезмәткәрләр:**
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 28.02.2020 ел.
Заказ А-448
Тираж 5311

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»




ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)


Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Фото: Анна Арахамия

# Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучым!

Тормыш язган бу хикәятне син безнең журнал битләрендә инде әллә кайчан укырга тиеш идең. «Сөембикә»не алдыручы хатын-кызлар моны, һичшиксез, ишетергә тиеш», – дип, Лира Махуповна сөйләгән иде аны. Озак еллар журналның бизәлеш мөхәррире булып эшләгән Алсу Тимергалинаның әнисе ул. Шулай ара-тирә редакциягә кергәләп, күп нәрсәгә өйрәтеп китүен әле дә сагынып искә алабыз. Тик һәрнәрсәнең үз вакыты шул. Журнал укучыларыбызга сөйләргә кызыксак та, тормыш мәшәкатьләре аркасында «онытылып» торган хикәяткә дә чират җитте менә.

«Мин моны бер ахирәтем авызыннан ишеттем, – дип сөйләгән иде ул. – Күз алдына китерегез. Ял көне. Гаилә кунакка чакырулы. Ир диванга кырын ятып телевизор карый. Хатын исә атна буена җыелган эшләренең бер өлешен булса да кичкә кадәр эшләп бетерергә ашыга. Башында – бигуди. Газ плитәсе өстендә керләре кайный (автомат кер юу машиналары турында хыялланмаган да чор әле бу). Юасы савыт-сабалары өелеп, үз чиратын көтә... Шулай ашыгып, тирләп-пешеп эшләп йөргәндә ире: «Матурым, алма бирмәссең микән?» – дип сорамасынмы! Хатынның күңелендә купкан давылны чамалау авыр түгел... Ваннада чайкый торган керен ташлап, эченнән генә: «Хәзер бирәм мин сиңа алма!» – дип ярсып, хатын кухняга керә. Алманы юа... Һәм... һәм туктап кала... Бер мизгел эчендә үзенең ире алдына нинди кыяфәттә чыгып басасын күз алдына китерә: халаттан, башында – бигуди, бите – кып-кызыл, маңгаенда – тир бөртекләре, шуңа өстәп – ачулы кыяфәт (ә ул беркемне дә бизәми)... Хатын, үзе күренмичә генә, алманы иренә ишектән генә суза. Ире рәхмәт әйтеп ала да телевизордан кино каравын дәвам итә...»

«Минем нәрсә әйтергә теләгәнемне аңладыгызмы, кызлар?» – дип тәмамлаган иде сүзен Лира Махуповна. Аңладык, әлбәттә... Еллар үзгәч: «Мин – бәхетле!» – дип әйтә алу өчен тормышта хатын-кызга кайчак сабыр булу да кирәк. Ә сүзебезне үз вакытында җайлап кына әйтергә зирәклегебез, һичшиксез, җитәчәк. Без бит хатын-кыз.

Хөрмәтле гүзәл затлар, бәйрәм белән барыгызны да! Бәхетле булыйк!

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

## Безнең тышлыкта



*«Химиядә эшләүче хатын-кызлар кулы белән каучук ясамый, ләкин җиһазлар берөзлексез эшләсен өчен күп көч куялар. Бу – зур җаваплылык. Гигант заводның хатын-кызлары моңа курыкмыйча алына. Чын күңел белән. Хатын-кызларча!»*


12 Алар – химиклар!
Чулпан Галиәхмәтова


## Заман һәм без




6 Хушлашмыйк, яшьлек
Чулпан Галиәхмәтова





18 Карадуган. Гимназия. Гамәл дәфтәреннән...
Эльмира Закирова

24 Принцесса синдромы
Раилә Хәялиева





22 Өйдә бәлеш исе, ә киштәдә... «Грэмми»
Чулпан Галиәхмәтова

## Татар дөньясы



30 Сарман җыры
Гөлнур Сафиуллина

34 Җилкәннәр җилдә сынала
Раилә Хәялиева



38 «Кабатланмас эзләр калдырыйк»
Лилия Гәрәева

## Мәдәни тормыш



44 Кайту
Ризидә Гасыймова

## Яшәеш



50 Сөт әнисе
Чулпан Галиәхмәтова

54 Вахит Имамов: «Йөрәккә мәкер кермәсен»

## Хуҗабикә



60 Илнур Закировтан
Тутырылган карп балыгы



62 «Дөрес» торт



# ХУШЛАШМЫЙК, ЯШЬЛЕК



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

**Җиһанга яз аяк баса. Тиздән табигать, җанланып, яшәрә башлар. Хәер, табигать кенә түгел, елның бу фасылы җиткәч, кешеләр дә, бигрәк тә без, хатын-кызлар, яшәрә, чәчәк ата башлыйбыз. Яшь кызлар чәчәк атар инде ул, оныкларың күзеңә карап торганда исә картлык турында гына уйланасың дип әйтергә ашыкмагыз әле. Без, ничә яшьтә булуга карамастан, язын кабат гүзәлләнә башлыйбыз. Чәчләргә яңа прическа ясатабыз, кыш буе кигән соры киемнәрне алып куеп, якты төсләрдәге күлмәкләрне сайлыйбыз, ә иң мөһиме: күзләрдә очкын кабына, күңелдә күбәләкләр оча. Бу чорда хәтта ак яулыклы акъәбиләр дә, кояшка чыкканда яулыкларын төзәтеп алыр өчен, көзге каршына килеп баса. Яз китмәсен иде ул, әнә шулай яшәү дәрте биреп торсын иде. Тик табигать кануннарын үзгәртеп булмый. (Аллага шөкер!) Ә күңелебездә һәрвакыт яз булдырырга кем комачаулый соң? Үзебез түгелме?!**

### *Картлыкның яше нинди?*

Хатын-кыз кайчан картая башлый? Кемдер, балалар үскәч дияр (ә бит алар үсеп җитүгә үзебез кабат яшьлеккә дә кайтырга мөмкин), башка бер ханым битттәге җыерчыкларына карап уфтаныр (ә анысы эмоцияләргә бай булганлыктан!), әллә каян күренеп торган ак чәчләр дә эчне пошырмый калмый (әкрен генә куна башлаган бәсләр – безнең тормыш, безнең борчулар, югалтулар, гомумән, бүгенге безне «ясаучылар»). Әйе, безгә генә кадерле, бары үзебез генә белгән тормыш серләрен яшерә алар. Тик җәмгыять өчен хатын-кызның төп гүзәллеге – яшьлеге. Һәм ул стереотипны берничек тә үзгәртеп булмый. Яшьлек безнең белән кайчан саубуллаша башлый соң? Барысы да урта яшьләр кризисыннан башлана, дип әйтә дөньякүләм белгечләр. Дөрес, безнең илдә кеше тормышындагы әлеге чорны санга сукмыйлар иде. Имеш, мондый тенденция көнбатышта гына. Хәзер ул хакта да сөйләшәләр инде. Кеше кайда эшләвенә, ничек яшәвенә карамастан, бу чорны уза. Англия философия докторы Дэвид Бланчфлауэр бик күп илләрдә кеше яше белән тормыш яме арасындагы бәйләнешне эзләгән. Нәтиҗәдә, бәхет графигын булдырган. Баксаң, бәхет «U» хәрефе формасында икән. Аның иң аскы (үзеңне бәхетсез итеп хис итү чоры) ноктасы 46–50 яшькә туры килә. Урта яшьләр кризисы да әнә шул вакытка туры килә. Белгечләр әйтүенчә, нәкъ шушы яшьтә кеше яшьлектә корган планнарының барысы да килеп чыкмавын таный башлый. Гомер уртасы, карьерада зур үрләр яулау вакыты узып бара, инде мөмкинлекләренең офыклары күренә... Тормышым мәгънәсе – гаиләм дип яшәүче аналарга да, карьерага омтылучы ханымнарга да тия ул кризис җиле. Сексопатолог Любовь Мумладзе, урта яшьләр кризисы ир-атларда гына була, ә хатын-кызларда ул юк, алар бары тик «буш оя синдромы» белән очраша, ди. Хатын-кыз 50 яшьләргә җиткәндә, балалары туган оядан очып чыгып китә башлый. Алар инде хәзер әни ярдәменә мохтаҗ түгел. Ашарларына пешерергә, артларыннан җыярга, контрольдә тотарга кирәкми. Гомере буе бала мәшәкатьләреннән арынмаган, үзен бары сабыйларына багышлаган ана бу чор җиткәч аптырап кала. Эш белән гаиләне бергә тартучыларга да кризис килә. Тәнкыйть күзлеге аша карап, алар әле үзләрен ике яклап бәяли! Бер үк вакытта уңышлы белгеч яки җитәкче дә, яхшы ана һәм хатын да булып булмый дип уйлыйлар. «Урта яшьләр кризисын иң авыр узучылар – баласыз хатын-кызлар», – ди психологлар. Балалар хатын-кыз гомеренең бушка узмавын күрсәтә. Яшь чакта куйган максатларга ирешә алмавыңны да балаларга сылтап калдырырга мөмкин: хыялларны чынга ашырып бетермәдем, аның каравы, тәрбияле балалар үстердем дип уйлыйсың. Ә дәвамчыларың булмаса, көннәрдән бер көнне, ярты гомеремне нишләп уздырдым, хәзер кем өчен яшәргә инде дигән сорау тумый калмастыр, мөгаен. Карьерада күтәрелүчеләр үзләрен яшьтәшләре белән чагыштыра башлый. Кемдер – ике, кемдер өч бала табып, күңелле мәшәкатьләргә чумып, куанып яши. Табигать эшлекле ханымнарга да хатын-кыз миссиясе турында искәртми калмый – аларда әни инстинкты уяна. Шуңа да 40 яшьтән соң беренче балаларын табучы ханымнар бик күп. Алар, шул рәвешле, шәхес кризисларын җиңә. Ә инде шәхси тормышларын сызып ташлап, үзләрен тулаем карьерага багышлаган хатын-кызларның урта яшьләр кризисы нәкъ ирләрнеке кебек уза. Дөрес, гүзәл затлар дөньяларын онытып сузылып ятып үткәрми бу чорны. Салкын акыл белән рациональ фикер йөртеп яшәгән хатын-кыз белә: югары постларга, җаваплы вазыйфаларга нәкъ шушы яшьләрдә билгеләнә.



Эндокринолог
Марина МАКСИМОВА:
*«40–45 яшьтән соң хатын-кыз организмында гормональ үзгәрешләр башлана».*

Рухи кризистан битәр, гомернең бу чорында организмның да «гарантия вакыты» чыгып бара, димәк, сәламәтлекне җитди итеп кайгыртыр вакыт җитә. Хатын-кыз организмы климакска әзерләнә башлый. Эндокринолог Марина Максимова аңлатуынча, 40–45 яшьләрдән өлкәнрәк хатын-кызларның күкәйлек функцияләре әкренләп сүнә башлавы, җенси гормоннар дефициты белән бәйле гормоннар эшчәнлеге үзгәрә. Кәеф үзгәрүчәнгә әйләнә, апатия, хәтер начарлана башлый, игътибарны җыеп бетерү авырлаша, йокысызлык интектерә. Болары – беренче билгеләр. Варикоз, битттәге «кызыл

**Ришат ТӨХВӘТУЛЛИН, Татарстанның атказанган артисты:**



Хатын-кыз гомеренең һәр чорында да гүзәл. 14–15 яшьтә алар үсмерлектән чыгып, аккошка әйләнә башлый. Ә хатын-кызның бар матурлыгы бәби тапканнан соң ачыладыр, мөгаен. Сабыен кочагына алганда бөтен күзәнәге ярату, наз белән тулган аналардан да матуррак кеше юктыр бу дөньяда. Менә ул – мәңгелек матурлык! Гомер уртасына җиткәннәргә чибәрлекләреннән кала, туплаган тормыш тәҗрибәсе, акылы, зирәклеге тагын да матур чалымнар өсти. Хатын-кыз һәм нәфислек аерылгысыз төшенчәләр. Йөзеннән бәхетле елмаю китмәгән, сөйгән һәм сөелгәннәргә картлык куркыныч түгел. Алар һәрвакыт яшь булып кала!

Фото: www.pixabay.com





челтәрләр» (купероз), йөз овалы үзгәрү, тире тупаслану, пигмент таплар чыгу... Менопауза интим тормышка да үзгәреш кертми калмый. Либидо кими. Аның беренче билгеләре сизелә башлауга, күпләр интим тормышка нокта куярга вакыт җитте дип уйлый башлый. (Бу – тамырдан дөрес фикер түгел, ди белгечләр.) Менә шушылар барысы да бер вакыттарак калкып чыга да кеше үзеннән канәгать булмый башлый, эчке конфликт барлыкка килә. Тормыш мәгънәсе югала, күңелдән бушлык хисе китми. Күпләр күңел төшенкелегенә бирелә. Бу картаю инде, алда – гомер көзе диючеләргә белгечләр моның киресен раслый. «65 яшенә җиткәнче хатын-кызны карт дип әйтү җинаятькә тиң», – ди Любовь Мумладзе. Аның сүзләренчә, бүген «хатын-кыз бәхетен» озынайту өчен бик күп чаралар бар. Табиб белән киңәшләшеп, кирәкле гормоннар эчәргә кирәк. Һәм үзеңне яратырга. Ничекме?

### *Яшь булып калу сере – үзебездә*

Кемдер бик тиз картая, кемдер һаман яшьлеген югалтмый. Генетика, гормоннардан кала, кешенең тормышка мөнәсәбәте, холкы да тәэсир итә икән моңа. Әгәр хатын-кыз үз эченә бикләнгән, һәрвакыт зарлана, шатлык хисен күптән оныткан, депрессиягә бирелүчән икән, ул инде 30 яшендә үк өлкән күренәчәк. Моннан кала, күңел төшенкелегендә яшәгәннәрнең җенси гормоннары да аз эшләнеп чыга, чөнки кешедә төп инстинкт – яшәргә тырышу. Соңыннан гына үрчү теләге барлыкка килә. «Яшь булып калуда күңел халәте зур роль уйный, – ди Россия табигать фәннәре академиясе профессоры, психология фәннәре кандидаты, психолог Фәния Әхмәтҗанова. – Бала табу яше тәмамлану (ә хатын-кыз сәламәт, генетикасы яхшы, инфекция, ялкынсынулары юк икән, ул 50–55 яшьтә генә тәмамлана) бу әле картаю дигән сүз түгел, картлык – дөньяга, яшәүгә битарафлык. Хәтерлисезме, «Белое солнце пустыни» дигән фильмны? Анда сугышалар, йөгерешәләр. Ә бер төркем аксакаллар битараф кыяфәт белән әле бер якка, әле икенче якка карап утыра бирәләр. Аларның бернәрсәгә катнашлары да, эмоцияләре дә юк. Бу – картлыкны иң яхшы сурәтләү дип уйлыйм. Тормыштан ямь табып, күңел күтәренкелеге белән яшәгәннәрнең, һәрчак кызыксынучыларның картаерга вакытлары да, теләкләре дә юк. Алар ничә яшьтә булуларына карамастан, яшь булып калалар. Бары тик күңел көрлеге югалмасын».



Россия табигать фәннәре академиясе профессоры, психология фәннәре кандидаты, психолог Фәния ӘХМӘТҖАНОВА:
*«Бала табу яше тәмамлану картаю дигән сүз түгел әле ул, картлык – дөньяга, яшәүгә битарафлык».*

Хәрәкәттә – бәрәкәт дип тикмәгә әйтмәгәннәр өлкәннәр. Психиолог әйтүенчә, картлыкны кичектерүнең рецепты гап-гади, актив тормыш, аралашу, яңа һөнәр үзләштерү, гомумән, яңалыкка омтылу. Һич кенә дә спортны онытырга ярамый. «Бер танышларымның ике улы бар. Алар үстеләр дә, туган ояларыннан чыгып киттеләр. Ир белән хатын үзләре генә калды. Балаларсыз тормышны күз алдына китерә алмыйча, кайгыга сабышты, хәтта мөнәсәбәтләре начарланды. Зирәк хатын тормышларын үзгәртергә ниятләп, актив рәвештә спорт белән шөгыльләнә башлады. Аның артыннан ире дә иярде. Казанда үткән марафон аларсыз үтми, хәтта Төркиягә барып, Босфор култыгын йөзеп чыгу ярышында катнаштылар. Алар икесе дә яшәреп китте. Гәүдәләре җыйнакланды. Ә иң мөһиме: күзләрендә – яшәү чаткысы», – дип сөйли Любовь Мумладзе спортның мөһимлеге хакында. Карт күренәсем килми, дип, косметологка барып, бит тиресен тарттырып, ә гәүдәң, йөрешең картларча икән, моннан да кызганыч күренеш юк.

Шатлана белү дә – яшьлекне озынайтучы фактор. Ир-атлар да үзен яшь кызлар кебек тоткан (ялгыша күрмәгез, яшь кызлар кебек кыска итәк, биек үкчәле туфли киеп йөрү түгел. Һәр яшьтә кием дә билгеле бер кагыйдәләргә туры килергә тиеш. Яшь-җилкенчәкләр кебек шат күңеллелек турында сүз бара) ханымнарга күз төшерә. Күтәренке кәеф булганда елмаясы гына килеп тора. Елмайган ханымнарга бөтен дөнья елмая! Яхшы кәефне, билгеле, берәүнең дә алдына китереп куймыйлар. Ул бары тик үзебездән тора.

**Рүзәл МӨХӘММӘТШИН, шагыйрь:**



Үзем белгән хатын-кызларны күз алдымнан уздырдым да, шуңа инандым әле: минем өчен алар һәрвакыт матур икән. Мин ямьсез хатын-кызны белмим! Алай да, аеруча матур вакыты дип, Һади Такташ белән килешеп, аларның ана булган чагын атар идем. Картаю-картаймау да, минемчә, яшькә бәйле түгел. Ләкин кайгы-хәсрәт, борчу-михнәт бик тиз арада хатын-кызның бөтен яшьлеген, сусыллыгын, матурлыгын суырып ала. Шуңа күрә мин Җир йөзендәге һәммә гүзәл затка сәламәтлек һәм бәхет телим! Чөнки без дә (ирләр) шул вакытта гына сәламәтлеккә, бәхеткә һәм тынычлыкка тиенергә мөмкин. Шигырьдәгечә: *Без батырып, тегәрмен йөрәкне – / Җәрәхәте ятсын кырык буй! – / Мине берни куркытмый. / Син барда – / Икеләтә берни куркытмый!*

«Күңел төшенкелегенә биреләсең икән, сузылып ятарга ярамый, – ди психолог. – Торырга һәм нидер эшләргә кирәк. Физик энергия биреп, без тормыш энергиясе алабыз». Күңеленә хуш килгән шөгыль тапкан хатын-кызларның ире белән мөнәсәбәтләре дә аеруча җылы була. Рухи якынлыктан ләззәт табу өстенлек итә. Дөрес, бу яшьтә интим тормышта буран уйнатучылар да бар әле. Сексопатолог әйтүенчә, анысы инде кешенең конституциясе белән бәйле.


Бу чорда хатын-кызга эндокринолог-гинекологка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Табиб гормонотерапия билгеләргә мөмкин. Тик, үз белдекләнеп, танышларыгызның сүзенә карап, бигрәк тә телевизордан барган рекламаларга алданып кына гормоннар эчү ярамый, чөнки алар – организм эшчәнлегенә җитди катнашу. «Һәр хатын-кыз өчен дәва индивидуаль, – ди Марина Максимова. – Җентекләп тикшергәннән соң, бәлки, витаминнар, фитоэстрогеннар һәм дөрес туклану җиткәне дә ачыкланыр». Табиб әйтүенчә, менопауза вакытында соя продуктлары, җитен орлыгы, E һәм B витаминнары организм өчен файдалы, алар хатын-кызлар гормоны – эстрогенга (аны «яшьлек гормоны» дип тә йөртәләр) бай.

Сузылып ятып авырый башлагач соң була инде ул. Үземне яратуым – сезнең өчен дип яшәргә кирәк. Үзеңне ярату әле ул эгоист булу, башкаларның сиңа хезмәт итеп яшәве дигән сүз түгел. Ул – иң элек сәламәтлегеңне кайгырту. Самолетта да бит һәлакәткә очрый калганда кислород маскасын башта үзеңә кияргә өйрәтәләр, соңыннан гына балага. Күктә генә түгел, көндәлек тормыш өчен дә кирәкле кагыйдә ул! Сәламәт булганда гына без якыннарыбыз тормышын бизи алабыз. Ә хатын-кызның төп бурычы – гаилә оясын саклау.

Хәтерләсәгез, моннан дистә еллар элек 50–55 яшьләргә җиткән ир-атлар, гомер иткән хатыннарыннан аерылып, үзләреннән күпкә яшь кызларга өйләнде. Шундый бер шаукым булып алды. Хәзер мондый тенденция бетте, чөнки хатын-кызлар үзләрен карый, тәрбияли башлады. Гормоннар эшчәнлегенең үзгәреш чорын да элекке кебек авыр узмыйлар, чөнки алар мәгълүматлы, табибка йөриләр, кирәкле терапия узалар. Шуңа да хатын-кызның активлыгы бетми. «Илледән соң тормыш башлана гына, һәм ул бөтенләй башка төсләр белән уйный икән, – ди бер танышым. – Балалар кулдан төште. Ниһаять, үзебез өчен яши башладык». Алар яшьлек хыялларын тормышка ашыра – йорт төзиләр. Җитмәсә, дәүләт тә халыкның бары тик яшәртү ягын кайгырта. Пенсия яшен арттыру да – шуның бер мисалы. Эштән китсәч, бик тиз генә тормыш арбасыннан төшеп калучылар да юк түгел бит. Дөрес, хезмәт урынын бик яратканнар турында сүз бара.

Язмам башында философия докторы Дэвид Бланчфлауэрның бәхет графигы булдырганын язган идем. «U» хәрефе формасындагы бәхет аскы ноктага җиткәч нишли? Дөрес, кабат өскә менеп китә. Ягъни бәхет яңадан килә дигән сүз бу.

УРТА ЯШЬЛӘР КРИЗИСЫ БАРЛЫГЫНА ЧЫНЛАП ТА ЫШАНАСЫЗМЫ? (сораштыру)



| | |
|---|---|
| **Әйе, минем уйлавымча, бар:** | |
| Гомум сораштырылганнар | 54% |
| Ир-атлар | 44% |
| Хатын-кызлар | 63% |
| **Әйе, ышанам. Шәхсән үзем уздым:** | |
| Гомум сораштырылганнар | 13% |
| Ир-атлар | 16% |
| Хатын-кызлар | 12% |
| **Юк, бу уйдырма:** | |
| Гомум сораштырылганнар | 17% |
| Ир-атлар | 22% |
| Хатын-кызлар | 12% |

(Мәгълүмат SuperJob.ru тикшеренүләр үзәге порталыннан алынды.)



**Айрат ФӘРРАХОВ, Россия Дәүләт Думасы депутаты:**

Без, ир-атлар, хатын-кызлар өчен яшибез, дуамал адымнарга барабыз, башкалардан аерылып торырга тырышабыз. Без бу дөньяга килгәндә дә, авырганда да, шатлык-кайгыда да, бәлки, бу дөньядан киткән чакта да алар гел янәшәбездә. Хатын-кыз һәрвакыт гүзәл! Бу сүземне һәр ир-ат раслар дип уйлыйм. Алар ярсыганда да, хәтта авырганда да чибәрлекләрен югалтмый. Авырлы хатын-кызлар искиткеч! Җиңүгә ирешкән хатын-кызга карап сокланасың, авыр хәлдә калсалар, таяныч, терәк буласы килә. Хатын-кыз һәм картлык – капма-каршы төшенчәләр. Теләсә нинди яшьтә дә ул чибәр, яшь, сөйкемле, үзенә тартып тора. Иң мөһиме: алар яшәү дәртен югалтмасын. Болары өчен инде без җаваплы, әлбәттә. Барлык хатын-кызларга да мәхәббәт һәм бәхет телим. Алар үзләре булып калсын, табигыйлекләрен, күңел күтәренкелеген югалтмасыннар!



**Рөстәм ГАЙЗУЛЛИН, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты:**

Хатын-кыз Аллаһы Тәгалә тарафыннан яратылган могҗиза бит ул. Юк, бу купшы сүзләр сөйләү түгел, чынлыкта да шулай. Аларның матур булмаган чагы юк. Кечкенә кызчыкка карап сокланасың. Күчеш чорында кыз бала тагын да ямьләнә: нәфис гәүдә, хыялый күзләр... Аннары – янып торган яшьлек чоры. Ә ап-ак туй күлмәге киеп, әтисе кочагыннан кияү егете куенына күчкән көнне кызлар аеруча чибәрләнә. Бәби көткән хатын-кызларда үзенә бер матурлык. Мин аларга сокланып туймыйм. Йөрәк астында нәни кешене йөртә бит алар! Урта яшьтәге хатын-кыз – гаиләсе, аның тулылыгы, балаларына сокланып каравы белән матур. Ә мунчадан чыкканда?! Чәчләре юеш, битләре алсу, үзләреннән урман исе килә. Ак яулыгын ябып, өй түрендә намаз укыган акъәбиләр, әйтерсең дөньяның бар пакьлеген җыйган. Мәхәббәткә төренеп яшәсә, хатын-кызлар һәрвакыт матур. Әтисе сөеп алган кызчык канатланып китә, сөйгәненең назын тойган хатынның күзләре янып тора, балалары, оныклары яратуын тойган әби бәхетле елмая. Табигать биргән шул матурлыкны саклыйк без, ир-атлар!






# ТАТАРСТАН. МАРТ.

Ләйлә ФАЗЛЫЕВА,
Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары.

Кадерле хатын-кызлар!
Сезне язның беренче бәйрәме –
Халыкара хатын-кызлар көне белән
чын күңелдән котлыйм!
Бу бәйрәм – мәхәббәт, матурлык, тормыш символы. Ул яңа өметләр уята, күңел күтәренкелеге, яшәү дәрте өсти, иңнәргә канатлар куя. Хәзерге катлаулы заманда хатын-кызга да көчле булырга туры килә. Ул эшендә зур уңышларга ирешү белән беррәттән, җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша, якыннарын кайгыртып торырга да вакыт таба, шул ук вакытта сөйкемле һәм нәфис булып та кала белә. Хатын-кызның хезмәт сөючәнлеге, күңел җылысы, мәрхәмәт тулы йөрәге, сабыр булуы соклану һәм хөрмәт уята. Авыр сугыш елларында кулларына корал алып яуга күтәрелгән, тылдагы бар авырлыкны үткән, яу кырында ятып калган сөйгәннәрен гомер буе көтеп, аларга тугры булган, балаларын ачлыктан саклап калган, ятимнәрне үз кочагына сыендырган хатын-кызлар – батырлыкның иң ачык мисалы!
Бу тормышны тагын да мәгънәле, үзенчәлекле, ямьле итүчеләр дә – сез, гүзәл затлар. Күңелләрегездә һәрчак кояш булсын, игелек, бәхет ташып торсын. Яз сулышы яңа көчләр, илһам өстәсен. Һәрвакыт якыннарыгызның олы мәхәббәт җылысын тоеп яшәвегезне телим!
Хатын-кыз ул – гөлчәчәкнең үзе,
Горур патшабикә, ут-ялкын.
Ул булганга гына дөнья гүзәл,
Җирдә – сөю, күңелләр – якты.

***

**ЛИЛИЯ НАСЫЙРОВА** («Хатын-кыз – ана» номинациясе, Апас) сәхнәгә дистәгә якын эреле-ваклы бала белән чыкты. Дини гаилә ятим балаларны үзенә сыендырып, аларга ата-ана җылысын бирә. Балалары үсеп чыгып киткәч, ире Җәмил белән башта өч бертуган Яна, Андрей, Лилияне алып кайталар. Узган ел биш бертуган – Ксения, Алексей, Светлана, Леонид, Кириллны гаиләле итәләр. Алексейның туган көне балаларны алып кайткан чакка туры килә. Аны мәктәптән шарлар, тортлар белән каршы алалар. Малай: «Бу минем иң яхшы туган көнем», – дип елый. «Алар мине үзләре дә елата, – ди ана. – Әни, без синсез ничек яшәдек икән, диләр. «Безгә кем килсә дә, сездә рәхәт, ди. Ничек рәхәт булмасын, гаиләдә тынычлык, үзара аңлашып яшибез, намаз вакыты җиткән саен, идәнгә 11 намазлык җәелә...»

***

**ЭНҖЕ КИТАЕВА** («Хатын-кыз – галим» номинациясе, Балык Бистәсе) хезмәт юлын шәфкать туташы булып башлаган, хәзер инде районда исеме билгеле табиб. ВИЧ, шикәр авыруы, инсульт, хатын-кыз авыруларыннан районда үзе оештырган профилактика мәктәпләре турында да, зур чараларда сәламәтлек темасына чыгыш ясаучы спикер буларак та, «Эшлекле хатын-кызлар» оешмасында эшләп йөрүләре хакында да сөйли алыр иде ул. Ә ул һаман гаиләсен мактый! Кызлары Мәрьям белән Сабираны, табиб булып эшләүче ире Мансурны... «Әти-әнием – укытучылар, алар өч табиб тәрбияләп үстерде. Минем тормышым бар яктан да медицина белән бәйләнгән», – ди ул. Энҗе ханым шактый зур проектларда да катнаша, аның уйлап табучы патенты бар. КДМУ коллегалары белән берлектә инсультны дәвалауның инновацион ысулын уйлап тапканнар.

***

Җәлил бистәсенең Мәдәният сараенда директор урынбасары булып эшләүче **ЛИЛИЯ ШӘЙМӨХӘММӘТОВАга** («Хатын-кыз – ана» номинациясе, Сарман) тормышта бик авыр сынау кичерергә туры килә: юл фаҗигасенә очрап, аның сеңлесе вафат була. Бердәнбер сеңлесе! Бу хакта сөйләгәндә тавышы әле дә калтырый... Берсеннән-берсе кечкенә ике бала ятим кала... Ире белән утырып сөйләшәләр дә, хәл итәләр: Раилә белән Ренальне үз канатыбыз астына алабыз. Гаилә кинәт кенә шулай өч балалыга әйләнә... Беренче кыенлыклар инде күптән артта калган. Балаларның кечкенәсе – Ренал дә инде беренче сыйныфка укырга барган. Алар үзләрен ятим итеп сизми – «әти», «әни» дип әйтер кешеләре бар. «Сеңлем Ләйләнең рухы тынычтыр», – ди Лилия. Шулайдыр...

Фото: Ната Смирнова, Илсөя Вәлиуллина





# ЕЛ ХАТЫН-КЫЗЫ



Зилә ВӘЛИЕВА, Татарстан Республикасының Иҗтимагый палата рәисе, Татарстан Республикасының «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе.

Нәркис-лаләләр елмаюы төсендә балкып, гүзәл затлар бәйрәме 8 Март якынлаша. Елның иң матур нәфис бер көнедер бу. Гаилә учагын җылытучы, балалар тәрбияләүче, һөнәри уңышларга ирешүче, иҗтимагый эшләрдә кайнаучы, карьера баскычларыннан күтәрелүче хатын-кызларыбыз тагын да матуррак, сөйкемлерәк күренә бүген. Алар әле гаҗәеп талантлы да, алтын куллы да, укымышлы да – үз эшләренең чын осталары!.. «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» дигән республика бәйгесе быел да гыйбрәтле язмышлар белән очраштырды: сокландырды, күз яшьләре аша елмайтты. Көтелмәгән яклары белән ялтырап ачылган бу хатын-кызлар арасында кемнәр генә юк! Күп балалы әниләр, күкрәкләре орден-медальләр белән тулы чал чәчле ветераннар, сугыш чоры балалары, милли традицияләребезне саклаучы мәдәният хезмәткәрләре, балаларның яраткан укытучылары, ачышлар ясаучы фән кешеләре... Бәйгедә катнашкан ир-атлар – чын егетләр! Әллә никадәр игелекле эшләр башкаралар, авылдашларына, районнарына ярдәм итәләр, әмма ул турыда сөйләп-чәчеп йөрмиләр – тыйнаклар! КАМАЗ төзүчеләр, Түбән Кама химиклары, республикабызда кара алтын чыгаручылар, авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләр сәхнәдән Татарстаныбызның нинди куәтле республика икәнен күрсәтә алды. ТАССР төзелүгә 100 ел тулу, Бөек Җиңүнең 75 еллыгы хатын-кызларның республика бәйгесендә әнә шулай гәүдәләнде. Татарстаныбыз уңышлары – сезнең дә үсеш, сезнең дә уңышлар ул. Булдырасыз, кызлар! Һәрчак сокландырып яшик шулай!

***

65 нче комплексның Ветераннар советы рәисе **НАЗИМӘ ЗАКИРОВА**ны («Өченче буын героинясы» номинациясе, Чаллы) бөтен Татарстан беләдер! Гади тәрбиячедән институт деканына кадәр күтәрелгән чын педагог, Татарстанның атказанган укытучысы. «Мәгариф отличнигы» «КамАЗ» төзелеше ударнигы», «Социалистик ярыш җиңүчесе», хәтта «СССР туристы» дигән билгеләргә кадәр бар аңарда. Эльбрус тау түбәләренә күтәрелгән, Кызыл диңгез төпләренә кадәр төшкән кеше. Курайда, гармунда уйный, техникага әвәслеге белән егетләрне дә уздыра! Шуңа аны дуслары, шаяртып, «автомотовелофото электрорадиомонтажер» дип йөртәләр... Үзе сугыш чоры баласы: аңа бер ай булганда Бөек Ватан сугышы башлана, Назимәгә алты ай булганда әтисе сугыш кырында ятып кала. 47 ел элек әтисе каберен эзләп табып, тәүге тапкыр «әткәй» диеп аңа эндәшә...

***

**ГӨЛНӘЗИРӘ ТАЛИПОВА** («Өченче буын героинясы» номинациясе, Мамадыш) бөтен гомерен мәдәниятккә багышлаган. Башта китапханәче булып эшли, аннан район мәдәният йортын, район мәдәният бүлеген җитәкли. Ә 1989 елда «Татар җыры» бәйгесендә лауреат була! Мамадышны дөньяга таныта ул чакта Гөлнәзирә ханым. Татарстанның атказанган артисты дигән мактаулы исемне йөртә. Тынгысыз җан һәрвакыт тынгысыз булып кала: лаеклы ялга чыккач, районның ветераннар советын җитәкли башлый. Өлкәннәрне социаль яклау мәсьәләләрен хәл итү буенча байтак эшләр башкара, алар өчен төрле кичәләр, экскурсияләр оештыра. «Өлкәннәр арасында ялгызларның, бәхетсезләрнең шактый күп булуын күргәч, үз гаиләмнең кадерен тагын да ныграк аңладым», – ди ул.

***

Бөек Ватан сугышы ветераны **ЗИННӘТУЛЛА ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН**ны («Алтын йөрәкле ир-ат» номинациясе, Спас) тамашачы аягүрә алкышлый. Аны чәчәкләргә күмәләр.

Яшьли ятим калып, башта – Балалар йортында, аннары туганнары гаиләсендә үскән егет укуга тартыла. 1941–1943 елларда китапханәче, пионервожатый булып эшли. Ләкин педагогик белем алырга өлгерми кала, фронтка җибәрәләр. 1943 елдан 1951 елга кадәр армия хезмәтендә була. Ә хыялына барыбер ирешә: 1958 елда Ульяновск педагогика институтын тәмамлап, гомере буе мәктәптә эшли. РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы. «Мәктәп миңа әти-әни тәрбиясен бирде, шуңа мин дә бар көчемне балалар укытуга багышладым», – ди ветеран.










PRESSA



# АЛАР – ХИМИКЛАР!



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

**«Без химиклар, химиядә эшлибез...» 120 төрле нефть химиясе продукциясен җитештерүче «Нижнекамскнефтехим» предприятиесе заводлары цехында эшләүчеләр үзләрен бервакытта да эшчеләр дип атамый. Алар – химиклар. Горур химиклар! Горурланмый мөмкин дә түгел, илдә генә түгел, бөтен дөньяга исеме билгеле заводта эшләүчеләр, аны яшәтүчеләр. Сәламәтлек өчен зыяны булган заводта хатын-кызларга урын юк та кебек. Тик гүзәл затларсыз сәнәгать тә, тормыш та алга китә алмый. Алар ир-атлар белән иңгә-иң торып республиканың бу тармагына да үз өлешен кертә. Алар – завод тормышына җан өрүчеләр. Гүзәл затлар булган урында тормыш гөрли.**

**«Бездә хатын-кызлар бик күп. Яшьләр дә, өлкән яшьтәгеләр дә. Укуын тәмамлап туп-туры заводка килүчеләр дә, урау юллар аша килеп урнашучылар да бар... Цехта кечәге укытучылар да эшли», – дип сөйли предприятиенең һөнәри берлек вәкиле Андрей Кузнецов.**

**– Укытучы? Ә без аның белән очраша алабызмы?**



# Ул үз эшен дөрес башкармый икән, завод туктаячак.



### *Кичә – укытучы, бүген – эшче*

Андрей безне машинага утыртып промышленность зонасына таба алып китте. Тик анда бик тиз генә кереп китеп булмый икән әле. Алдан ук язылган хатларны раслатып чыкканнан соң, аннан заводка керү юлына килеп бастык. Безне үткәрмәделәр. Бу капкадан машиналарны кертмиләр икән. Урау юллар белән икенче керү юлына киттек. Ә тирә-якта – торбалар, торбалар... алар чакрымнарга сузылган. Юл өстендә ясалма киртәләр булдырылган капка янына килеп туктадык. «Кызлар, сезгә чыгарга туры килер», – ди Андрей. Фотографыбызның мондый заводларга керүдә тәҗрибәсе бар, мин аптырап торган арада, сикереп торды да: «Әйдә, хәзер таможня аша узабыз», – дип елмайды. Чыннан да, чик аша узуга бик тә охшаган. «Нижнекамскнефтехим» аеруча саклана торган объектлар исемлегенә керә, шуңа күрә дә аңа махсус рөхсәт белән, катгый тикшерү узып кына керәсе. Сак вәкиле машинаны ике кат әйләнеп, астын, өчен җентекләп тикшереп чыкты. Хәтта машинаның бардачогы да энә күзе аша үтте. Паспортлар да кат-кат каралды. Махсус җайланма белән безне дә «сыйпап» алдылар. Аняның фотоаппараты да игътибар үзәгенә эләкте... Сак вәкиле рация аша кемгәдер фамилияләребезне атагач кына машинага кереп утырырга рөхсәт алдык. Предприятиенең ике промышленность зонасы бар. Без кергәнендә дүрт завод, алардан кала, төрле ремонтлау үзәкләре урнашкан. Торбалар тышкы якта күп булмаган икән әле ул, эчтә алар – чутсыз: җир буйлап та сузылган, утыртып та куелган. Торбалар патшалыгы бу дип уйлап куйдым. Шәһәр янында урнашкан аерым бер дәүләт! Урамында беркем күзгә чалынмый. Эшчеләр бүлмәдә компьютер артына утырып, бөтен производствоны контрольдә тота. Компрессор һәм насос җиһазларының 5 нче разрядлы машинисты Гөлнара Гыйльманова да 12 сәгать буе (бер смена) 46 (!) төрле җиһаз эшчәнлеге өчен җаваплы! Бүлмәдәге бик күп компьютерларның берсеннән ул күзен дә алмый. Контроль минут саен түгел, һәр секунд саен кирәк! Экрандагы схемаларга күз төшергәч: «Моны аңлап бетерергә хатын-кыз башы җитәме?» – дип сораганымны сизми дә калдым. «12 ел буе эшләсәң, ник җитмәсен? – дип ихластан елмайды Гөлнара. – Беренче атнасы гына авыр, аннан соң күнегәсең, шушылар белән яши башлыйсың».

– Көяз костюм, үкчәле туфлиләр киеп, чәчләргә прическа ясап, кәс-кәс атлап мәктәпкә барып, укучыларыгыз каршында дәрес бирүне ничек шушы зәңгәр эш киеменә, мәңге бетмәс гүләүгә алыштыра алдыгыз?

– Әле мәктәптә Гөлнара Ринатовна идем, монда мин гап-гади Гөлнара... үз кеше...

Күзләремә кадәр чыккан аптырауны күреп, ул тагын елмаеп куйды. Чын күңелдән! Бәхетле хатын-кызлар гына шулай елмая...

– Укытучы булырга кечкенәдән, балалар бакчасына йөри башлагач ук хыялландым. Мәктәптә гел «биш»кә генә укыдым. Класс старостасы булдым, бик актив идем. Укытучыга кирәк булган барлык сыйфатларым бар иде. Мәктәпне тәмамлагач, Түбән Камага чыгып киттем. Педагогика көллиятендә укыдым. 20 ел башлангыч сыйныф укытучысы булып эшләдем. Эшемне бик яратып башкардым. Балалар яратам! Кияүгә чыккач, шуңа да дүрт бала алып кайттык без. Өемдә үземнекеләр – дүртәү, мәктәптә тагын өч дистәгә якын. «Вакытыңны үзебезнекеләргә түгел, чит кеше балаларына күбрәк бирәсең», – дия иде ирем, уенын-чынын бергә кушып. Мин елмаеп кына куям да, кабат эшкә чумам. Башлангыч сыйныф укытучысының кем икәнен беләсез инде. Ул бит икенче әни! Тәүлек буе диярлек мин алар белән. Укытам, тәрбиялим, кайларга гына йөртмим, алар өчен сөенәм, борчылам... Җитмәсә, читтән торып Чаллы дәүләт педагогика институтында укыйм. Диплом аласы елым иде, беркөн ирем шалтырата: «Эшеңнән китәргә гариза яз, мин сиңа химиядә эш таптым», – ди. Ир сүзе закон инде... Аннан соң мәктәптә дә финанс хәлләре авырлашкан чор. Документларымны алдым да химиядә гардеробка эшкә урнаштым! Аптырамагыз, максат бит заводка эләгү. Ул елларда хатын-кызларга бирегә урнашу бик авыр иде. Эшли башлагач, институт дипломын алып кайтып киштәгә куйдым да, Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү колледжына насос җиһазлары машинисты белгечлегенә кичке курсларга языльдым. Бер елдан соң цехта машинист булып эшли башладым. Беренче көнем әле дә күз алдымда. Цехка килдем, ә анда торбалар... Алар бөтен җирдә һәм бик зурлар. Куркып та калдым. Ияләшәсең икән, бер атнадан соң кечерәйделәр. Разряд арттырыр өчен тагын укыдым әле.

Мәктәптән соң мондагы авыр эшкә ияләшү кыен булгандыр?

– Мин бит авыл баласы. Чистай районының Каргалы авылында туып-үстем. Кечкенәдән авыр эштә булдык.

Фото: Александр Ильин, Анна Арахамия

# Производствода хатын-кыз – тәртип, матурлык һәм ямь.

Эштән курыкмыйм анысы. Бервакытта да һөнәрләрне чагыштырганым, абруйлы, абруйсызга бүлеп караганым булмады. Укытучымы син, югары квалификацияле эшчеме... Алар һәрберсе кирәкле һәм лаеклы. Язмышымны эшче һөнәре белән бәйләгәнмен икән, димәк, миңа ул ошый. Бары тик күңелне биреп эшләргә һәм менә шушындый торбалар оясында да күңелле итеп яши белергә генә кирәк. Шулай да химиядә эшләүнең беренче елларында мәктәпне бик сагындым. Кире кайту теләгем дә булды. Нәрсә туктаттымы? Һөнәри берлек эше. Цехка килеп биш ай эшләгәч үк мине цехком җитәкчесе итеп сайладылар. Җәмәгать эшләре – минем стихиям инде. Сәгатьтән-сәгатькә генә килеп-китеп эшләп йөрү күңелсез ул. Җиһазларны карап-тикшереп йөрү генә дә кызык түгел иде. Укытучылык канга сеңгәндер, күрәсең. Үземне иҗади яктан да күрсәтү теләге көчле булды. Химиягә килеп урнашуның икенче аенда ук гаиләләр бәйгесе узды. Без дә гаиләбез белән шунда катнаштык. Ярдәмчеләрем белән бик күп чаралар әзерләп үткәрдек. Спорт, интеллектуаль уеннар, җыр-бию... Укытучы булып эшләгән чорда алган тәҗрибәм ярап куйды. Җәмәгать эшләрендә кайный башлагач, тагын да яраттым заводны. Яраттырды! Ирем Альберт – таянычым, һәрвакыт ярдәм итәргә әзер. Эштә күрше цехларда гына эшләсәк тә, сирәк очрашабыз. Аның – үз җиһазлары, минем – үземнеке. Аның каравы, өйдә гел бергә. Бу яктан аның хыялы чынга ашты. Сменаларны туры китерәбез дә, ял иткәндә бергә булабыз. Чаңгыга чыгабыз, бакчабызга китәбез. Ә безнең анда җәй көне генә түгел, кышын да тормыш гөрли: тавыкларыбыз, куяннарыбыз бар.

Гаилә династиябез белән шушы заводта без. Иремнең әти-әнисе дә 1965 елда завод төзергә дип шәһәргә килеп төпләнгән. Ике улыбыз – Рөстәм белән Айрат та – «Нижнекамскнефтехим»да эшли. Русланыбыз әле тормышын завод белән бәйләмәде, кызыбыз Әдилә Королев исемендәге Түбән Кама политехник көллиятендә белем ала. Үз һөнәре буенча химиядә эш табарына өметләнә. Балалар үз юлларын үзләре тапты. Аларга монда эшләү ошый. Иртәгәсе көнгә күңелләре тыныч. «Нижнекамскнефтехим» – илнең иң эре предприятиеләренең берсе. Ул – стабильлек гаранты. Җитештерү тагын да автоматлаштырылып, безнең балалар бернинди физик эш башкармыйча, компьютер экраныннан гына карап утырачак әле. Шуңа да балаларның киләчәге өчен борчылмыйбыз. Шушы гигантка кечкенә өлешебезне керткән өчен сөенеп яшибез.

12 ел элек тормышын бөтенләй икенче якка борып, нефтехимия тармагына кереп китүенә бер дә үкенми Гөлнара, чөнки эштән тәм һәм ямь табып яши белә. Нәтиҗәсе дә бар: эш урынында тиз арада разрядын күтәрә, җәмәгать эшләрендә катнашкан ханым быел – «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» зона бәйгесендә «Минем һөнәрем – минем язмышым» номинациясендә җиңүче.



«Баскыч буйлап көнгә бишүн тапкыр менеп төшкән вакытлар була», – ди Розалия. Аның сөйләмендә бернинди зарлану төсмере юк, киресенчә, дәрте ташып тора.

### *Хатын-кыз һәркайда матур булырга тиеш*

...Икенче заводка юл тоттык. Машина тәрәзәсеннән күземне ала алмыйм. Мондагы башняларның биеклеге ничә катлы йортка тиң икән? Биш... ун... унике... Ул баскычлардан курыкмый ничек өскә менәләр?..

Изопрен-мономерлар заводында аппаратчылар утырган цехка керәбез. Зур бүлмәдә ике дистәгә якын компьютер. Алар артында, нигездә, ир-атлар. Хатын-кызлар берничә генә. Ләкин бар! Бер өстәлдә көзге белән помада ята. Хатын-кыз булган җирдә гүзәллек булмый калмый инде. Карашымны күреп булса кирәк, аппаратчы Розалия Парфенова: «Хатын-кыз һәр җирдә һәм һәрвакыт матур булырга тиеш, хәтта җитештерү заводында да», – дип елмайды. Монда компьютерлардан конденсация дәрәҗәсен тикшереп торалар. Бер узелда (төенләнештә) кызыл ут яна икән, компьютер аркылы гына көйләп булмаса, урынга чыгып чабалар... урамдагы башняларга... Цехка килгәнче предприятиенең шәхси сак берләшмәсендә эшләгән Розалия. «Шәһәрне тотып торган предприятиедә эшләсәм, киләчәгем ышанычлы булыр кебек тоелды», – ди ул. Соңыннан Гөлнара кебек үк ул да махсус курслар уза – аппаратчы булырга тели. Әйе, эш урыны сәламәтлеккә зыянлы һөнәрләр исемлегендә. «Аның каравы, ташламалар бар, пенсиягә дә тизрәк чыгачакмын. Аннан, миңа мондагы хәрәкәт ошый. Гел йөреп торырга кирәк», – ди ул. «Актив кеше кайда да актив», – диләр аның хакында хезмәттәш егетләре. Эштә һаман аяк өстендә булуы җитмәгән, баскетбол, волейболга йөри. Коллектив белән завод үткәргән барлык ярышларда



■ Укучысы Айзирә Фәрхетдинова.

■ Елизавета Темникова – тикшеренү-аналитик лабораториядә әйдәп баручы инженер-технолог.



катнашалар. Кирәк икән – чаңгыга басалар, кирәк икән акыл бәйгесендә көч сынашалар. «Безнең цех һәрвакыт беренче өчлектә», – дип горурланалар. Розалиянең ире дә күрше цехта гына эшли. Заводта оештырылган гаилә стартлары аларсыз үтми. «Иң яхшы сменаны, иң яхшы эшчене билгеләп бүләкләү – предприятиенең матур традициясе. Актив булырга – мотивация. Үзеңнең кирәклегеңне тоеп эшлисең», – ди Розалия, фотога төшәр өчен киенеп, ясана-ясана.

Кабат өстәлдәге көзгегә карап алды да, иңсә аша сумка киде. «Бу – противогаз. Завод территориясендә ансыз йөрергә ярамый. Кагыйдә шундый».

## *Үз кагыйдәләре, үз галимнәре*

– Завод беркайчан да туктап тормый. Кешеләр монда – тәүлек әйләнәсе. Күпчелек гомерен шушында үткәрәләр. Ә предприятие өчен иң мөһиме: кешеләр. Шуңа да эшләргә дә, тормышларын җиңеләйтергә дә шартлар тудырырга тырышабыз», – ди Андрей. – Замана белән бергә атлыйбыз. Казанда бөтен дөньяны шаулатып дөньякүләм һөнәри осталык бәйгесе узды. Без дә аннан читтә кала алмадык. Ә хәзер мин сезне фән яшәгән җиргә алып барам...

...Предприятие масштабын аңлар өчен, мөгаен, аны күрергә кирәктер. Бу дәүләтнең үз кагыйдәләре, үз тормышы... Хәтта үз автобус линиясе! Бер тукталыш – бер сәнәгать мәйданы. Һәр мәйданда хатын-кыз үз өлешен кертә. Фәнгә дә...

Тиздән җитештерелә башлаячак продукцияне фәннитехнологик үзәктә галимнәр кечкенә җиһазларда сынап карый, үзенчәлекләрен өйрәнә. Әзер резиналарның сыйфатын тикшерәләр. Монысында резинаны – тартыпсузып, монысында сытып, ныклыгын тикшереп карыйлар, дип аңлаталар безгә. Сүздә генә аңлау бик читен, әлбәттә. Лабораториядә безгә таныш бердәнбер җиһаз – колбалар. Аларга төрле төстәге сыекчалар салынган. Цехтан аермалы буларак, биредә тынлык хөкем сөрә. Ак халатлы белгечләр дә үзара әкрен генә сөйләшә кебек. Елизавета Темникова – тикшеренү-аналитик лабораториядә әйдәп баручы инженер-технолог. Шушы лабораторияләрдә эшләп, кандидатлык диссертациясе яклаган. Полимерлар үзенчәлеген анализлый. 2016 елдан бирле WorldSkills хәрәкәтендә эксперт. Үз укучысы бар: Айзирә Фәрхетдинованы ярышларга ул әзерләгән. Кыз илкүләм ярышларда икенче урынга лаек булган. Хәзер сәнәгать предприятиеләре арасында көзен үткәреләчәк WorldSkills Hi-Tech ярышында катнашырга әзерләнәләр. «Һөнәри осталык ярышлары төп эшебез түгел, билгеле, ләкин ул безгә офыкларны ачты. Элек һөнәри ярышларны завод күләмендә генә уздыра ала идек. Хәзер исә төбәкләр арасында узган ярышларда да катнашабыз. Яшьләр үзләрен әнә шулай күрсәтә ала. Без дә Айзирәне үзебезгә эшкә алдык», – дип сөйләде Елизавета.

Химиядә эшләүче хатын-кызлар кулы белән каучук ясамый, ләкин җиһазлар берөзлексез эшләсен өчен күп көч куялар. Бу – зур җаваплылык. Гигант заводның хатын-кызлары моңа курыкмыйча алына. Чын күңел белән. Хатын-кызларча!

Заводтан чыкканда да безне кат-кат тикшерделәр. Тәртибе шулай. Бу дәүләтнең, әйткәнемчә, үз канунннары. Ә без анда кунакта булдык. Кайтырга кузгалабыз. Инде караңгы төшеп килә. Артта яп-якты булып Түбән Кама заводларының утлары җемелди. «Ә син ул хатынкызларның күзләренә карадыңмы? – ди Аня, бертын баргач. Ул да әле минем кебек күңеле белән завод цехларыннан чыкмаган бугай. – Аларның бит күзләре янып тора! Эшләрен ниндидер бер рәхәтлек белән башкаралар! Шуннан эйфория алалар. Эшен яраткан хатын-кыз – бәхетле хатын-кыз инде ул...»

Ә башкача мөмкин дә түгел... Химиклар бит алар!

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да... Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

# ХЕЗМӘТ ГЕРОЕ ГАНЖӘ












































Фото: Анна Арахамия

Ганҗә ӘХМӘДИЕВА: «Түбән Кама урамнарыннан, хәзер инде күбрәк уйларымда гына, горурлык хисе белән узам. Күпме йортка, мәктәпләргә, биналарга пумалалардагы буяулар түгел, күңелебез яктысы күчкән. Кешеләр тормышына ямь өстәүчеләр идек без, буяучылар».

Ганҗә апаның хезмәт кенәгәсендә ике генә язу бар. Аның беренчесе – 1955 елда 18 яшьлек кызның төзелешкә буяучы булып урнашуы, икенчесе – 1961 елның июнендә Кама елгасы буенда төзеләчәк яшь калага үз участоклары белән эшкә күчерелүе. Хыялый күңелле авыл баласы Азнакай ягындагы туган авылы Әсәйне сагынуын, яшьлек хисләрен, пар канатлы бәхетен, төсләр балкышы итеп, яңа калыккан йортларның диварларына күчерә. Шул йортта яшәячәк кешеләрнең, мәктәптә укыячак балаларның күңелләре дә шатлык белән тулсын... Көн узсын дип түгел, башкарган эше яхшы да, сыйфатлы да булсын дип тырыша җитез Ганҗә. Янәшәсендәге башка буяучыларга да ярдәм итәргә өлгерә. Бригадирлары авырып, дәваханәдә яткан бер ел дәвамында аның вазыйфасын да үти. Җитәкчеләрнең булдыклы, эшлекле кешеләрне күрә һәм тиешенчә бәяли белгән еллар шул... 31 яшьлек Ганҗәне «Татэнергострой» тресты идарәсенә чакырталар. «Балаларым да кечкенә, русчам да ипи-тозлык кына», – дип каршы килеп карый. Үзе шикелле үк төзелештә эшләүче ире, Бөек Ватан сугышы ветераны Мөдәррис тә җитәкчеләр фикерен хуплагач, Ганҗә ризалаша. Аңа 50 кешелек малярлар бригадасын ышанып тапшыралар.

Иң җаваплы объектларны – элекке «горком», елга порты, автовокзал, «Җәлил» кинотеатры, «Бигеш» аэропорты биналарын, «химкомбинат» эстакадасын (башка-башка йортларны) Ганҗә бригадасына тапшыралар. Синең булдыра алуыңа ышаналар, ә бригада кызларың кушканнарыңны җиренә җиткереп үти икән, социалистик ярышларда җиңәргә дә, бишьеллык планны өч елда үтәргә дә була. Әгәр хезмәт чорында ире һәм төзелештә кранчы булып эшләүче уллары Нәҗип белән Әнис аның ныклы терәге булмаса, Ганҗә дүрт чакырылыш шәһәр Советы депутаты булып сайлана да, җәмәгать эшендә катнаша да алмас иде, мөгаен... Шәһәрдә яңа фатир алучылар исә «Ганҗә кызлары» төзегән йортта яшәүләрен эчке бер горурлык белән сөйли. Шуңа күрә дә малярлар бригадиры, 43 яшьлек Ганҗә Галим кызы Әхмәдиевага Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелү шатлыгын буяучы кызлар гына түгел, каладашлары да ихластан уртаклаша. «Азат хатын»ның 1980 елгы ноябрь санын – тышлыгында күкрәгенә Ленин ордены таккан көләч йөзле Ганҗәнең сурәте төшерелгән журналны кулдан-кулга йөртәләр. (Сүз уңаеннан: аның әтисенә дә, ТАССРның иң яхшы терлекчесе буларак, 1936 елда Ленин ордены бирелгән.)

...Бүген Ганҗә апа үзенең гаилә альбомында, данлы узганнарының истәлеге итеп, Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев, хәзерге Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов белән төшкән фотоларны, бригада кызларының рәсемнәрен, мәрхүм ире Мөдәррис сурәтен кадерләп саклый.

Ачык йөзле Ганҗә апа белән саубуллашып, ишеккә юнәләм. Ә иркен кунак бүлмәсендәге гөлләр гүя, уйларымны сизгәндәй, тын гына пышылдыйлар: «Бүгенге көндә шәһәрнең бердәнбер Хезмәт Героена – «миңа аның әллә ни әһәмияте юк та, әмма тарихи гаделлек өчен кирәк», дип әйтүче Ганҗә Әхмәдиевага Түбән Каманың мактаулы гражданы исеме бирелгәнен күрергә язсын иде...»

Фирая МОРАТОВА

PRESSA





# КАРАДУГАН. ГИМНАЗИЯ. ГАМӘЛ ДӘФТӘРЕННӘН...

**Шаккаттырды мине Карадуган! Шәһәрдә, район үзәгендә булса бер хәл, ә монда – авыл җирендә гимназия! Легендар мәктәп директоры Бакый Зыятдинов исемен йөртә! нда инглиз, француз, төрек телләре укытыла!**

**Авыл мәктәпләрендә укучылар саны кими, диләр. Ә монда – арта бара! Карадуган гимназиясендә бүген 186 бала белем ала, 31 укытучы эшли. Чагыштырып карагыз: өч ел элек гимназиядә 140 укучы исәпләнгән. «Яшьләр авылда кала, яшь гаиләләр арта, балалар туа тора», – диләр анә. Күрше Арбаш, Түбән һәм Югары Шубан, Таузар, Түбән Кенә, Югары Кенә, Кенәбаш, Хәсәншәех, Апаз авылларыннан да Карадуганга килеп укыйлар. Сыйфатлы белем, хоккей, хореография, туризм... «Кызыл ромашка» штабы... Алары да ымсындыра, кызыктыра. Бар да формадан йөри! Кызлар шакмаклы итәктән, зәңгәр жилеттан, малайлар – зәңгәр күлмәктән... Ашханәдә 30 сумга ике тапкыр кайнар ризык ашаталар, ә кечерәк классларга ул нибары 27 сумга төшә. Гимназиянең үз президенты, министрлары бар!.. Әллә ниләр белән җәлеп итәләр биредә! «Себер тракты тарихы», «Муса Җәлил» музейларының ачылу тарихы да Карадуган мәктәбе тарихына барып тоташа.**



Эльмира
ЗАКИРОВА

# Гимназия Бөтенроссия, Татарстан күләмендә уздырылган конкурс, бәйгеләрдә гел алдынгы урыннарда!

…Без бер көнебезне Карадуган гимназиясендә үткәрдек. Укытучылар һәм укучылар белән аралаштык. Яңа ачылган актлар залын да, заман таләпләренә туры китереп җиһазланган кабинетларын да, брусчаткалар җәелгән юлларын да күрдек, туризм белән шөгыльләнүгә җайлаштырылган спортзалда «кыя»ларга менүче, «канат юлы»ннан үтүче кызлар-малайлар белән аралаштык. Кул көрәше, шахмат, милли көрәштә катнашучы укучылар белән таныштык.

Икенче катка күтәрелгәндә мәгърифәтчеләрнең кагыйдә итеп язып эленгән алтын сүзләре күңелгә кереп кала: «Тәрбияледән яраладыр тәрбия», «Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас»… Стена тулы дипломнар, Мактау кәгазьләре.

Директор Гөлсинә Фаил кызы Зарипова бер кабинеттан икенчесенә йөртә-йөртә, укучылар, укытучылар белән таныштыра. Тәрбия эшләре, укыту, инклюзив укыту буенча урынбасарлар Гөлүзә Рафаиловна Һашимова, Рәйханә Сәүбәновна Мәрданова, Гүзәл Нурулловна Закирова экскурсовод ролендә гимназия тормышы, уңышлары, планнары турында сөйлиләр. «Мәгариф» илкүләм проекты, һәр укучының шәхси белем траекториясе, универсаль уку гамәлләре, предметара төшенчәләр, аттестацияләр, БДИлар, белем сыйфатына дәүләт контроле… Тиз генә төшенә алмаслык әллә никадәр терминнар, таләпләр бу мәгариф системасында! Һәм шуларның нигезендә балаларга әдәп-әхлак тәрбиясе, тирән белем бирү дигән гап-гади һәм аңлаешлы төшенчәләр ята.

Инклюзив белем бирү юнәлешендә дә эшлиләр. Гимназиядә бу эшне башлап җибәргәндә район башлыгы Рамил Нотфуллин, мәгариф идарәсе җитәкчесе Алия Шагаева, «Игенче» хуҗалыгы рәисе Булат Зыятдинов, эшмәкәр Мокшиннар һәм рухи, һәм матди яктан ярдәм күрсәтеп торалар. Мөмкинлекләре чикле булган 17 бала 9 авылдан килеп укый. Аларны дәресләргә йөртер өчен махсус автобус маршруты билгеләнгән. Сәламәт яшьтәшләре белән бергә укыйлар, аралашалар. Башта куркып кына йөргән балалар гимназиянең үзенекенә әйләнгән. Аларны укырга-язарга өйрәтеп кенә калмыйлар, бүгенге җәмгыятькә яраклашырга һәм киләчәк тормышта үз урыннарын табарга да булышалар.



Гөлсинә Фаил кызы Зарипова: «Без – бер команда! Гимназиябез укытучылары – минем ныклы таянычым, акыллы фикердәшләрем, зирәк киңәшчеләрем».

Гимназия Россия күләмендә 2035 елга кадәр исәпләнгән «Ачык мәктәп» платформасына күчеп бара. Укытучы өй эшләрен интернет аша бирә, интернет аша дәрес үткәрә. Чыгарылыш укучыларының 70–80 проценты югары уку йортларында белем ала. Мине шаккаттырганы – рус теле, математика, биология, физика, химия, тарих фәннәреннән күрсәткечләре ел саен район, республиканыкыннан югарырак икән бит! БДИны 80, хәтта аннан да югарырак баллга тапшыручылар саны да елдан-ел арта бара, диделәр. 2018, 2019 елларда дәүләт йомгаклау нәтиҗәләре буенча гимназия район буенча беренчелекне яулаган. 2017 елда «Татарстан Республикасының иң яхшы мәгариф оешмасы» дипломы белән бүләкләнгән. Менә шулай!..

Укытучылар гимназия директоры үрнәгендә үзләре дә алдынгылыкка, заманчалыкка, матурлыкка омтыла. «Яшь, талантлы укытучыларны ничек сайлап аласыз?» дигән сорауга директор: «Алар үзләре ишетеп килә дә гимназиядә кала. Китүчеләр юк бездә», – дип җавап бирә. Авыл һәм шәһәр мәктәпләре арасындагы аерманы киметүгә юнәлтелгән «Заманча мәктәп» проекты исә директор Гөлсинә Зарипованың эш стиленә әверелгән.

Авыл җирендә гимназия ачу, бинага заманча ремонтлар ясау, балаларда матурлык, зәвык тәрбияләү…

Яраталар Гөлсинә Фаилевнаны. Укытучылар һәм укучылар да, ата-аналар да. Бер сүз белән генә биргән бәяләрен бергә тупласаң да, үзенчәлекле образ туа.

«Җаваплы, элегант, зәвыклы, сүзендә тора, тавышын күтәрми, күп укый, күп белә, эзләнүчән, кешеләрне ишетә һәм тыңлый белә, сүзен авыр итеп әйтмичә җайлап кына җиткерә, мөлаем, матур киенә…

Шигырьләр ярата, әледән-әле Казан театрларында бергәләп спектакльләр карауны оештыра…»

Зарипова исә язмышына рәхмәтле. «Тормышымда гел яхшы кешеләр очрады миңа. Укытучыларым бик күп булды. Һәркайсыннан нәрсәдер алганмындыр. Укытучы образы – җыелма бер герой минем өчен», – ди ул.

Фото: Анна Арахамия

PRESSA



Укытучылар үзләре дә алдынгылыкка, матурлыкка омтыла.

### Укытучы матур булырга тиеш!

Гимназия директоры Гөлсинә Зарипованың бу сүзләрен исә һәр укытучы үзенә эчке бер кагыйдә сыман кабул иткән. Эшләре дә, уй-хыяллары да, үз-үзен тотышы, киенүләре, атлап йөрүләренә кадәр матур булырга тиеш укытучының.

«Без көн саен балалар каршында басып торабыз. Ә алар укытучыны энә күзеннән үткәреп утыра. Шуңа күрә без бөтен барлыгыбыз белән гармониядә булырга тиеш».

Гөлсинә Фаилевна унынчыларда тарих дәресләрен дә алып бара. «Шундый шәп класс, – ди ул укучыларын яратып. – Узган ел да укыттым үзләрен. Хәзер алар бөтенләй башка! Укуның кирәген аңлап йөриләр дәрескә. Таләпләре дә башка. Алар каршында инде син теләсә нинди сорауларына җавап бирерлек әзерлекле, һәрчак формада булырга тиеш. Класска кергәч, иң элек баштанаяк «сканер» аша уздыралар сине. Артык кырыс түгелме? Үз артыннан фәненә мавыктырып алып кереп китәрме? Безнең белем офыкларын киңәйтә алырмы? Шуннан соң гына дәрес башлана. Ике секунд пауза ясап алам: карасыннар, сынасыннар, бәяләсеннәр, соңыннан игътибарлары читкә китмәслек булсын... Көн саен иртән Балтачтан килә-килешли ашыгып кына кабинетыма узганда, кайбер көннәрдә ярдәмчем Алсу артымнан: «Сез бүген бөтенләй башкача!» – дип кала. «Минем дәрес!» – дим. Хәзер инде ул аеруча дулкынланган көннәремне алдан ук белә: бүген сезнең дәрес, дип елмая».

Кара инде, бу укытучы халкы гел мәктәп дөньясында яши икән!

«Укучылардан күреп Гарри Поттерны укып чыктым әле менә. Кайчак укучылардан да өйрәнәбез...»

«Мөхәммәт Мәһдиевнең мәктәп, укытучылар турында язганнарын кайта-кайта укыйм...»

«Коллегаларга Казандагы Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2 нче гимназияне, Актаныштагы гуманитар гимназияне үрнәк итеп сөйлим. Бик ошатып кайттым. Районыбызның һәр мәктәбе шулай ук үзенчәлекле. Алардагы уңай тәҗрибәне үзебезгә алабыз».

Менә шундый ул Гөлсинә Фаилевна. Авылга матурлык, шәһәрчәлек алып килгән. Үзе Балтачта туып-үскән. Казанда педучилище, университетның тарих факультеты, 83 нче лицей, Балтач гимназиясендә завуч, район мәгариф бүлеге җитәкчесе урынбасары, һәм менә сигез ел инде директор. Институттан соң ире Илдарны Ерак Көнчыгышка – Хабаровск краена офицер итеп җибәргәч, Гөлсинә Амурск шәһәрендә дә балалар укыта әле. Тәрбиясендә, үз-үзен тотышында шәһәр кызы чалымнары сизелә. Авыл мәктәбен үзгәртергә дип килгән ул. Хыялы шул. Безнең балалар беркайда да югалып калмасын, үзләрен күрсәтә белсен, башкалардан һич калышмавын, әле өстенрәк тә булуын раслый алсын, ди.

«Мин район үзәгендә укып килдем Казанга. Төшеп калганнардан түгел кебек идек үзебезчә. Әмма Казаннар янында барыбер югалып кала идек. Нәрсәдер әйтергә үз фикеребезне җиткерергә кыенсына идек. Комплекслар компоты, билләһи! Ә хәзергеләр югалып калмый. Шәһәр мәктәбендә эшләдем бит, беләм. Авылныкылар шәһәрнекеләрдән аерылып торадыр, диләр. Юк, алар да шул ук балалар. Безнекеләргә дә шул ук таләпләр. Бүген мин авыл һәм шәһәр балалары арасында аерма күрмим. Әмма авылныкылар күпкә тыйнаграк, кешелеклерәк, ихласрак. Чынлап шулай!»

### Балтач–Карадуган арасы

Шушы җиде чакрымны Гөлсинә Зарипова көн саен иртә-кич руль артында машинасында уза. Күп булса, ун-унбиш минуттыр. Ә никадәр уй-хыяллар, матур хатирәләр белән тулы юл була ул...

Карадуган... Яшьтән таныш, җанга якын авыл. Фәйрүзә апаларына гел кунакка килә иде бит Гөлсинә. Марат җизнәсе колхоз рәисе булып эшләде. Студент чакта исә иптәш кызы белән – аның әтисе прораб иде – шушы мәктәп стеналарын буяп йөргәннәр иде. Кем уйлаган, еллар узгач, биредә эшләргә туры килер дип...

Яшерен-батырын түгел: РОНОда эшләгәндә дә гел мәктәпкә барасы килеп яшәде ул. Чын тормыш, көн саен яңалык, көн саен балаларның мең сорау тулы күзләре белән очра-





шасың... Үз эшеңнең нәтиҗәсе күренеп тора. Ә Карадуган мәктәбенә директор булып килгәч, беренче мәлләрдә ничек куркып калган иде... «Бакый мәктәбе»ндә эшләп кара син! 35 елга якын директор булып эшләп, балаларның гына түгел, укытучыларның, авыл халкының иң дәрәҗәле, абруйлы якын кешесенә әйләнгән оста җитәкче, тынгысыз, гадел, туры сүзле шәхес. Элек-электән Карадуган мәктәбе районда гына түгел, республикада атаклы мәктәп иде. Марканы төшермәскә кирәк! Ә Бакый Шәймулловичның үзе белән аралашулар?! Гөлсинә директор булып килгәч, Бакый абыйсы аның янына кереп утырып, тегесен-монысын сорашып, яшь коллегасының фикерен тыңлап, аны мәктәп дөньясының төрле якларында капшап, сынап, ахырдан: «Булдырасың, сеңлем! Шулай дәвам ит!» – дип канатландырып чыгып киткән иде...

...Әнә Карадуганның яшел, кызыл, фирүзә төсендәге түбәләре күренә. Таллар арасына посып кына Шушма ага, шунда гына «Ишморат болыны». Машина тәрәзәсеннән «Бай урманы» күренеп кала. Бакый күле – авылның зәңгәр күзе булып ялтырый. Карадуган тау башыннан караганда үзенә бер сихри почмак булып күренә. Вертолеттан төшерелгән авыл панорамасы һаман күз алдында Гөлсинәнең. Ай матур соң бу Карадуган! Кызы Гүзәл белән кияве Руслан да, оныклары Әмир белән Әскәр дә үз итә шушы авылны. Бераз үссеннәр әле, дәү әниләре авылдагы атаклы музейга да алып барыр, Себер юлын да күрсәтер... Муса Җәлил шигырьләрен ятлап йөргән малайлар өчен биредәге герой-шагыйрь музеенда гаҗәеп бер дөнья ачылачак! Мәктәп укучыларының Муса Җәлилнең туган авылы Мостафага барулары, ул әсирлеккә төшкән «Үлем үзәне»нә десант төшерүләре, Мәскәүдә Әминә һәм Чулпан Җәлиловалар белән очрашулары, Одессага барып, «Муса Җәлил» теплоходында йөзүләр, Җәлил белән Моабит төрмәсендә утырган Рушад Хисаметдинов белән аралашулар...

Авыл аркылы Себер юлы уза... Почта атларының кыңгырау чыңнарын, каторжаннарның богау тавышларын ишеттергәндәй була ул. Явыз Иван гаскәрләре Казан ханлыгын басып алгач, аңа Себерне яулау өчен юл ачыла. Ул күп сәүдәгәрләрне дә үзенә җәлеп иткән. Шушы юлны, Карадуганда борынгы почта станциясе, этап төрмәсе урнашуны исәпкә алып, Мортаза байның ике катлы йортында 1995 елда «Себер тракты тарихы» музее ачыла. Себердә сөргендә булып кайткан Александр Радищев Карадуган аша үтеп киткән. «Себергә сәяхәт» хезмәтендә ул татарларны тәртипле, чиста халык дип тасвирлаган. Монда яшәүчеләр тукыма ману, мех эше белән шөгыльләнгән. Оренбург якларыннан йомран тиресе алып кайтып, тун-толыплар теккәннәр. Революциядән соң «Кызыл мехчы» промартеле оешкан. Бөек Ватан сугышы башлангач, фронтовиклар өчен киемнәр теккәннәр. Аннары артель Карадуган мебель фабрикасына әверелгән.

Музей залларының берсе Карадуган мәктәбе тарихына багышланган. 1925 елда Карадуганда ТАССРның бишьеллыгы исемендәге икенче баскыч мәктәп ачыла. Анда һөнәрләргә дә өйрәтәләр. Ир балалар – аяк киемнәре, кызлар өс киемнәре тегә.

Гөлсинә Зариповага, тарих фәне укытучысына, бу мәгълүматлар аеруча кызык. Ул Карадуган халкын өр-яңадан ачкандай була. Гомумән, Карадуганда бик үзенчәлекле халык. Монда инде син аларның ышанычын бар яктан да акларга тиеш!

...Гөлсинә Фаилевна, күңеле нечкәреп, ветеран укытучы Мәдинә апа Зыятдинова күптән түгел генә бүләк иткән китапны кулына ала. «Хөрмәтле Гөлсинә ханым! Авылыбызда Карадуган мәктәп тарихын үз биеклегендә дәвам итүегез, алай гына да түгел, Бакый Зыятдинов исемендәге гимназия дәрәҗәсенә күтәрүегез өчен чын күңелдән рәхмәтемне җиткерәм». Ахырга: «Күңелендә шигырь йөрткән кеше бәхетле ул!» – дип тә язып куйган.

«Мин ул ышанычны акладым дип саныйм! – дип әйтәчәк ул үз эшенә нәтиҗә ясаганда. – Сигез ел аз вакыт түгел: шактый эшләр башкардык. Мәктәпне дә, балаларны да, авыл халкын да өйрәндем. Хәтта үзем дә Карадуган кешесенә әйләндем инде. Барысын да яратам!»

Бакый абый Зыятдиновның санаулы гына санда чыккан һәм иң якыннарына – нәсел дәвамчыларына аталган «Гамәл дәфтәрем» дигән китабы бар. Бөтен игелекле эшләре, кылган гамәлләре барланган, шул дәфтәргә теркәлгән аның. Хәзер инде аның эшен дәвам итүче шәкертләренең дә бар кылган игелекле эшләре гамәл дәфтәренә язылып барадыр. Гимназиянең гамәл дәфтәренә.

Мин шул гамәл дәфтәренең кайбер битләре белән танышып кайттым Карадуганнан.





# ӨЙДӘ БӘЛЕШ ИСЕ, Ә КИШТӘДӘ... «ГРЭММИ»

**Эльмира КӘЛИМУЛЛИНА – Россиянең «Көмеш тавышы» рәсми булмаган титул иясе. Аны эстрада артисты дип әйтеп кенә таныштыру иҗат чикләрен кысар кебек. Ул татар сәнгате мәдәнияте өчен янып йөрүче, аның дәрәҗәсен күтәрү, зыялылык өстәү өстендә эшләгән артист. Үзе дә затлы, зыялы! Тормышындагы перфекционистлыгы иҗатына да күчкән. Сәхнәдә тере тавышка җырлаумы, кинода уйнаумы – бар да камил булырга тиеш!**



**Эльмира, исемең бөтен илгә танылуга сигез ел вакыт үтте. Шушы чор эчендә иҗатыңда нинди үзгәрешләр булды?**

– Шушы сигез ел эчендә музыка өлкәсендә кем булуымны аңладым. Эльмир Низамов белән альбом чыгардык, ике концерт туры оештырдык, хәзер яңасына әзерләнәбез. «Голос» проектына рәхмәтлемен: бик күп чит милләт кешеләре татар музыкасын тыңлый башлады. Димәк, мәдәниятебезне, сәнгатебезне башкаларга да яраттыра алабыз.

**Ә шәхси тормышыңда?**

– Бу хакта күп сөйләргә яратмыйм. Кияүгә чыктым. Мин – бәхетле ирнең бәхетле хатыны.

**Опера вокалы белән шөгыльләнгәнеңне беләм...**

– Хыяллар тормышка аша дигән шигарь белән яшим. Һәм кулымнан килгәннең барысын да эшлим. Аллаһы Тәгалә мине үземне күрсәтә алырлык дөрес юлга кертеп җибәрер дип ышанам. Әйе, опера вокалы белән шөгыльләнәм, операда ничек хис иткәнемне сынап карар өчен төрле бәйгеләргә йөрим. Опера сәхнәсендә җырлар өчен әзер икәнемне аңлау белән үк тәкъдимнәр килер дип уйлыйм.

**Концертларыңда һәрвакыт тере тавыш. Югыйсә фонограммага җырлау, музыкантлар ияртеп йөрмәү, күпкә арзанга төшә...**

– Барысы да чын булырга тиеш! Бу – иҗаттагы позициям. Әйе, ул миңа кыйммәткә төшә, тамашачы да әле тере тавышка үткән концертларга күбрәк түләргә әзер түгел. Музыка инструментларыннан башка узган концертлар бик кызганыч һәм көлке. Моны тамашачы әлегә аңлап бетерми бугай. Тик күрәм, халык сыйфатлы музыкага тартыла башлады. Сыйфатлы, димәк, тере тавышка җырлау, тавышыңның бөтен көчен күрсәтү. Быел язын Мәскәүдә үтәчәк классик концертымда микрофон булмаячак. Сәхнәдә бары рояль һәм тере тавыш. Камиллеккә омтылуымны якыннарым да аңлап бетерми кайчак. Әйе, еллар буе шәһәр һәм авыллар буенча гастрольләрдә йөрмим, концерт турымда 72 шәһәр юк. Ләкин тормыш барысын да үз урынына куячак. Үземә беркайчан да хыянәт итмәячәкмен.

**Син җырчы гына түгел, кино артисты да. «Золотая Орда», «Кире» фильмнарында уйнадың.**

– Кино – сихри дөнья ул! Һәр иҗат кешесе кинода төшәргә хыялланып яши. Тырышуларым бушка китмәде, – миңа бәхет елмайды. Ул искиткеч тәҗрибә булды. Актерлык осталыгы мине камилләштерде, сәхнәдә үземне ирекле тотарга өйрәтте. Кинога төшү глобаль максатым түгел. Үземә ошаган сценарийлар булса гына «проба»га барам.

**Ә театр...**

– Сәхнәдә Шиллерның «Мария Стюарт» пьесасындагы төп геройны уйнар идем...

**Композитор Эльмир Низамов белән иҗади дуслыгыңа күпләр сокланадыр, бәлки, көнләшәдер дә. Сер булмаса, бу тандем безне тагын нинди белән сөендерер икән?**

– Тормышымда аның кебек уникаль кеше булуына сөенеп туя алмыйм. Мин Эльмирга таянам, ышанам. Ул чиксез талант иясе генә түгел, шәп кеше дә! Иҗаттагы кыйблабыз да охшаш: бер сукмактан барабыз. Мәскәүдә узачак концерт та – уртак проектыбыз. Бик күп яңа җырлар яздырдык. Берсе тиздән экраннарга чыгачак кинога – саундтрек. Татар җырлары тупланган альбом чыгарып, аны бөтен дөньяга танытырга җыенабыз.

**Эльмира, сине һәрвакыт зыялы, затлы итеп күрергә өйрәндек. Ә өйдә нинди син?**

– Эш һәм өй чикләрен бүлеп карый беләм. Йорт җанлы, тыныч кеше мин. Пешеренергә, өйдә чисталык, тәртип сакларга яратам. Чын татар хатыны инде!

**Яшь, чибәр, талантлы хатын-кыз тагын нәрсәләр хакында хыялланып яши?**

– Диңгез, күл яки елга буенда йорт, янәшәмдә – якын кешем, өй тулы бала-чага, бәлеш исе, ә киштәдә... «Гремми», «Оскар»... Бу хакта сөйләгәндә дә күзләремә яшь килә.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА әзерләде.
Фото: Анна Арахамия.
Видео: Фәнис Садыйков.





# ПРИНЦЕССА СИНДРОМЫ

**Алсу күлмәк, бант, шул ук төстәге чалбар, куртка, башлык... Бүлмәдәге пәрдәләр, хәтта караваt япкычы да алсу төстә. Һәр адымы, гамәле белән башкалардан аерылып торырга тиеш ул! Бөдрә чәчләр арасыннан ялтыравык таҗ күренеп тора, кулындагы уенчыгыннан күзне алып булмый. Чү-чү, балам, нишләп йөгерәсең, принцессалар бит алай эшләми!**

Раилә
ХӘЯЛИЕВА

Беркөнне кызым балалар бакчасыннан кайтты да, каршына куйган аш тәлинкәсен кырыйга этеп:

– Әнием, Амалиянең әнисе аңа гел принцессам дип эндәшә. Ә мин принцессамы? – дип сорау бирде.

– Әйе, – дидем кызымны сөепсыйпап. – Син минем иң матур принцессам!

– Юк, әни, миңа калса... мин – служанка...

Баладан мондый сүзне ишетергә әзер түгел идем, бер мәл югалып калдым. Сүзне дәвам итәр өчен тиз-тиз генә аның фикер юнәлешен барларга тырыштым.

– Кызым?!

– Мин бит өйдә эшлим! (Уф, бу «эшлим» сүзе!) Тәлинкәләр юам, уенчыкларны да җыештырам, син юган табак-савытны сөртәм, чүпләрне җыям...

– Ә безнең өйдә һәркем «эшли»! Һәркемнең үз вазыйфасы бар. Бөтен эш тә әнигә генә калса күңелсез була бит.

– Ә принцессалар эшләми! Бернәрсә дә эш-лә-ми!

Сүзебез озакка китте ул көнне, өйдә башкарылган гамәлләр эш түгел, вазыйфа икәнен дә, «эшләми» торган принцессаларның әкиятләрдә генә булуы, әниләрнең кызларына бары тик яратып кына «принцесса» дип эндәшүе турында да аңлатырга тырыштым кызыма. Сүземне игътибар белән тыңлаганын сизсәм дә, икеләнә калдым. Мультфильмнардагы, әкиятләрдәге образларга ышана торган чагы бит әле. Ә монда хакыйкать икегә бүленде...

Фото: www.pixabay.com

Көннәр уза торды, әмма бу сөйләшү күңелдән һаман китми йөдәтте. Беренчедән, кызымның инде зур үсеп, үзен башкалар белән чагыштыра башлавын сизмәгәнмен, икенчедән, кызларын чыннан да «принцессам» дип үстерүче әниләр тирәлегендә яшәгәнемне абайламый калганмын… Үзенә һәрдаим «принцесса» дигәнне ишеткән сабыйның дөньяга карашы ничек формалаша икән соң? Үзен кем итеп тоя ул? Принцессалар бит алар затлы, купшы, чибәр була. Аларга һәркем яраклашырга тырыша, теләкләре дә бик тиз үтәлә. Әкияттә, әлбәттә. Чын тормышта принцесса булып үскәннәргә көннәрдән бер көнне каршы килүче табылса, теләкләре үтәлми башласа, авырлыклар каршында йөзгә-йөз калса… Әниләр, яратып, «принцессам» дип эндәшкәндә баланың үз-үзен тотышын күзаллыйлар, ә бала бу сүздә башкаларның аңа карата мөнәсәбәтен күрә. «Принцесса» купшы киенгән, барлык теләкләре үтәлгән (кибеттә сораган әйбере алынган, тәмтомнары өелеп торган, татлы ризык ашау тыелмаган…), бүләкләргә күмелгән була. Матур манералар, әни кушканны үтәү?! Юк, юк! Әни миннән принцесса ясаучы!

…Әнисә кечкенәдән үк абыйсыннан да, сеңлесеннән дә үзенең иҗадилыгы белән аерылып торды. Шигырьләр язды, төрле конкурсларда катнашты. Әнисе гел, безнең Әнисә башка төрле шул, дип кабатларга яратты. Борчымагыз, апагыз язарга утырган, дигән кисәтүләргә өйдәгеләр дә ияләшеп бетте. Язсын, укысын гына! Гаилә белән җыелышып бакчада эшләүләр, өйдәге вак-төяк мәшәкать Әнисәне читләтеп кенә узды. Яшүсмер кыз үзенә «ул башка төрле, ул язучы» дип караганнарына ияләшкән иде инде. Мәктәпне медальгә бетерде, университетны кызыл дипломга тәмамлады. Үзенең тиң ярын табып, гаилә корды. Менә шунда инде аңа гап-гади хатын-кыз сыйфатларын үзләштерергә туры килде. Кечкенәдән хуҗалык эшләрен алып барырга өйрәнмәгәч, авыргарак туры килде шул. Әле тагын бәби алып кайтырга җыендылар… Әнисәнең иң зур бәхете – сабыр һәм тор-

## Принцессалар эталоны алга сөрелгән тирәлектә яшибез кебек.

мышчан ире иде. Әнисәгә хуҗалык эшләрендә дә булышты, кәефен дә күтәрде, юк-барга кисәтү ясап та вакланмады. Алар барысына да бергәләп өйрәнделәр. Ә менә күрше апабызның принцесса итеп өф-өф итеп кенә үстергән бердәнбер кызы өлешенә үзе кебек үк принц эләкте. Бик матур яшәргә тиеш иде алар! Гаиләнең бөтен байлыгы да, игътибары да аңа гына бирелгән кыз һәм эти-әнисе зур ышаныч белән җилңгыр тидертми үстергән егет! Тик яшьләрнең икесе дә булдырырга түгел, булганга ияләшкән иде шул. Купшы туйлар ясап бер-ике ай уздымы икән, күрше кызы әниләренә кайтуны ешайтты. «Сездә рәхәт, дип, кунарга да кала. Бала бит әле, нишләтәсең. Кияүдән уңмадык бугай», – дип зарланды беркөнне күрше апа. Ярты ел да узмады, кыз яңадан әниләренә кайтып яши башлады. «Кайтсын, чит кеше янында елап ятканчы, үзебездә торсын. Кеше баласы артыннан җыеп, ашсу пешереп яшьлеген әрәм итәргә…» – дип сөйләнде әни кеше бу юлы. Аңлыйм, бала – йөрәк парәсе, башкалардан ким булмасын дия-дия, кырыкка ярылырга да туры килә кайчак. Аның эше, укуы, дәресләре күп, ял итсен! Аның болай да вакыты юк дия-дия, көндәлек эшләрдән азат итеп, өйдә вазыйфалар бүлешмичә, балага һәрвакыт аерым шартлар тудырырга тырышып ялгышмыйбызмы без, әниләр?!

Бервакыт кечкенә кызым белән балалар үзәгенә килгәч, соңлап кына бала тапкан ханым белән танышкан идем. «Кызымны дәү әни булыр яшьтә тапканымны яхшы аңлыйм. Шуңа хыял дөньясына ышандырып үстермим аны. Көннәрдән бер көнне минсез калса – мөстәкыйль яшәрлек булсын…» Ул вакытта бөдрә чәчле кызга карата әйтелгән бу сүзләр артык кырыс булып тоелган иде. Хәзер бу сүзләрдә хаклык барлыгына ышанам. Ә сез килешәсезме?! Яшьләрнең күбесе гаилә корырга ашыкмый, бик күп яшь гаиләләр яшәп китә алмый аерыла. Бу күренешнең нигезендә дә принц-принцессалык синдромы ятмыймы икән, ничек уйлыйсыз?

Безне әниләр – бер пар сандалиең булса шул җиткән, кышка бер пәлтә, язга-көзгә бер куртка, дип үстерделәр. Кием ягыннан да, уенчыклар алып биреп тә артык иркәләү булмады. Барыбызның да шулай иде. Ә менә безнең буын әниләренең балаларга карашы башка төрле шул. Үзебезгә тимәгән өлешне артыгы белән балаларыбызга бирергә тырышабыз. Безгә мондый түгәрәкләр эләкмәде инде, балам йөрсен, мин мондый уенчыкка кызыгып кына үстем, балам уйнасын, балам ашасын, үзем кия алмадым, балам киенсен… Балага бу чаклы кайгырту, үз өлешен генә түгел, безнең өлешне дә яшәү кирәкме икән соң?! Мондый фәлсәфә белән яшәп балаларыбызны авыр хәлгә генә куймыйбызмы?!

Икенче яктан, кызларның үзләрен принцесса итеп күрү гадәти хәл инде анысы. Купшы күлмәкләр, нәни туфлиләр, бөдрә баштагы таҗлар… Һәр нәни туташның зур хыялы бу, аның дөньяга гүзәл зат булып туууына дәлил түгелме?!

Төрле фикерләр ишетергә туры килде. Кемдер принцесса булып үскән кызларның ахырда гаилә кора алмавы турында мисаллар китерде, кемдер бу дөньяда бөтен кеше аңа гына «тиеш» дип санаган буын үсеп килүен искәртте.

Чыннан да, принцессалар күбәеп киткән заманда яшибез бугай без. Бала өчен барысын да эшләү, киләчәктә ни буласын кем белгән, мөмкинлек булганда иркәләп калырга кирәк дигән кагыйдәне колачлап куллану… Принцессалар да үсә, көннәрдән бер көнне безнең кочактан чыга бит алар. Канат ярдым дигәндә генә язмышлары чәлпәрәмә килмәсен иде! Психологиядә «принцесса синдромы» дигән төшенчә бар. Бу теманы белгечләр шактый өй-

# Королеваның оныкларына кеше хезмәтенең кадере турында кечкенәдән аңлаталар сарайда.

рәнгән. Баладан уйдырма принцесса ясый торган сәбәпләрнең берничәсенә тукталыйк.

### Әти-әни тәрбиясе

Озак еллар бала көтеп яшәүче гаиләдә кыз туса, еш кына ул «принцесса»га әйләнә. Әти-әни аны кирәгеннән артык кайгыртуга, игътибарга күмә. Һәм тормыштан аерып куя! Аңлашыла да инде, көтеп алынган бала бит! Әмма бервакыт бала һәрнәрсәнең аңа гына яраклашкан булуын гадәти хәл дип кабул итә һәм үсә төшкәч, дусларыннан, әйләнә-тирәдәгеләрдән дә шуны көтә башлый.

Бүгенге заман әниләренә үз кызларын башкаларга караганда иң-иңе дип дөньяга таныту хас. Кечкенәдән матурлык салоннарына йөрү, иң кыйммәтле уенчыклар, күлмәкләр алу... Монысы инде бала аша үзеңне раслау дип атала. Кызларны кечкенәдән үз-үзләрен кайгыртырга өйрәтергә, эстетик тәрбия бирергә кирәк, әлбәттә. Әмма культ дәрәҗәсенә җиткермичә генә!

### Мультфильм, әкият, журналлар тәэсире

Кызганыч, балалар өчен чыгарылган мультфильмнар югары мораль тәрбия бирүгә корылмаган шул. Тышкы атрибутлар мөһим! Шул ук матур кием-салым, прическа һәм бик күп табынучыларың булу – бәхет күрсәткече итеп бирелә. Балалар, сәгатьләр буе экраннарга текәлеп, шул хакыйкатьне йота... Әгәр дә бала принцессалар турындагы мультиклар, журналлардан башка бернәрсә белән дә кызыксынмый икән, ул үрнәк итеп күргән ориентирлар турында уйланырга кирәктер.

### Яратуга һәм игътибарга мохтаҗлык

Кайвакыт кыз бала игътибар җәлеп итәр өчен, үз-үзенә таҗ кидертә. Әгәр дә ул принцесса булса, аны барысы да ярата башлаячак дип ышана ул. Бала бу образга төрлечә керергә тырыша. Ә бит чынлыкта балага аны ничек бар шулай ярату-ларын тою гына да җитәр иде...

Әниләр, ә сезнең чын принцлар яки принцессаларны ничек тәрбияләгәннәре турында кызыксынып караганыгыз бармы соң?! Баланы 20 төсмердәге алсу төскә күмү – монысы да без әниләр фантазиясе генә. Чын принцессаларны шактый кырыс шартларда тәрбиялиләр дип беләм. Принц Уильям һәм Кейт гаиләсендәге тәрбия турында сарай журналистлары күп язган иде заманында. Әниләренең, гувернантканың өйдә тәртип урнаштыру өчен бик күп көч сарыф итүләре турында нәни принцесса белән принц яхшы белгән. Уйнаганнан соң уенчыкларын үзләренә җыештырып куярга, ризыкны кадерләргә кирәген аңлыйлар. Бергәләп нидер әзерләр өчен Кейт еш кына Шарлоттаны үзе белән аш бүлмәсенә ала. Уенчык буларак, гаджетлар балаларга бирелми. Ә кием-салымны алар әти-әнисеннән калганны да, Гарри абыйларыныкын да кияргә мөмкин. «Иң мөһиме: сыйфатлы һәм җайлы булсын», – ди Кейт.

Йә, ничек, принцессалар тәрбияләү турындагы күз аллаулар белән королева гаиләсендәге тәртипләрнең уртак ягы бармы?!

Шулай да, инде башына таҗ кияргә өлгергән, әйткәнен үтәтә, сораганын алдырта, үз көенә биетә торган кечкенә «принцессалар» белән нишләргә соң?

1. Тәрбия чараларына игътибар итегез. Аралашуыгыз мактауга гына корылмаганмы? Әти-әни репутациясе ничегрәк куелган. Иң мөһиме – бала тормыштан аерылмаганмы?

2. Принцессалар тормышына гына багышланган мультфильмнарны, китап яки рәсем буягычларны төрләндерергә тырышыгыз. Бала бөтен әйбер белән дә кызыксынучан була.

3. Баланың кием-салымын яңадан барлап чыгыгыз. Купшы күлмәкләр, нәфис туфлиләр арасында чатыр чабып йөрерлек кроссовкалар, джинсы чалбарлар да булсын.

Тәрбия гаиләдән башлана. Әни кеше – бала өчен галәм ул. Мәхәббәт тә, ярату да, кадерләү дә, тәрбия дә... һәрнәрсәдә алтын урталык табу без – әниләр җаваплылыгында. Кызларыбыз затлы да, талантлы да, иң-иңе дә булсыннар иде. Үз-үзләренә, көчләренә ышансыннар. Үзләрен кадерле һәм ярата белсеннәр. Тормышка яраклашкан «принцессалар» булып үссеннәр иде!



**Роза ШӘФИЕВА, психолог**

Кызларны син минем принцессам, дип үстерүнең плюслары: алар үзләрен яратырга өйрәнәләр, үз-үзләренә ышанычлары арта. Киләчәктә шәхес буларак формалашканда бу сыйфатлар аларга ярдәм итәргә дә мөмкин. Үзләрен бәяли, кадерли белергә өйрәнәләр. Минуслары: артык әрсезлек, җир күчәре аның тирәсендә әйләнергә тиеш дип уйлау, артык иркә булып үсү. Бу сыйфатлар балага нинди кыенлыклар тудырырга мөмкинме? Бала үскәч тә һәрвакыт башкалар фикеренә бәйле булып кала. Бар кешенең дә аңа сокланганын, күп игътибар бирүләрен көтеп алҗырга мөмкин. Әгәр дә инде көткәннәре акланмый икән – дөньясы җимереләчәген көт тә тор! Үпкәләр, канәгатьсезлек артачак. Кечкенә чагында ук кызларга сокланырга, аларга ягымлы сүзләр әйтергә кирәк, әлбәттә. Бигрәк тә әти кешенең «син бик матур», «мәрхәмәтле», «кадерле кызым» дигән сүзләре аның күңеленә гомергә кереп калачак. Чөнки әти кеше – кыз бала өчен ир-ат образының тәүге үрнәге. Әтисе нинди, уе белән кыз бала да киләчәктә шундый ир-атны сайларга тырыша.

05
АПРЕЛЬ

ПИРАМИДА
17:00

# ТАТАР TMTV ПРЕМИЯСЕ 2020

МУЗЫКАЛЬ
ТЕЛЕКАНАЛЫ

ЭЛВИН ГРЕЙ | АЙДАР ГАЛИМОВ
ГҮЗӘЛ УРАЗОВА
РИШАТ ТӨХВӘТУЛЛИН
ӘНВӘР НУРГАЛИЕВ
ЗӘЙНӘБ ФӘРХЕТДИНОВА
НӘФКАТЬ НИГЪМӘТУЛЛИН
ИРКӘ | РАЯЗ ФАСЫЙХОВ
ЗИНИРА / РИЗАТ РАМАЗАНОВЛАР
АЛСУ ӘБЕЛХАНОВА
ЛӘЙСӘН ГЫЙМАЕВА
ХӘМДҮНӘ ТИМЕРГАЛИЕВА
ДЖ. РАДИК | АЙРАТ САФИН

ҺӘМ ТАГЫН БИК КҮП
ПОПУЛЯР ҖЫРЧЫЛАР

260 34 34

+6

ОЕШТЫРУЧЫЛАР

barsmedia
ТАТАРСКАЯ МЕДИА ГРУППА

barsmedia
КОНЦЕРТНОЕ АГЕНТСТВО




ГЕНЕРАЛЬ МӘГЪЛҮМАТИ ПАРТНЕР


TATAR RADIOSI
сеть радиостанций

ПАРТНЕР

Kukmara
Сделано в России

РЕКЛАМА

# О-О, МИЛАН! О-О, ЛИЛИЯ!



Рәмзия КАШАПОВА

**Хатын-кыз матурлыгы һәр чорда да мода белән тәгаенләнгән – камиллеккә омтылу, гүзәл затлар дөньясы үзенчәлеге, һәр яңалык җәмгыятьнең шул заманга хас кануннарында чагылган. Бүгенге көннең – үз модасы, үз кагыйдәләре, үз гүзәлләре. «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика конкурсының Чаллыда узган зона турында «Хатын-кыз – бизнес-леди» номинациясендә имиджмейкер-стилист Лилия Давыдова чыгыш ясады. Ул – стиль һәм заманча образлар тудыру остасы. Сәхнәгә килеп чыгуы белән үк тамашачыларда кызыксыну уятты. Юк, Лилия игътибарыбызны җәлеп итеп кенә калмады, аңарда ниндидер сер, шарм бар иде!**

– Таныш булыйк, мин – Лилия Давыдова, персональ стилист, халыкара дәрәҗәдәге имиджмейкер, стилистларның халыкара берлеге резиденты, Имидж һәм Стиль мәктәбе җитәкчесе, Россия хатын-кызлары иҗтимагый-дәүләт оешмасы әгъзасы! – дип башлады ул үзенең визит карточкасын. Төс-кыяфәте мода журналлары героен хәтерләтә иде. – Мәскәүдә берничә тапкыр «Fashion WeekRussia» мода атналыгында, стилистларның халыкара съездында катнаштым. Мин – имидж һәм стиль курсларына өйрәтүче «Перезагрузка» проекты авторы. Мастер-класслар, «Девичник»лар, стилистлар белән бранчлар оештырам... Бәхетле хатын, бәхетле әни мин: җиткән кызым, улым бар...

«Кама аръягы гүзәле», «Татарстан гүзәле» конкурсларында катнашкан, «Нечкәбил» матурлык республика конкурсында җиңгән, 15 елдан артык матурлык индустриясендә эшләүче Лилияне танып алып, алкышларга күмәләр.

Ул – гармонияле һәм рациональ гардероб булдыру тарафдары. Киемдә кешенең эчке дөньясы чагылырга тиеш дип исәпли:

«Һәр хатын-кыз матур һәм кабатланмас. Имиджларын үзгәртеп, күпләргә карьера ясарга, үзен ышанычлырак хис итәргә, үзләрен яратырга булышам».

«Үз компанияләре имиджын күтәрергә теләүче оешмалар белән дә эшлим. Компания танылырлык булсын, уңышлы эшләсен өчен бөтен иҗатымны, фантазиямне файдаланам».

«Мин хезмәттәшлеккә әзер!»

«Онытмагыз: шәхес буларак сезгә бәя биргәнче, иң элек ничек күренүегезгә игътибар итәләр. Төс-кыяфәт, киенү зур роль уйный!»

Стилист Лилия Давыдованың сәхнәдән әйткән сүзләре акыллы киңәш, кагыйдә булып яңгырый. Ә үзе әнә нинди сылу, горур, зифа буйлы, киемнәре аһ итәрлек!

Лилия үзенең иҗатында һәм эшчәнлегендә бер Чаллы белән генә чикләнми икән. Хәтта республика кысалары да тар тоела аңа. Проектлары белән чит илләрне яулый! Йөзләгән хатын-кызларның хыялын чынга ашырып, Миланда киендерә үзләрен!

О-о, Милан! Дөньяның мода һәм матурлык үзәге! Заманча теләсә кайсы хатын-кызның хыял шәһәре. Бай ханымнарның Миланга шопингка баруын телевизордан еш күрсәтәләр. Күпләр өчен бу чынга ашмас хыял. Ләкин шулай микән? Матур һәм модалы күренер өчен Миланга ук бару кирәкме соң?

Серне ачабыз: Миланда яшәүче барлык хатын-кыз да бутикларда гына киенә алмый шул, заказга киемнәр тектерү дә барысының да хәленнән килми, хәтта аутлетлар да күпләр өчен кыйммәт тоела. Миланлылар кайдан кием ала, ничек гел шулай матур күренә икән? Җавап гади генә – базарга барыгыз! Чыннан да, Милан маркетларында юк кына бәягә дә люкс брендлы киемнәр күпләп сатыла, бутикларда йөрисе дә түгел. Хәер, товарлар бик үк сыйфатлы булмаска йә бөтенләй ялган әйбер булып чыгарга мөмкин. Шуңа күрә игътибар белән карап алырга кирәк. Шунда яшәүчеләр сатып алганнарын сайларга тырышыгыз.

Лилия фикеренчә, заманча һәм һәрчак модада күренер өчен «кайчан да килешә» категориясеннән берничә әйберең булса, шуларга туры килә торган аксессуарлар белән әллә нинди образлар ясап була.

Сиңа нибары 20 яшь кенә булса, стильгә туры килгән образ тудыру берни түгел кебек. Бу яшьтә төрле экспериментлар үткәреп, гәүдәңә килешкән киемнәрне киеп карап була: бар да матур, бар да килешә. Әмма ирекле стиль белән эшкә, укырга йөри торган җитди киемнәрне һәрчак дөрес итеп аралаштыра да белергә кирәк. Аннары 20 яшьтә әле бар хыялланган киемне сатып алырга акчасы җитми бит аның.

Менә шундый чакларда Лилия ярдәмгә килә инде. Ул стильле образны тәкъдим итеп кенә калмый, классик әйберләр белән ничек универсаль гардероб булдырырга, төрле очракларның һәркайсына яраклы образны ничек сайларга, нәрсәләргә акцент ясап шәп кәеф булдырырга икәнен дә әйтә.

Әйдәгез, имиджмейкер Лилия Давыдованың үзен тыңлыйк әле.

– Беренче тапкыр күргәч, әйләнә-тирәдәгеләр сезнең турыда нинди фикердә кала икән – шул хакта уйланганыгыз бармы? Иң элек кешенең эчке дөньясы матур булсын дисәләр дә, беренче тәэсирләр барыбер тышкы кыяфәтегездән чыгып билгеләнә шул. Сез «Ура!» кычкырып кереп тә, эффект тудыра аласыздыр, бәлки. Ләкин шулай эшләрсез микән?

Сез килеп кереп җиде секунд узуга туган беренче тәэсирләр турында сөйләшәбез хәзер. Визуаль эффект турында!

Тирә-юньдәгеләрнең игътибарын җәлеп итәсегез киләме? Көлмәк киегез! Чәчләрегезне таратыгыз! Кыю атлап керегез, бер мәлгә тукталып, чәчләрегезне рәтләгәндәй итегез. Бары шул гына! Сезгә инде кызыксынып карыйлар! Ышанасызмы, инде бер кочак бонус җыеп өлгердегез. Бер хәрәкәтегез белән генә дә мизгел эчендә иң кырыс ирләрне үзегезгә караттыгыз.

Алда көтелгән яз-җәйне көздә тотып, иң төп трендларга акцент ясасак та була. Трендлар бик күп, без иңиңнәренә генә тукталырбыз. Төп тема – колористика. Сирень чәчәге, миләүшә чәчәге, шәмәхә төсмерләр бик актуаль булачак. Психологлар шәмәхә төс депрессия уята, дисәләр дә... Ачык шәмәхә төс иҗат итү теләген көчәйтә дип исәпли колористлар. Алар хаклы. Бу төсләр белән укучыларыбыз күңелен дә яулыйсы килә. Шәмәхәнең фуксия, миләүшә, сирень, лаванда чәчәкләре төсмерләре киемнәрдә сирәк чагыла әлегә, шуңа күрә сез бик оригиналь күренәчәксез.

Яз һәм җәйнең икенче тылсымлы төсе – яшелнең төрле төсмерләре. Бөтнек, ментол, фисташка чикләвеге яшеленнән башлап, зәйтүн һәм саз яшеллегенә кадәр. Нәфис яшел төс алдагы сезонда модада булачак. Яшел төс күзләрне ял иттерә, кәефне күтәрә, ә яңа төсмерләр гаҗәпләнү һәм яңалык тойгысы белән ачыла.

Төрле колористика һәм яктыдан караңгырак төсмерләргә күчә бару үз төсмереңне сайларга, үз төсеңне табарга булыша. Ә ул төсмерләрне башка төстәге кием, аксессуарлар белән яраклаштырасың...

Гәүдәсен төз тотмау, муен чокырындагы «бөкре»се күренү хатын-кызны олыгайта. Үзең сизмәсәң дә, башкалар сизә аны. Кайчак шулай да була: ыгы-зыгы килеп, төн йокламыйча мөһим вакыйгага әзерләнеп, иртән көзгегә күз салсаң, арыган хатын-кыз йөзе белән очрашасың. Борчылмагыз. Салкын су белән юынгач, битегез матурланып китәр. Коррекция ясаучы эчке киемнән гәүдәгез тураер. Андый кием үз яшегездән олырак итеп тә күрсәтмәс. Ә менә ясалма керфекләр, кашлар татуажы исә сезне чынлап торып картайтачак...

* * *

Стилист белән килешәсездер, кызлар. Белеп торыгыз: ирләр ихлас хатын-кызларны ярата. Үзегезгә һәм әйләнә-тирәдәгеләргә бәйрәм ясагыз, елмаегыз! Матур бәхетле хатын булу бик килешә сезгә!




РЕКЛАМА STYLIST_L.DAVYDOVA 8 919 646-55-63

**Һәркемнең үз туган ягы, төбәге, үз иле бар. Аныкы – Сарман. Ул аның яшәвен, матурлануын, аягында нык басып торуын тели. Кылган игелекләренең дә күбесе Сарман белән бәйле: «Эшмәкәр Илдар Гамировның матди ярдәме белән Сарман сәнгать мәктәбе каршында җырчы Илһам Шакировка бюст куелды...», «Миләүшә һәм Илдар Гамировлар гаиләсе Сарман районы балалары арасында «Илһам чишмәсе» дигән җыр фестивале үткәрә...» Ә җыр ул – тамырлар! Шагыйрь дөрес әйтә: «җыры барда – халык мәңгелек».**
**Игелекләр моның белән генә чикләнми әле: төзекләндерелгән чишмәләр, зиратлар, аның ярдәмен тойган якташлар... Күңелендә уй һәм гамьнәр булганнар шулай яши.**
**Әңгәмәдәшебез – эшмәкәр Илдар Өнип улы ГАМИРОВ.**

# САРМАН ҖЫРЫ

Гөлнур САФИУЛЛИНА





**ТАМЫРЛАР** Сарман районының кайсы авылына гына барып чыксам да, әтине белмәгән кеше юк бездә. 7 нче класстан соң ул Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый. 17 яшендә үк аны районның иң зур колхозына – «Җинүче»гә өлкән зоотехник итеп куялар. Ә 25 яшендә инде күрше «Коммунизм» колхозына рәис итеп билгелиләр. Җитмешенче еллар бу. Ул елның җәй башында әти өйләнә. Әнием Фәүзия – Балагач авылыннан. Әти белән бер колхозда өлкән агроном булып эшләүче егет шушы авылныкы була – аларны ул таныштыргандыр дип беләм. Урман эчендә утырган бер генә урамлы авыл иде Балагач. Матур авыл! Чишмәсе генә дә өчәү иде! Хәзер инде ул таралды: кем Әлмәткә, кем Җәлилгә күченде. Бер-ике гаилә җәйгә килеп, умарталар гына тота. Биш ел элек анда Сабантуй уздырдым. Бу авылдан чыгучылар гына түгел, бөтен район җыелды. «Мунча ташы» театрын чакырдык... Бездән 15 чакрымда иде Балагач. Үсә төшкәч, мин бабайларга кунакка велосипед белән дә барып чыга идем. Тирә-күрше авылларның берсендә дә җиләк-җимеш түгел, хәтта яшелчә дә үстермиләр. Ә аларда йорт саен алма бакчасы гөрләп утыра! Әле узган җәй дә нигезгә кереп, шул алмалардан, кура җиләгеннән авыз итеп чыктык. Чүп үләне арасында булса да үсеп яталар.

Әти белән әни өч еллап очрашып йөриләр. Әни ул чакта Казанда укыган – шәһәрдә яшәргә хыялланган. Ә язмышы инде башкача язылып куелган булган... Бик оста тегә иде ул. Туксанынчы елларда безгә үзе дубленкаларга кадәр тегеп кигезде. Декабрист хатыны белән бер ул безнең әни: әтине эшкә кая күчерделәр, шунда ияреп барды. Өч тапкыр күчендек.

Минем күңелгә иң якыны – әтинең туган авылы Рангазар. Бөтен җәем шунда үтте. Дини авыл бу: районда иң беренче мәчет 1985 елларда ук анда төзелде. Гамирҗан бабайны яхшы хәтерлим. (Әти фамилияне аның исеменнән алган.) Улыбыз аңа охша-

ган. Озын буйлы иде бабай. Бик ачык кеше иде. Бердәнбер ир-бала онык идем аларга: әби бөтен конфетларны, тәмле әйберләрне миңа дип саклап тора. Нуриасма әби 100 яшькә кадәр яшәде. 95 яшькә кадәр аны үз нигезеннән кузгата алмадык. «Төп нигездән китмим», – диде.

Әти чын коммунист иде – колхоздан ит тә алмады. Алса да, күрше колхоздан сатып алып кайта иде. Кыш көне ягарга утын бетә. Трактор белән урманнан агачны буе белән сөйрәп кайтаралар: әни белән икәү шуны кисәбез аннары. Юеш агачны кабызып җибәрүнең никадәр нужа икәнен искә дә төшерәсе килми...

1977 елда әтине Саратовка, югары партия мәктәбенә укырга җибәрделәр. Ул чакта анда беренче секретарьлар гына укый иде. Утыз яше тулганчы ук «Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исемен, Хезмәт даны орденын алган кеше ул. Яңа гына 75 яше тулды менә. Шөкер, әни белән тигезлектә яшәп яталар. Юбилеена Татарстан авыл хуҗалыгы министрлыгының Мактау кәгазен тапшырдылар.

Сүз уңаеннан әйтим әле, нәсел шәҗәрәбезне 10–15 ел элек үк ясатып алдык. Җиде буын бабаларыбыз язылган анда.



**БАЛАЧАК** Сеңелкәш белән икәү үстек. Араларыбыз яшь тә ун ай гына безнең. Бүген аңарда да өч бала, миндә дә. Гаиләсе белән ул да хәзер Казанга күченде. Әни бик тырышты: «Бергә яшәгез», – диде... Гөлназның бик яшьли ире үлеп китте, улы белән сигез ел икәү генә тордылар. Аннары яңа гаилә корды менә, игезәк кызлары бар хәзер.

Безне әти белән әни бик мөстәкыйль итеп үстерде. Елга бер-ике тапкыр ялга китеп баралар иде алар. Партоешма секретаре – гаиләсе белән, безнекеләр... 8-9 яшьлек балалар өйдә үзебез генә калабыз, дөнья көтәбез. Бабай мәрхүм булгач, сыерны үзебезгә алып кайттык. Аны карау минем өстә иде. Миңа ул чакта 7 яшь. Башак болгатам, өйдән бер чиләк кайнар су алып чыгам...

УАЗ машинасы булса да, әти күбрәк атта йөри иде. Атлар яратты ул! Берсендә зуррак малайлар мине атка атландырды. Ә ул тотты да ат абзарларына таба чабып китте. 6 яшьлек бала кайдан ныклап тотына алсын инде – егылып төшеп калдым, билгеле. Күзне ачуга каршымда атның арт аякларын күрдем: ул өстемнән сикереп чыгып бара иде. Ат кешегә басмый икән. Шуннан соң биш еллап атка бөтенләй якын килмәдем. Зур малайларның мине – колхоз рәисе малаен үзләренчә сынап караулары иде инде бу. Тагын бер хатирә истә. Яз көне тракторлар йөреп, юлда зур тирән чокырлар хасил булган. Алар су белән тулган. Малайлар мине: «Үзең председатель малае, үзең шул чокырны да сикереп чыга алмыйсың», – дип үртиләр. Кердем дә чумдым гына инде... Тирәнлеге ярты метрдан артыграк булгандыр. Өйдә эләкте: «Утка кер дип әйтсәләр, анда да керәсеңме?» – диделәр. Керер идем – әтигә сүз тидерәсе килми бит!



**МӘКТӘП** Мин 3 нче класска кергән елны Сарманга, район үзәгенә күчеп килдек. 1-2 нче классларда «дүртле» билгесе бөтенләй алмадым. Хәтта берне дә! Ә Сарманда миңа беренче «дүртле»не куйдылар... Бөтен фәннәрне дә рус телендә уку беренче чиректә, әлбәттә, авыррак булды. Икенче чиректә инде математикадан барысын да уздырдым... Узган ел җәй башлангыч класс укытучым Римма Ризатдиновна Мөхәммәтҗанова янына кереп чыктым. «Синең сыман тырыш бала булмады», – дип сөйләп торды...

Яраткан фәннәрем математика, физика булды. (Әти ягыннан туганнар барысы да математикадан бик көчле. Кемдер институтта математика укытты, кемдер мәктәптә... Мин, күрәсең, алар ягына тартылган.) Олимпиадаларның берсен дә калдырмадым. Төп конкурентлар – Җәлил бистәсе мәктәбе укучылары иде. Район үзәге булсак та, бездә 5 мең кеше генә яши, ә анда 15 мең. Петровка Завод авылыннан да көчле укучылар килә иде.

Мәктәпне тәмамларга ике ел кала, Сарманның икенче очына күчендек. Мәктәпкә кадәр бездән өч чакрым иде. Көнгә икешәр әйләнгән чаклар булды. Әллә шул ярдәм итте, соңгы елларны спорт мәктәбенә йөргән малайларны да йөгерүдә уза башладым. Институтта инде йөгерү белән чынлап торып шөгыльләндем.

Кечерәк чакта шофер, очучы булырга хыялландым. Ә аннан, ике-өч классташ белән Алма-Атага, чик буе училищесына китәргә җыендык. Тик әтиләр бу теләгемә каршы килде: ерак, диделәр. Арадан беребез генә китте, тик ул да керә алмыйча кире борылып кайтты. Башта үкенеч сыман иде бу, хәзер инде онытылды. Ә армиядә Украинада – чик буенда хезмәт иттем! Очраклы рәвештә шулай килеп чыкты. Бәлки, очраклы да түгелдер...

Теләк дигәннән. Әти, әйткәнемчә, озак еллар колхоз рәисе булып эшләде. Иртәнге дүрттә китә, кичке тугыз-уннарда гына кайта иде. Төшке ашка кайтканда да: «Аннары кабызып булмый», – дип, машинасын капка төбендә кабынган килеш кенә калдыра иде. Әти өйдә озаграк торсын әле дип, бер-ике тапкыр машинасын сүндереп куйганым да булды: трактор белән тарттырып кабыздылар. Тормышны әни алып барды. Ул үзе дә эшли иде бит әле. Безне күрше Бәнат апада калдыра иде – аңарда үстек. Соңгы көненә кадәр аның белән аннары да аралашып яшәдек... Мин укырга керергә җыена башлагач, әти: «Гомер буе җитәкче булып эшләдем, өстемдә гел җаваплылык булды, ә хезмәт хакым баш бухгалтерныкы белән бер иде – бухгалтерга укы», – диде. Казан финанс-икътисад институтына түгел, ә авыл хуҗалыгы институтына керүемне дә әти теләде. Ул чакта бу уку йортларының дәрәҗәләре бер иде. Килдем документларым белән Казанга. Кабул итү комиссиясендә яшь кенә кызлар утыра. «Егет кешегә нинди экономфак, әнә мехфакка керегез», – диләр. Аттестатымда «бишле»ләр генә: бер имтихан тапшырып, мехфакка кереп кайттым.

Ул факультетка кеше җитмәгәнен соңыннан гына белдем… Бер ел укуга аңладым, бу минеке түгел. I курстан соң, үз теләгем белән, сорап армиягә китеп бардым. Илдә булмаган хәл дип калдылар… Кайтуга исә, гариза язып, икътисад факультетына күчтем.



**УҢЫШ** Мин хезмәт итеп кайтканчы дөньялар үзгәргән иде инде. Элекке группадашларымның кайберсе үз эшен ачкан. Аудиторияләрдә вакытны бушка уздырам кебек тоелды – III курстан соң читтән торып укуга күчтем. Сарманга кайтып комбикорма заводына эшкә кердем. Өлкән икътисадчы итеп куйдылар. Бер елдан Изаил Газизуллин мине «Җәлилнефть» идарәсенә баш бухгалтер итеп чакырды. Тагын өч елдан соң Әлмәт шәһәре Сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе Илгизәр Усманов баш бухгалтер урынын тәкъдим итте. (Тормышта миңа юл күрсәткән, ярдәм иткән кешеләремнең икесе – шушылар. Икесе дә мәрхүмнәр инде, урыннары җәннәттә булсын.) Миңа бу вакытта 26 яшь иде. Кул астымда 54 бухгалтер эшләде.

Озакламый үз төзелеш фирмамны ачтым. Берничә елдан, баш бухгалтер вазыйфасыннан китеп, төзү эшләренә генә чумдым. Төзелеш бүген дә безнең эшчәнлекнең бер тармагы булып тора.

Инде медицина җиһазлары белән ничек шөгыльләнә башлавым турында. Дустым җырчы Алмаз Ишмуратов берсендә: «Уфада Айдар Котлызаманов дигән кеше белән таныштым. Ул анда Татар яшьләр оешмасын җитәкли. Бер җырымны бик ошатты, шуңа клип төшерергә булыша», – диде. Клип әзер булгач, барыбыз бергә очраштык. Айдар да килгән иде. Сөйләшеп киттек… «Әйдә, минем бизнеска алын. Мин аны сиңа Татарстанда ачарга булышырмын», – диде ул миңа. Айдар Әмир улын тормыштагы өченче укытучым дип саныйм. Ул миңа, чыннан да, үзе белгәннең барысын да өйрәтте. Башта аларның филиалы гына булып ачылган идек, инде шактыйдан башка чыктык. Бүген Казан гына түгел, Татарстанның зур шәһәрләрендәге барлык клиникалар өчен «чиста мәйданнар комплексы» әзерләү белән шөгыльләнәбез. Санкт-Петербург шәһәренең Р. Вреден исемендәге травматология институтын да тулысынча без җиһазландырдык. Идеаль чисталык таләп ителә торган бу мәйданнарда, ягъни операция ясый торган бүлмәләрдә температура, басым, дымлылык кына түгел, хәтта бер куб метрда күпме тузан бөртеге, микроорганизмнар, химик парлар саны да контрольдә булырга тиеш. Аның сыйфаты без кулланган иң кечкенә элементка да бәйле икәнен әйтмәсәм дә, аңлашыладыр. Операция бүлмәләренең проектын әзерлибез, җиһазларны кайтартабыз, урнаштырабыз, аннан карап торабыз. Җиһазларны Чиләбе өлкәсенең Миас шәһәреннән, Айдарның Уфадагы заводыннан кайтартабыз. Республикада конкурентларыбыз юк, Россиядә дә мондый фирмалар дүрт-биш кенә.



**ДУСЛАР** Дуслар бар һәм берәү генә дә түгел. Эштә таяна алган якын дусларымның берсе, әлбәттә, Айдар. Тик, кызганыч, ул ераграк яши. Икенчесе – Ильвар Мөхлисуллин. Аның әтисе минем әтинең колхозына практикага кайткан булган. Ильвар белән бергә инде 20 ел эшлибез. Ул – техник яктан көчле белгеч: проектлауда, монтажлауда аның кебек көчле инженерлар сирәк.



**МӘХӘББӘТ** Хатыным Миләүшә Җәлил бистәсендә туып-үскән. Без аның белән мин шунда эшләгәндә таныштык. Беркөнне әтисе Мөдәфис абый ишек шакып керде дә: «Директор белән сөйләшкән идем инде… Кыз практикага кайта, алмассызмы?» – ди. «Ә кызыгыз матурмы соң?» – дим, шаяртып. Ул бик тыйнак кеше, «Белмим инде», – дип елмайды гына… Февраль башы иде. Башта бер-ике атна бухгалтерия кызлары янында йөрде Миләүшә. Күзем төшкән саен, күңелемә күбрәк ошый бара… Аннан эш кушып, аны үз яныма утырттым. Ай ярымнан туган көнем булды – аны да чакырдым. Мин дә төшеп калган егет түгел идем бит: фатирым да, машинам да бар, эшем дә. Җиде айдан без өйләнештек. Ярты ел үзебезнең кибеттә сатучы булып эшләде, аннары гына аңа бухгалтериядә эш чыкты.

Миләүшә кебек терәгем булмаса, болай күпкә ирешә алмас идем дип саныйм. Ул бик тыныч кеше. Хәтта мин катырак сүз әйткәндә дә каршы дәшкәнен хәтерләмим. Бөтен нәрсәдән хәбәрдар булса да (дөнья хәлен белеп булмый, аңлап торсын дип, эштәге яңалыкларны аңа һәрвакыт сөйләргә тырыштым), «нигә алай яки болай итәсең» дип, эшемә катнашмады. Миңа ышанды. Ул хәтта Әлмәттәге өч бүлмәле фатирыбызны сатканда да каршы төшмәде. Бизнесымны шул акчага башладым. Ә бит барысын да югалтуым да мөмкин иде… Мин аны ул чакта ике бала белән Сарманга, әтиләргә кайтарып куйдым. Кечкенәсе алты гына айлык иде әле. Өйдә ремонт башлаган чак. Бөтен җирдә тузан, бер бүлмәнең ишеген пленка белән капладык та, Миләүшә балалар белән шунда урнашты. Шул вакыт ул сыер саварга өйрәнде.

Эшем гел командировкалар белән бәйле булды. Чит илләргә дә күп йөрелде: Европаның медицина җиһазлары әзерли торган барлык заводларын карап, танышып чыктык. Көнләшеп җанымны кыйнамады ул… Әлмәттән күчә алмыйча да ике арада биш ел йөрдем. Өченче бала тугач кына, Миләүшә: «Мин монда башка калмыйм, сине югалтырмын дип куркам», – диде һәм гаилә белән, ниһаять, Казанда төпләндек.



**КУРКУ** Барлык әти-әниләр кебек мин дә балаларымның исәнлеге-саулыгы өчен куркам. Илдә стабильлек булмау да куркыта. Дөресрәге, куркытмый – борчый. Бизнестагы кешеләр моны күбрәк тоя… Үзем турында гына уйлап, зарланып әйтүем түгел. Шөкер, эшебез бар. Авылга кайткач, кешеләрнең ничек яшәгәнен, ничек көн иткәнен күрәм бит мин. Нәтиҗәләр ясыйм…



**АКЧА** Минем кулга акча бик иртә керде. 11 яшьтән колхозда эшли башладым. 12 яшьтә үземә – мопед, 15 яшьтә инде мотоцикл сатып алдым. Беренче хезмәт хакым әтинекеннән ике тапкыр күбрәк булган иде. Колхоз рәисе 250 сум ала иде ул чакта, ә минем бер айлык хезмәт хакым 500 сум чыкты! Комбайнерлар ул елларда колхоз рәисеннән өч-дүрт тапкыр күбрәк акча ала иде. Хәзер генә ул җитәкче һәм аның кул астында эшләүчеләрнең хезмәт хакы арасында аерма 10–15 тапкырдан да артыграк... Сенаж салуда эшләдем. 13 яшьтә инде чәчүдә катнаштым – чәчкеч артына басып йөри идек. Югарырак классларда комбайнер ярдәмчесе булып урнаштым. Ә институтта инде төзелеш отрядларына йөрдем.

1989 елны Сарманда беренче кооператив ачтылар – йортлар төзи башладылар. I курсны тәмамлап кайткач, армиягә киткәнче шунда эшләдем. Гади төзелештә ташчылар бер айга 200 сум алса, монда 1 мең түләделәр. Мин шунда «подсобник» булып урнаштым: иртәнге биштән кичке тугызга кадәр бетон, измә ташыдым. Хезмәт хакым бер айга 700 шәр сум чыкты! Беренче машинамны шул акчага алдым.

Әтиләр, тапкан малыңның 10 процентын башкалар – ятимнәр, мохтаҗлар белән бүлешергә кирәк дип үстерделәр. Шуны үтәргә тырышып яшибез. Туган ягыма, якташларыма ярдәм итүне бурычым дип саныйм. Районда сәламәтлеге чикле балалар тәрбияләүче гаиләләргә күптән ярдәм итеп киләбез. Өч авыл зиратының тирә-юнен яңарттык. Карамалынныкын да... Без беренче балабызны югалттык, ул шунда җирләнгән. Ә якташыбыз Илһам абый Шакировның исемен мәңгеләштерүгә алыну, әлбәттә, юктан түгел. Әти председатель булып эшләгәндә Илһам абыйның берничә тапкыр безнең өйдә кунганы да булды. Кунакханәләр юк иде бит әле ул чакта. Гармуннар белән өйдә җырлашып утырганнары әлегедәй күз алдымда... Миңа аның җырлары бик ошый! Гомумән, моңлы көйләр яратам. Юлда гел Илһам Шакировны, Әлфия Афзалованы тыңлыйм. Зөһрә Шәрифуллина, Зөһрә Сәхәбиевалар белән аралашып яшим. Якташым Алинә Кәримова (Прокофьева) күтәрелеп килә менә – аның өчен сөенәм... «Илһам чишмәләре» җыр фестивалендә быел инде йөзгә якын бала катнашты. Аларның берсе дә сәхнәдән бүләксез китмәде. Балага белем бирү барысыннан да мөһимрәк дип саныйм. Ә фестиваль шул ук белем бирү ул. Нәрсә өчен сөйлимме боларны? Акча эшләүдән тәм табуга караганда, болары җанга күбрәк рәхәтлек бирә. Бигрәк тә балаларга булышу. Чынлап әйтәм! Алар яныннан күңел тынычланып кайта, йомшара. Рухландыра! Алай гына да түгел, бизнес алга китә!

Акча эшләүнең чиге юк аның. Ул арада яңәшәңнән гомер үтеп китәргә мөмкин. Соңгы елларда ялга барырга вакыт чыгара башладык – мин моны да уңыш дип саныйм. Үз тапканын үзеннән җәлләүчеләр дә байтак бүгенге көндә.



**БАЛАЛАР** Акчаның өйгә ничек килгәнен белә алар. Ирек мәктәптә укыганда ук безнең монтажчылар янында эшләп йөрде. Кечкенәдән хоккей белән шөгыльләнде ул: башта «Нефтяник»та уйнады, аннан – «Ак барс»та. Өметле уенчы дип санала иде, беренче бишлеккә керде. Командасы белән ярты дөньяны гизде дисәм дә була: Белоруссия, Финляндия, Чехия, Америкада уйнадылар. Ә аннан, 16 яше тулгач, үз теләге белән хоккейны кинәт ташлады. «Укырга кирәк», – диде. Чит илдә белем алыр дип уйлаган идем, ә ул: «Минем сезнең янда торасым килә», – дип баш тартты. Спорт мәктәбендә укыгач, кечкенәдән интернатларда яшәргә туры килде бит аңа, мөгаен, шуңа тагын өйдән ераккка китәсе килмәгәндер. IV курста укып йөри, инде әкрен генә бизнеска да кереп бара.

Мәдинәне гимнастикага биргән идек. Спортның шактый авыр төре бу, әмма ул яратты: ярышларда катнашып, байтак кына призлы урыннар да алды. Аның холкы нәкъ минеке кебек. Әллә шуңамы икән, без бик озак вакытлар уртак тел таба алмадык. Бер-беребезне аңламадык. Ул үскәндә мин көн-төн эштә булдым бит – бәлки, шуңадыр да. Быел ул мәктәпне тәмамлый, араларыбыз да шактый якынайды хәзер. Минем юлдан китәргә – икътисадчы булырга җыена.

Төпчегебезгә – Әминәгә әле 11 яшь кенә. Без аны никадәр тырышсак та, спортның бер төре белән дә кызыксындыра алмадык. Гел атлар дип сөйли башлагач, күптән түгел ипподромга алып барган идек, ул аннан: «Менә минем спорт нәрсә икән!» – дип канатланып кайтты. Атта йөри хәзер.

Балалар белән өйдә татарча гына сөйләшәбез. Бер очрак искә төште әле. Ирекнең Россия җыелма командасы белән Чиләбедә уйнаган вакыты. Кич белән мәктәптән тренировкадан чыгып киләбез. Ирек янында өч-дүрт дусты да бар, барысы да рус малайлары. Мин шунда аңа: «Сынок», – дип дәштем. Ул бик гаҗәпләнеп: «Әти, нигә миңа алай дип әйтәсең?» – дип сорады. Шул вакыт сөенгәннәрем...



**ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ** Холкымда үзгәртәсе килгән сыйфатлар бар инде ул. Хәтта күп! Кызып китә торган гадәтем бар менә. Кайчак уйламыйчарак та әйтергә мөмкинмен. Соңгы өч елда болай да бик үзгәрергә тырышам. Планеркаларда өстәл сугулар юк хәзер: сүземне каты бәрелеп түгел, җайлап, сабыр гына әйтәм. Үземне шуңа өйрәтәм. Болай тизрәк аңлыйлар. Гомумән, яхшы мөнәсәбәтләр аша күпкә күбрәккә ирешергә була. Безнең компаниядә бүген илле кеше эшли. Зур объектлар булганда, алар йөз иллегә җитә. Һәркайсы белән килешеп эшләргә кирәк... Тагын холкымда нәрсәне үзгәртер идемме? Миләүшәдән шалтыратып сорыйм әле, ул мине үземә караганда да яхшырак белә. Сиңа сабырлык җитми диячәк инде, ул үзе бик сабыр кеше. *(Телефоннан сөйләшә.)* Миләүшә, миңа нинди сыйфатлар җитми дип саныйсың? Син болай да идеаль кеше ди... Артык яхшы күңелле? Монысы начар түгел инде аның... Тагын? Миңа игътибарлырак бул ди... Тырышырмын!



# ҖИЛКӘННӘР ҖИЛДӘ СЫНАЛА



Раилә
ХӘЯЛИЕВА

Сәхнә тутырып егетләр-кызлар бии. Шаян көйгә коляскага утырган егетне алып чыгалар, кызлар аның кулларыннан тотып музыка дулкынында бөтерелә башлый. Бу бию күңелне кузгатыр өчен генә куелган, ниндидер шаяру сыман. Менә коляскадагы егет тә, тамашачыны таң калдырып, сикереп төшәр дә башкаларга кушылып бии башлар кебек. Күзләрендә нур, йөзендә гел яктылык аның….

Булат тугач, без дә башта гел могҗиза көттек. Менә йөреп китәр, дип өметләндек. Кайларга гына алып бармадык, нинди генә дәвалар биреп карамадык аңа. Барысы да үзгәрер кебек иде, – ди әнисе Ләйсән. – Бу ситуацияне кабул итү бик авыр булды. Беренче балабызны югалткан идек инде. Дөньяга килеп биш ай гына яшәде... Аннары Булат 28 атналык булып туды. Туганда баш миенә зарар килгән... ДЦП диагнозы куелды. Бала белән гел хастаханә юлын таптадым. Бервакыт өч айга Чаллыдагы «Солнышко» тернәкләндерү үзәгенә килдек. Шул чагында «ДЦПлы балалар» фонды җитәкчесе җайлап кына миңа баламның язмышы белән килешергә кирәклеген аңлатты. «Инде бернишләп тә булмый, тиешле тәрбия, кайгырту бирергә кирәк аңа, – диде ул. – Өй–хастаханә маршрутын таптаудан туктарга, дөньяга иркенрәк итеп карарга кирәк. Менә иреңне өч айга калдырып киткәнсең, ә ул анда берүзе генә ничек яшәргә тиеш?!» Бу сүзләрне ишетү дә, кабул итү дә гаять авыр иде. Өйгә кайтып, бераз вакыт узгач кына ул сүзләрнең мәгънәсе башыма барып җитте. Әйе, инвалид бала – гаиләгә, әти-әнигә зур сынау ул. Аның беренче адымнарын күреп сөенеп булмый, җитәкләшеп бакчага да, мәктәпкә дә бара алмыйсың... Гаилә үзеннән-үзе ябык пространствода кала. Мин инде бу темага бик күп укыдым, белем тупладым. ДЦП бит ул туганда баш мие зарарлану аркасында барлыкка килә торган авыру. Баш мие никадәр травма алса – организмга шулкадәр зыян салына. Тагын бала тапсам, шундый ук диагноз белән туар дип куркасы юк. Булатка 2 яшь чагында Әмирханны алып кайттык. Әмирхан безне өйдән дөньяга алып чыкты. Үзем аралашкан күп кенә гаиләләргә дә мин хәзер шушы хакыйкатьне аңлатырга тырышам. «Мондый бала белән гомер буе яшисегез була. Икенчене дә алып кайтырга курыкмагыз!» – дим. Киңәшемә

## Мин ДЦПлы бала тәрбиялим дип, тормышка чикләр куеп яшәргә ярамый икәнен аңладым.

колак салып, ДЦПлы бала тәрбияләү белән генә чикләнмичә, икенче, өченче бала алып кайтучы танышларым бар. Чыннан да, икенче балалары тугач, әниләр ачылып китә, алар тулы тормыш белән яши башлый, бу балалар аларны өйдән алып чыга.

Ләйсән һәм Рөстәм Заһидуллиннар гаиләсе белән Кукмарада узган «Ел хатын кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» бәйгесендә очраштык. 96 кешедән торган иҗат коллективы белән сәхнә тотты алар. Саба районының мәдәният бүлеге җитәкчесенең чын артистларча чыгыш ясавына күпләр таң калды. «Ир-ат – лидер» номинациясендә чыгыш ясаган гаилә башлыгына таяныч булыр өчен сәхнәгә тормыш иптәше Ләйсән дә, уллары Әмирхан белән Булат та чыкты...

Заһидуллиннар кайда да бердәм алар! Ә бит әле яши генә башлаган, язмыш сукмагына тәүге адымнарын атлаган чорда бу яшь гаиләгә тормышта җитди имтихан тотарга, мөнәсәбәтләрне зур сынаулар аша үтеп ныгытырга туры килә. Ирләрнең мондый йөкне күтәрәсе килмәгән очракларны да беләбез...

– Безнең өйдә мәхәббәттән дә зуррак булып хөрмәт яши, – ди Ләйсән горур итеп. – Бер-беребезне күз карашыннан ук аңлыйбыз, кирәк булганда сабыр итәргә тырышабыз...

Рөстәм белән Ләйсән икесе дә – Саба районыннан. Кыз – Мишәбаш авылыннан, егет – Сабаның үзеннән. Рөстәм автотранспорт оешмасында шофер булып эшли, Ләйсән – ПМК-159 да бухгалтер-икътисадчы. Сабага Фидан Гаффаров белән Ләйлә Дәүләтова концерты килгән көн була ул. Егеткә эштән ике чакыру билеты бирәләр. Концертка ялгызы гына бармас өчен Ләйсәнне чакыра. Икәүләп, шаяра-көлешә, җитәкләшеп концертка төшеп китәләр...

– Иртән эшкә чыгып китәм, кич кайтам, – дип яшьлек эзләрен барлый Рөстәм. – Кызлар күзләргә вакыт юк! Ләйсән белән танышкач та, очрашулар сирәк булды инде, вакыт җитеп бетмәде. 2002 елның августында туй итәргә булдык. Хәзерге яшьләргә әти-әни гөрләтеп туй ясый да куя. Безнең алай булмады. Туйга әзерләнгәнемне беркемгә дә белгертәсем килмәде. Әнигә дә, туганнарга да күңелле сюрприз ясарга булдык. Эштән кредит алдым. Шул акчага туй алдыннан башта Ләйсән белән бергә яшәячәк фатирыбызга ремонт ясадык. Ул акча әле туй чыгымнарына да җитте. Бакчадан кишер-чөгендерләр казып мендек. Ул вакытта телефон заманы түгел, игъланнар газетасыннан татарча туй алып баручы тамаданы таптык, ничек кирәк – шулай аппаратура юнәттек. Үзебезнең туй мәшәкатьләрен беркемгә дә күтәртәсе килмәде. Бик күңелле мәҗлес уздырдык. Туйдан соң минем эшләгән акчам кредит түләргә китте, Ләйсәннекенә яшәп тордык. Сынауларга ир-ат түзми дисез... Менә шулай беренче көненнән үк төрле авырлыклар аша төзелгән кадерле тормышны һич тә җимерәсе, сынауларга бирешәсе килми шул ул. Әйе, шактый авырлыклар аша узарга туры килде. Әмма хәзер менә, Аллага шөкер! Өебез, күңел биреп эшли торган эшебез, иң мөһиме – балаларыбыз бар.

– Тормышта яшим дисәң – ир кешегә юл куя белергә кирәк. Ирдән әллә ниләр көтеп, юкка-барга үпкәләп йөрсәң, ай-һай, хатын-кызга авырга туры килә. 18 еллык гаилә тәҗрибәсеннән чыгып әйтәм: һәрнәрсәгә ипләп кенә, сабырлык белән дә килеп була. Рөстәм безнең бер дә үпкәли белми, әмма бик кызу кеше. Кызу кешенең карарла-

Фото: Ната Смирнова

Ир кешедән булмаганны көтмиләр, аны ничек бар шулай кабул итәргә, теләгәненңне җайлап кына җиткерә белергә кирәк.

ры да кызу була. «Җыеныгыз!» дип әйтте икән, ике минуттан өчебез дә әзер булып каршында басып торырга тиеш! Без инде моңа күнеккән. Җайлап аңлашсаң, ир кешенең дә көе бар аның. Туйдан соң Рөстәм үскән фатирда яши башладык. Тик мин бит авыл кызы. Миңа бакча, ишегалды кирәк! Җир генә алыйк инде, дим Рөстәмгә. Ул кырт кисеп «юк!» ди. Мин тагы гозеремне кабатлыйм… Күңелемнән генә аны да аңлыйм инде. Ул бит кечкенәдән йорт карарга, хуҗалык эшләренә гадәтләнмәгән. Менә хәзер ишегалдыбыз булса – чыгып утырыр идек, бакчабызда бергәләп эшләр идек, дия торгач, өч елдан соң Рөстәм тәки җир алды бит! Аннан инде йорт тергезә башладык.

– Өйнең нигезен Ләйсән белән икәүләп казыдык. Эштән йөгереп кайтам да, Ләйсән белән раствор бутап, өлешләп фундамент коябыз. Шулай бергәләп өй нигезен салдык. Ләйсән төзелеш эшенә бик хирыс ул безнең, ялкауланырга ирек бирми, тегесен ясыйк, монысына тотыныйк, дип, эш фронтын билгеләп кенә тора. Ир кеше бит инде ул башта киреләнеп ала, аннары гына эшкә тотына, ә аннары инде үзем дә кызыгып китәм, бөтенесен дә җиренә җиткереп башкарасым килә башлый.

Рөстәмнең хезмәт кенәгәсенә беренче һөнәре «Шофер» дип язылган. Сәхнәдә җиде минутлык чыгыш ясаганда да тамашачыны таң калдырган кешенең, кайчандыр тыныч кына руль артында утыруын, кайнар яшьлек елларын бары тик юлларга багышлавына ышануы авыр, әлбәттә.

– Мин башта шофер булып эшләдем. Ул чорда оешмалар арасында КВН командалары төзеп ярышу бар иде. Тапкыр, шаян телле, сәхнәне ярату тумыштан бирелгәндер инде. Мәктәптә укыганда ук спектакльләрдә катнаша, концертлар алып бара идем… Безнең оешманың КВН командасына мине гел капитан итеп билгеләлиләр иде. Шундагы чаялыкны күрептерме, миңа Шыңар авыл җирлеге рәисе булырга тәкъдим иттеләр. Ризалаштым. Сабадан 20 чакрым ераклыктагы ул авылга һәр көн иртүк чыгып китә идем. Бу вазыйфада ун ел эшләдем, инде менә хәзер биш ел район мәдәният бүлеге җитәкчесе булып торам. Эш күп, вакыт юк, кем әйтмешли.

Яшь гаиләләр турында сөйләшкәндә үзара мөнәсәбәтләр, берберенә карата ышаныч, көнләшү турында сүз чыкмый калмый. Рөстәм белән Ләйсән икесе дә яшь, чибәр, булдыклы – гел игътибар үзәгендәге кешеләр. Мәдәният дөньясында җитәкче булып эшләүче ир солтаны, балалар белән мәш килүче өйдәге сылу хатын… Юк, юк! Әллә ни төпченәсе дә түгел, көнләшү турында ни әйтәселәрен алдан ук сизеп торам.

– Менә карагыз: иртәгә район Советы җыелышы, аннары Шыңар авылында якташлар очрашуына барасы бар, татар теле бәйрәме, ялларда өйдә аш уздырабыз. Һәр көнне иртән җиденче яртыда улларым белән җыенып чыгып китәбез. Булатны Кызыл Мишә авылындагы коррекция мәктәбендә калдырабыз. Әмирхан Килдебәк мәктәбендә укый, аны шунда кертәбез. Әмирхан, дәресләре беткәч, сәнгать мәктәбенә кайта, баян классында укый. Аннан биюгә китә. Әле кичләрен «Йолдызлык» фестиваленә әзерләнәбез, өйгә тугызынчы яртыга гына кайтып җитәбез. Көнләшеп яшәргә вакыт юк безнең! Ачуланышырга да, берберебез турында әллә ниләр уйлап йөрергә дә вакыт калмый. Матур итеп яшәргә өлгерергә кирәк! Иртәгә ни буласын белмәгән, исән чакта күрешергә кирәк, дим мин. Без дә, Ләйсәннәр дә гаиләдә өч туган. Бергәләп җыелышып, очрашырга яратабыз. Гаиләбезнең тагын бер шундый гадәте бар: атнага бер-ике көн абыйларга кичке ашка йөрибез. Кайчан кемгә барасын Булат алдан ук телефоннан сөйләшеп хәл итеп куя. Туганнар белән ешрак очрашырга кирәк!

– Әйе, Булат безне тәртиптә дә тота, яшәргә дә өйрәтә. Ул бик акыллы, әкәмәт чиста, – ди Ләйсән, Булатны яратып аркасыннан сөя. – Аңа инде 15 яшь. Бөтен әйберне белә, йөри генә алмый. Без анардан һәрвакыт үрнәк алабыз. Гаиләнең иң мөһим кешесе ул. Кем кергән, кем кайткан – бөтенесен барлап тора. Әмирхан мәктәптән кайткач, киемнәреңне элеп куйдыңмы, тәмәке тартмадыңмы, тәртипле булдыңмы, дип, абыйларча кайгырта ул энесен. Нәрсәгәдер ачулана башласам, канәгатьсез булсам, Булатны күз алдына китерәм дә уңайсызланып куям. Безнең бит бөтен мөмкинлекләр дә бар, нигә зарланып торырга?! Соңгы арада Ходайдан һәрвакыт булганын югалтмыйча яшәргә язсын иде, дип сорыйм. Кеше рәхәткә түзми ул, ә менә михнәткә түзә.

Гадәттә, авыру баласы булган гаиләләр уңайсызланып яши, балаларын кешегә күрсәтәселәре килми, – ди әти кеше. – Ә без Булатка мөмкин кадәр дөнья күрсәтергә тырышабыз. Балаларны яклау көне уңаеннан районда коляскалар парады оештырабыз. Былтыр Булатның коляскасын трактор итеп ясадык та, ул да парадта катнашты. Һәр көнне Әмирхан аны урамга алып чыгарга тырыша. Без аңа чана да ясадык, махсус мотоцикл да алдык инде. Узган ел җыйнаулашып чит илгә барып кайттык. Тормышымда булган тәҗрибәмә таянып, һәрвакыт бер нәтиҗә ясыйм: яшәр өчен тырышырга кирәк. Бик тырышырга! Башкалардан өмет итеп кенә яшәсәң, булганын да югалтуың бар. Безнең гаилә сынаулар аша көчле булырга өйрәнә – җилкәннәребез җилдә сынала!

# БЕЗНЕН ЖУРНАЛГА НИЧЕК ЯЗЫЛЫРГА



1

**ТАТАРСТАНДА**
«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП)
рәсми каталогы буенча
Индекс – **П2204**



2

**РОССИЯ ТӨБӘКЛӘРЕНДӘ**
«Роспечать» каталогы буенча
Индекс – **73002**

3

**РЕДАКЦИЯДӘ**
Килеп алу шарты белән
ярты елга язылу бәясе – **330 сум.**
Теләсә кайсы айдан язылырга мөмкин.

Яртыеллыкка язылырга өлгерми калучылар һәр айның
15 нә кадәр язылып, журналны киләсе айдан алдыра ала.

БЕЗНЕ УКЫГЫЗ
Сайтта: **www.syuyumbike.ru**
ВКонтактеда: **vk.com/suumbike**
Фейсбукта: **www.facebook.com/syuyumbike**
Инстаграмда: **www.instagram.com/suyumbike_journal**

РЕКЛАМА 16+



Нинди хыялың бар, тормыштан ни телисең, дип сорасалар: «Шамил белән Регинаны аякка бастыру, Гөлгенәбезне комадан чыгару», – дип әйтәчәк ул. Регинаның инде аякларын селкетүен, янә бер операциядән соң Шамилнең дә аякка басу өмете барлыгын сөйләячәк. «Тагын аз гына тырышсак...» – диячәк. Юк, ул табиб түгел. Гомумән, медицинага бер катнашы да юк бу егетнең. Әгәр аның турында повесть язсалар, тәгаен, өч сюжетка корылган әсәр булыр иде ул. Ә аларны, тегәрҗеп кебек, бер сызык – ЯРАТУ берләштерер.



Лилия ГӘРӘЕВА

# «Кабатланмас эзләр калдырыйк»












## Безне авыл кеше итте. Без – авыл малайлары.

### *Беренче сюжет. Рүзәл – эшмәкәр*

– Син калайны шулай бөгәсеңме? Ә бу өлешен шулай тоташтырасыңмы? Нәрсә була инде бу? – Янына җыелышкан күрше-күлән сорауны яудыра гына.

– Почта тартмасы булачак!

Балтачка баргач, капкаларга беркетелгән матур тартмаларга кызыгып кайткан иде шул Рүзәл. Тартмалар гына түгел, тәрәзә йөзлекләре дә күңеленә кереп калды. Метрәй тәрәзәләрен дә бизәргә иде шул йөзлекләр белән! Авылга тагын да ямь керер иде. «Йөзлек дисең, әле бер тартманы да ясап бетерә алмыйсың!» – егет үзен-үзе ачуланып, үҗәтләнеп кабат эшкә тотынды. Иртәгәсен почтальон кыз газетларны Минһаҗевларның урам як коймасына беркетелгән бизәкле әрҗәгә салып китте...

Авылда хәбәр тиз йөри. Рүзәлгә яңа заказ инде килеп тә ирешә: «Миңа да ясап бир инде?» Авылдашның сүзен аяк астына салырсыңмы? Башта ике тартма ясады Рүзәл, аннары – дүртне. Аннары – көн саен икешәрне... Була икән бит тырышсаң! Югыйсә калайчы булырга укымаган иде үзе. Кесәсендә Казан Федераль университетының дипломы бар. Ул кергәндә КамПИ дип атала иде, хәзер әнә университетның филиалына әверелде. Әй ашкынган иде Рүзәл ул вакытта шәһәргә. Шәһәр диеп алгысынуы нәкъ бер айга җитте. Метрәйнең сандугачларын сагынды, Ыкны, авылдашларын...

– Әти, халык яратты бит бу тартмаларны. Үз эшебезне ачсак, дим, ничек уйлыйсың?

Гомер буе эретеп ябыштыручы булып эшләгән Радик абыйның җавабы катгый иде:

– Син башта хөкүмәткә эшләп күрсәт!

Эшне эзләмәде түгел, эзләде Рүзәл. Кайда да тәҗрибә сорадылар. Интегеп ник укып йөрдем инде, дигән уйлар да килгәләде башына. Соңгы курста укыганда бик зур оешмага әңгәмәгә чакырдылар аны. Урнашырга өлгерми калды – дәүләт имтиханын тапшырасы көнгә туры килде. Шулай килеп чыгуына бер дә үкенми үзе. Ике кулы исән, ике аягы сау булганда югалып калырмы? Иске гаражны җыештырып, станоклар көйләде, Чаллыдан төсле калайлар кайтартты... Әнисе Галия апа да, Балтачтагы Дамир абыйсы да канатландырып тора әнә. Ул чакта беренче тәрәзә йөзлеген ике атна ясаса соң?! Күпме калаен яраксызга чыгарып, ишегалдына өеп куйса соң?!

...Рүзәл Минһаҗев белән Метрәйнең киң урамыннан тәрәзә йөзлекләрен карап йөрибез. Төсле җирлеккә ак чәчәкләр төшерелгән бу бизәкләрне Мөслимне узганда да күргән идек, Сарман авылларында да күзгә чалынды алар... «Синекеләрме?» – дим. «Безнекеләр!» – ди.

Гаражга гына сыймый башлаганына шактыйдан инде. «Мәктәпнең элеккеге остаханә бинасын ал да рәхәтләнеп эшлә шунда. Авылга да ярдәм итәрсең», – ди аңа Мөслимнең район башлыгы Рамил Муллин 2013 елда. Шул елны хосусый эшмәкәр булып теркәлә егет. Башта бер туганы белән генә эшли әле. Әмма заказлары күбәеп, тәрәзәләрне үлчәргә барырга да өлгерми башлагач, үз янына тагын дүрт егетне чакыра. Тәрәзә йөзлекләре, почта тартмалары гына түгел, түбә сырты, өй почмаклары, урам атамалары, су улаклары, вентиляция каналлары – кем нәрсә сорый, шуны ясап бирә бу егетләр. Рүзәлнең: «Мөмкин булганны да, мөмкин булмаганны да ясыйбыз», – дигән сүзенең хикмәте бар. «Әйдәгез, бер әйбер күрсәтәм», – ди дә безне машинасына утыртып Мөслимгә үк алып чыгып китә ул. «Кояшкай» балалар бакчасы ишегалдындагы ике метр ярымлы тәвә кошын күреп, «аһ» итәбез.

«Бик яраткан туган төбәгемә
Булып калсын әле истәлек.
Кабатланмас эзләр калдырыйк без,
Мәңгелеккә диеп килмәдек», – дип, шигырь белән җавап бирә Рүзәл.

– Йөзлекләрне элек агачтан ясаганнар. Синең дә агачтан ясыйсың килмиме? – дигән соравымны бирәм.

– Агачны гел буяп, карап торырга кирәк бит. Калайга исә завод утыз ел гарантия бирә. Илле ел торса да, аңа бернәрсә дә булмаячак. Шуңа да калайдан сорый халык.

### *Икенче сюжет. Миһербанлы йөрәк*

Быелгы «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» конкурсының Актанышта узган зона этабында ул шушы номинациядә чыгыш ясады. Районыбызның иң олы йөрәкле кешесе, диделәр аның хакында.

– Конкурста катнашырга уйламаган да идем. Мактануны өнәмим. Күрсәтерлек эшең булса, халык аны болай да күрә, – ди Рүзәл үзе. – Минем төп эшем тәрәзә йөзлекләре ясау. Ә монысы аның күңел кушканга...

...Әйе, күңеле кушканга алына ул бу игелекле эшкә – хәсрәткә тарыганнарга ярдәм кулы сузарга, моңлы күзләрдә өмет нуры кабызырга...

Ул көннең мизгеленә кадәр хәтерли Рүзәл:

– Регина исемле бәләкәй кызга ярдәм кирәген интернеттан күргән идем. Диагнозы: спинальная мышечная атрофия. Фотодан гына күрү бер нәрсә, аның кадәр йөрәкне сызлатмый. Ә менә аннары аның әтисе Ринатны Мөслимдә – банкта очраттым. Бер мизгелдә күзләребез очрашты да, алардагы моңны күреп, имәнеп киттем. Беркайчан да андый хис кичергәнем юк иде – аяк астымдагы җирне тоймый башладым. Йөгереп урамга чыктым. Күктән талгын гына күбәләк кар төшә. Урам тып-тын. Ник бер кеше, ник бер машина булсын! Әйтерсең дөнья туктап калган. Җаным сулкылдады... Рүзәл, дидем, әле яши генә башлаган, бер гаебе дә булмаган шушы нарасыйга булыша алмагач, син ник яшисең? Ринатны эзләп, кире борылдым. Балтачка барышым иде. Радиодан моңлы җыр агыла. Җанның әрнүенә түзәрлек түгел, юл кырыена туктап, шигырь яздым. Мөслимдәге хәйрия концертында мин дә «Тормыш серем» дип аталган шул шигырем белән катнаштым.

Регинаны дәвалау өчен елына 45 миллионлык дару кирәк. Бер ампуланың бәясе 7,5 миллион тора. Шушының кадәр зур сумманы туплау өчен, хәйрия концертла-

Фото: Анна Арахамия

## Аның девизы: «Кайда бердәмлек – шунда җиңү».

рыннан торган зур дулкын кузгатып җибәрә алар. Ул дулкынга Сарманнар кушыла, Чаллылар, Казаннар...

– Моңарчы мин халыкның 98 проценты яхшы кешеләр дип уйлыйм идем, бер елдан фикерем үзгәрде: яхшы кешеләр 99 процент икән. Һәр концерт алдыннан ярминкәләр оештырдык. Мин почта тартмаларымны алып киләм, кемдер – пирожкилар пешерә, кемдер оекбашлар бәйли... Сарманнан бертуган Рузилә һәм Эльвира апалар, Чаллыда нинди генә чара, нинди генә концерт узмасын, хәйрия тартмаларын күтәреп барып, Регина өчен акча җыялар иде. Югыйсә ул балага алар авылдаш та, хәтта райондаш та түгел.

Акча җыелгач, Аптеевлар визага документлар тапшырды. Әлеге уколны ул чакта бары чит илдә генә кулланалар, Россиядә юк иде ул. Ике тапкыр документларны кире бордылар. Бер нәрсә дә тиктомалдан гына түгел. Ярый әле шулай булган. Быелдан ул препарат Россиягә кертелеп, 41 балага бушлай бирелде. Җыелган акчаларга исә Регинаны тернәкләндерү өчен кирәкле җиһазлар сатып алынды.

Нарасыйның: «Рәхмәт, Рүзәл абый» диюе аның өчен иң зур бәһа. Инде бар көчне кулланып, Шамил белән Гөлгенәне терелтү өчен тырыша яшьләр. Абдуллин Шамилгә 5 яшь. Берничә катлаулы операция кичергән баланың бот сөягенә тагын бер операция ясатырга кирәк. Абдуллиннарның Шуганка авылындагы яши торган йортлары да төзек түгел. Әтиләре Рамил гаиләне тәэмин итү өчен яртышар ел читтә эшләргә мәҗбүр.

Рүзәлнең инстаграм битендәге сәхифәләрен укыйм. «Яраткан эшеңә барып, максатларыңа ирешеп, якыннарың белән гомер сөрү – бәхет. Без тормышның кадерен беләбезме соң? Гел зарланып, кемнедер сүгеп, гаеп табып, юк-бар сөйләп гомернең узганын да сизми калабыз түгелме? Ә кемдер шушы якты дөньяга күзләрен ачып, «әтием-әнием» дип әйтергә тилмереп ята. Бербөтен булып, бу мизгелне якынайтырга тиешбез».

Актаныш кызы Гөлгенә Сафина узган елның 30 июнендә Чаллы медицина училищесына имтихан бирергә барганда юл һәлакәтенә очрый. Һәлакәткә бер сәгать кала, дус кызларына «смс» юллый ул: «Вакытны туктатыгыз!» Кичке сигезенче яртыда аның өчен вакыт туктала... Машинада алар өчәү була. Машина йөртүче егет шунда ук җан бирә, ә ике пассажиры авыр имгәнүләр алса да, исән кала. Баш миенә бик нык зыян килгән 18 яшьлек кыз комага китә. 31 октябрьдә аны аңсыз килеш Грециянең «Эвексия» тернәкләндерү үзәгенә алып киләләр. Яшәү хакы миллионнар белән бәяләнә.

«Без бүген йөгерәбез, чабабыз, ашыгабыз... Алда ни көтәсен белмибез!!! Ходай безгә берләшер өчен сынаулар бирә. Кара болытлар астында калганда мәрхәмәтле йөрәкләрнең бу җирдә күп булуы безгә ышаныч, яшәргә көч бирә». Рүзәлнең инстаграм битендәге сәхифәләр бу.

Гөлгенәне тормышка кире кайтару өчен көрәш әле дә дәвам итә. Аның кабаттан шатланып көлүен күрү – Рүзәлнең иң зур хыялы.

### *Өченче сюжет. Мөслим кырмыскасы*

Аның балачактагы кушаматы – Шагыйрь. «Җитди кеше түгел мин. Шаяртырга, кешеләргә кушаматлар тагарга, нинди дә булса кызык чыгарырга яратам», – дип таныштырган иде ул үзе белән. Мәктәп партасыннан ук КВН дөньясына тартылуы – әнә шул шуклыгыннандыр.

14 яшендә беренче тапкыр КВНда катнаша Рүзәл. Уйнап кына башланган бу мавыгуына быел 15 ел.

– Ул елны Мөслимнең һәр авыл җирлегендә КВН командалары оештырдылар. Безнең «Чикерткә» командасы шул елны ук районда икенче урынны алды. КВН ул – тормышның җитешсез якларын юмор аша кистереп әйтү. Монда үпкә-сапка юк. Хәзер командабыз «Мөслим кырмыскасы» исемен йөртә. Шулай дип атавыбыз юкка түгел. Кырмыскалар – тырыш һәм бердәм. Ә кайда бердәмлек – шунда җиңү! (Бу – Рүзәлнең яшәү девизы.)

Аларның максаты – миниатюралар аша авылдагы тормышның да кызыклы һәм рәхәт булуын күрсәтү.

– КВН пошмас җаннарны да уятып җибәрә торган жанр, – ди ул. – Узган ел командабызда 22 кеше катнашты. «Барысына да ничек роль табып бетерим икән», – дип борчылдым. «Мөслим кырмыскалары» «Әйдә, шаярт!» татар КВН лигасында да җиңү яулады. Ә «Кояшлы Ык»та «Әйдә, шаярт!»ның музыкаль фестивале узды.

Мәскәүләр, Башкортстаннар, Сарманнар, Мөслимнәр, Балтачлар, Арчалар – барыбыз бер гаилә кебек хәзер. Костюмнар алмашабыз, миниатюраларны бергә әзерлибез, ярдәмләшәбез... Безне КВН шулай дуслаштырды.

«Кояшлы Ык» – Мөслимнең горурлыгы. Ык буендагы табигый паркны яшьләр үзләре шулай атаган. Быел «Кояшлы Ык» федераль Сабан туе кунакларын каршыларга әзерләнә.

«Авылны яшәтәсе иде бит!» – дип хыяллана Рүзәл. «Син аны яшәтү юлларын ничек күрәсең?» – дим.

– Безнең Метрәй балалар бакчасына бүген 30 бала йөри. Бер авыл өчен аз түгел бит инде бу, – ди ул. – Метрәйдә генә дә унбишләп эшмәкәр. Мин менә калай бөгәм, кемдер брусчатка җитештерә, терлек асрыйлар, казлар тоталар, тимер бөгәләр, блоклар ясыйлар... Яшьләргә авылда да яхшы итеп яшәргә мөмкин булуын аңлатырга гына кирәк. Авылга караш үзгәрәчәк әле ул.

Гади генә итеп, «авылдан без» дип әйтеп куюларында да авылын эчкерсез яратуы чагыла аның. Хатыны Алисә белән (ул Башкортстан кызы. Мөслим Яшьләр үзәгендә эшли) туган нигезендә йорт җиткезә Рүзәл. Инде ике ел рәттән йортына сандугач кайтып оялый икән. Бу йортта олы йөрәкле, игелекле егет яшәвен сизенәдер ул да.

– Көненә берәр файдалы эш эшләмәсәм, ул көн бушка узган сыман миңа. Ә инде берәрсенә ярдәмем тисә, кич өйгә кайткач, күңелемә шулкадәр канәгатьләнү килә. Кешеләргә булыша алуыма шатланам. Хезмәтем, көчем – милләтем өчен! Бу дөньяда хуҗа булып түгел, кунак булып яшик, – ди Рүзәл.

# ТААРУГА – ТАУ ЧӘЧӘГЕ

**Иң элек мине остаханәнең ТААРУГА (фин-угыр телендә – тау чәчәге) дигән исеме үзенә җәлеп итте. Аннары – киемнәре, хуҗасының үз эшен генә түгел, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне һәм, әлбәттә, кешеләрне яратуы. Әнә шундый сыйфатларга ия булган кеше генә хатын-кызларның һәркайсын бизәрлек киемнәр уйлап таба ала. Үлчәмнәр, буй озынлыклары, комплекциялар, җәмгыятьтә тоткан урын – берсе дә мөһим түгел бу очракта. Беренче чиратта син – хатын-кыз! Татьяна ЕФРЕМОВА – әнә шуны, шул кагыйдәне яхшы белгән осталарның берсе.**

Яз! Якты кояш, күтәренке кәеф... 2020 елгы яз-җәй модасында – күз явын алырлык өр-яңа тенденцияләр. Юнәлеше кайбер үзгәрешләр кичерсә дә, бохо стиле чын-чынлап лидерлык позициясен алды. Ачык матур төсләргә яңа детальләр өстәлде: чуклар, эре итеп бәйләнгән челтәрләр... Контрастлар исә шулкадәр стильгә килешеп тора!

ТААРУГА киемнәре сыйфаты, бәяләре һәм, әлбәттә, матурлыгы белән үзенә җәлеп итә. Һәрвакыт һәм һәр җирдә арзанлы да, модалы да, табигый дә булган киемнәрдән йөри дә алмыйсың әле. Ә брендлар авторы Татьяна Ефремова менә шуңа ирешкән! Ачык күңелле, игътибарлы, тамчы да тәкәбберлек юк аңарда, талантлы, тырыш... Мөгаен, шул сыйфатлары белән үзенә тартып торадыр ул. Балачак, һәр ике яктан да әби-бабаларының куплеге аңа күп нәрсә биргән: белемен дә, күнекмәләрен дә, осталыгын да... Тегәргә, чигәргә, челтәрләр бәйләргә өйрәнгән. 2000 нче еллар башында, тәвәккәлләп, үз эшен ачып җибәргән һәм уңышларга ирешкән: Россия мода индустриясендә ул лаеклы урында.

Бүген Татьяна модельләре – этно һәм пред-а-порте классына караган киемнәр. Провансаль стиленең модалы тенденцияләре Урал халыкларының традицион мәдәнияте белән тыгыз бәйләнгән, алар фин-угор мотивлары белән кушылып китә. Төрле тукымаларны аралаштырып теккән күлмәкләр әбиләребезнекен хәтерләтә. Миннән алда гына кием сайлаган кызлар әниләре өчен дә, намаз укыганда, ашка барганда кияргә дип тә күлмәкләр сатып алдылар.

Вак чәчәкле штапель күлмәкләр берничә сезон инде тренд саналды, киләсе елда да популяр булачак алар. Күлмәкләрдәге флористик орнаментлар лидерлык позициясен ала. Югары сыйфатлы твидтан, трикотаж йоннан тегелгән пальто, камзол, жилетлар кемгә дә ошарлык. Тиздән балалар өчен дә коллекция булачак, Татьяна коллекциясендә текстиль уенчыклар бар инде: төлке-куяннар, 3 яшьлек сабый гәүдәле гаҗәеп курчаклар...

Нинди яшьтә булуыгызга карамастан, сез моннан буш кул белән китмәячәксез! ТААРУГАда сезне көтәләр!

Рәмзия КАШАПОВА

Модель: К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты Резеда Сәлахова.

мастерская
Тааруга

Кибетнең адресы: Казан шәһәре,
Бауман ур., 51/50 нче йорт, ГУМ.

www.taaruga.com/o-kompanii-taaruga
ok.ru/taaruga
instagram.com/taarugashop
vk.com/taaruga

РЕКЛАМА

PRESSA

# КЕШЕЛЕКНЕҢ СЕЗДЕР ЧӘЧӘГЕ...

Равил ФӘЙЗУЛЛИН

### *Бәлки, Син...*

Бәлки, Син – минем җырланмас
иң гүзәл җырымдыр?
Бәлки, син – минем чыгалмас
иң данлы юлымдыр?

Бәлки, Син – минем меналмас
иң биек күгемдер?
Бәлки, син – күтәралмас
гомерлек йөгемдер?

Бәлки, Син – минем беркайчан
кул җитмәс кошымдыр?
Бәлки, син – үзем аңламас
бәхетем алкышыдыр?

Рәдиф ГАТАШ

* * *

Шагыйрьләргә тик илһамчымы син,
Татар кызы?! Күпме ярасын
Бәйләдең бит илнең! Әле озак
Безгә бергә-бергә барасы,
Сине, ак калфаклы алиһәбез,
Сынауларның көтә яңасы...

Борынгының Афродитасымы? –
Син Тукайның, бәлки, Зәйтүнәсе –
Әрнүләрнең горур Музасы.
Тарих аша синең йөрәктә ул
Килә назның сабыр туташы –
Язмышларның тугры юлдашы!

Күпме шагыйрьне син алып килдең
Татар Парнасының тәхетенә.
«Зәүкың» өчен түгел, хисең һаман
Тоташ ил җанына, бәхетенә:
Безнең тулпарда син таккан чуклар
Бәйгеләрдә барган чагында.
Гамь, дибез еш – җәрәхәтле хәтер
Гасырлардан кайтып чагыла,
Ул синең дә тере – җаныңда...

Татар кызы, Муза, Алиһәбез,
Әле озак бергә барасы,
Ахыргача бул син моң туташы,
Ахыргача ил, җыр ярасын
Син ябарсың наз-яулыгың белән...
Чор, җир тетри...
Безгә – барасы!

ЗӨЛФӘТ

### *Кичер*

Назларымны кичер – соңардылар,
Язларымны кичер – соңардылар,
Күзләремне кичер – соң бактылар,
Сүзләремне кичер – елаттылар...

Буш булганы өчен – кулларымны,
Кушылмавы өчен – юлларымны,
Ашыкканы өчен – елларымны,
Ашыкмавы өчен – уйларымны...

Барысын да кичер... Елап-көлеп...
Мин кичергән, гафу иткән кебек.

Ренат ХАРИС

### *Серле йолдыз*

Мәхәббәтем канатланды минем,
сөеклемә таба юл алды.
Ләкин аңа барып ирешмичә
галәм киңлегендә югалды.

Нигә-нигә телем әйләнмәде,
белгертергә йөрәк хисемне?!
Хәзер инде йолдызларда бугай
сөйгәнемнең нурлы исеме.

Көмеш нурлар җыям учларыма,
яңгыр тамчыларын җыйгандай.
Бәлки, алар хәбәр йөртәләрдер
серле йолдыз тулы җиһаннан.

Ул да карар әле йолдызларга,
бер нур керер әле күзенә
һәм аңлатыр кайнар хисләремне
мин әйтәсе иткән сүз белән.

Нигә-нигә телем әйләнмәде,
белгертергә йөрәк хисемне?!
Хәзер инде йолдызларда бугай
сөйгәнемнең нурлы исеме.

Фәннур САФИН

### *Ил кызларына*

Чәчәк эзләп йөрим кырларда,
Белмим сезне ничек зурларга.
Теләп сезгә изге теләкләр,
Йолдыз булып яна йөрәкләр.

Кайгыларны сыйпап аласыз,
Хәерле юл теләп каласыз.
Сез бит шундый назлы
һәм чыдам,
Сезне уйлап юлга мин чыгам.
Балкый анда еллар,
Без барасы юллар
Ала якты нурлар
Сезнең күзләрдән!..

Күзләрегез көлеп торсын гел,
Юлыгызга яусын алсу гөл!
Сезнең өчен якты җырларым,
Данлыйм илнең
батыр кызларын!

Харрас ӘЮП

### *Матурларга*

Бу табигать сезнең бер карашка
Никадәрле кодрәт яшергән! –
Күпме йөрәк сезнең коллыктадыр...
Сезнең алда шаһлар баш игән.

Гомерегез – безгә бер бүләктер:
Сезнең белән көннәр нурлырак,
Яшәү мәгънәлерәк сезнең белән,
Сезнең белән җырлар моңлырак.

Карашларың ничек тартылмасын:
Кешелекнең сездер чәчәге;
Күпме куллар сузыла үзегезгә, –
Кыенрактыр сезгә яшәве.

Әллә сезгә сынау өчен генә
Бирелдеме икән матурлык:
Гүзәлләргә җанын матур килеш
Саклап йөртә алу – батырлык!

Зиннур МАНСУРОВ

### *Табышу*

Учак-учак йолдызлары,
кочак-кочак кызлары...
Минем куенга кергәне
син – бердәнбер кыз бары.

Кычкырасым килә күккә:
– Гомерлегем, яктым! – дип, –
Мәхәббәттә ятим чагым,
сау бул, инде таптым!.. – дип.

Сөю сукмаклары озын –
барасы да барасы.
Ничек кулга иялэштең,
ах син, болан баласы!..

Газинур МОРАТ

### *Син вә мин*

Син ул – гүзәл!
Син ул – нәфис!
Миндә һаман элеккечә:
йөгәнләнгән
уй-хис.

Син ул – камил!
Син ул – матур!
Миндә һаман
элеккечә:
хөкем итә
салкын акыл.

Нигә әле күңелемдә
уянмаган уй соң?..
Ә бит синдә
күрер күзгә
искитәрлек
буй-сын...

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

* * *

Сәфәр китәм еракларга, –
Күтәрдем җилкәннәрне.
Алга дәшеп яна йөрәк,
Ә үзе никтер әрни.

Сәфәр китәм еракларга, –
Саф күңел, ап-ак җилкән.
Тик нигәдер әрни йөрәк –
Аерылышу авыр икән.

Каян эзлим сине, дисең,
Сагынган чакларымда?
Кемнәр кулын бирер, дисең,
Абынган чакларымда?

Сәламнәр җибәреп сиңа,
Юксынып җырларымда,
Чәчәкләр сибеп барырмын
Мин үткән юлларыма.

Учак ягармын төннәрен,
Утым биектә янар,
Шул җирләрдән эзлә мине –
Эзләрем булыр кайнар!

Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ

* * *

Көз сиңа дүрт алма биргән
Һәм әйткән: «Сеңел, менә
Икесен битеңә куй син,
Икесен – күкрәгеңә».

Кыш сиңа аклыгын биргән
Һәм әйткән: «Сеңел, менә
Яртысын тәнеңә сип син,
Яртысын – күңелеңә».
Җәй сиңа эсселек биргән
Һәм әйткән: «Сеңел, менә
Берэзын куеныңа сал,
Калганын – йөрәгеңә».

Яз сиңа мине биргән
Һәм әйткән: «Сеңел, менә
Бәхетле ит бу егетне,
Сөяр ул сине генә».

Ленар ШӘЕХ

### *Бу язларны сиңа бүләк итәм...*

Бу язларны сиңа бүләк итәм,
Ул язларга сыйган барсы да –
Мәхәббәт тә, күңел сафлыгы да,
Җанны эретерлек ярсу да.
Бу язларны сиңа бүләк итәм,
Ул язларда яшәү моңы бар.
Күктән тамган тамчы чыңнарында
Сөенеч һәм бәхет тыны бар.

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН

### *Син идең*

Җан авыртып, әрнегәндә күңел,
«Барсы узар әле, көт», – дидең.
Һәм бар дөнья мине оныткanda,
Минем янда бары син идең...

Яшь тәгәрәп, битне чылатканда:
«Юк, килешми, зинһар, сөрт! –
дидең.
Маңгаемнан үбеп юатучы
Минем янда һәрчак син идең...

Аерылганда, күзең күтәрмичә:
«Мин яратам сине бик!» – дидең.
Мин дә сөйдем,
һәм ул сөйгән кешем,
Сездең микән... Бары син идең...

Рифат СӘЛАХ

### *Күпләр сиңа гашыйктыр*

Хушлашабыз... Чын күңелдән теләк:
Ярларыңнан һаман ташып тор!
Берни булмас диеп сүнә күрмә,
Күп егетләр сиңа гашыйктыр.

Бу тормышның кырыс чынлыгыннан
Хыялларың белән качып тор.
Мин киткәннән дөнья җимерелми,
Күп егетләр сиңа гашыйктыр.


Язмышыңнан гына кача күрмә,
Һәр иртәне ишек ачып тор.
Яратып та өлгермәдең бугай...
Күп егетләр сиңа гашыйктыр.

Хаталарың синең төзәтерлек,
Хаталандым мин дә, ачык бел!
Миндәй яраталмас сине кем дә,
Бәлки күпләр сиңа гашыйктыр.

Ләбиб ЛЕРОН

### *Без табышкан көн*

**М**өлаем елмаю...
Бүген дә хәтерли**М**:
**И**кәү без. Биибез.
Мизгелләр илаһ**И**!
**Н**аз тоям – бәхетле итәчәк
килер кө**Н**...
**С**әп-сәер бер халәт –
җанымда яңа хи**С**,
**И**ләрә музыка. Биибез...
Төн би**И**...
**Н**әзакәт хәрәкәт. Карашың –
мут, ная**Н**.
**Е**шая сулышлар, йөрәкләр тибү**Е**...
**Я**т йөзләр, парсызлар бер
читтә моңа**Я**.
**Р**иясыз күңелемдә уяна
пакь уйла**Р**,
**А**кылны йөгәнлим –
ыргыла ул алг**А**:
**Т**абышу. Танышу. Кавышу.
Йөрәк ша**Т**.
**А**к дөнья. Назлы яз.
Бөреләр уян**А**...
**М**өлаем елмаю... Әле дә хәтерли**М**..





Ризидә Гасыймова сезгә яхшы таныш. «Сөембикә» журналы сайтының блогеры. Уйландырырлык язмалары, фәлсәфи фикерләре белән үзенә тарта торган журналист. «Тузга язмаган дөнья» исемле китабына публицистик язмалары урнаштырылган. «Кешеләрне нәрсә борчый – шулар турында язам», – ди ул. Авыл, туган тел язмышы, сәясәт, психология, үзара мөнәсәбәтләр... Чаллыда нәшер ителүче «Көмеш кыңгырау» газетасының баш мөхәррире ул. Ризидә өчен балалар газетасы – үзе бер рәхәт дөнья.

«Сөембикә» журналында Ризидә Гасыймованың дебюты – игътибарыгызга хикәясен тәкъдим итәбез.



Ризидә ГАСЫЙМОВА

*кайту*

# КАЙТУ

– Әни, Самат шалтыратты!

– Нинди Самат әле ул? – дип игътибарсыз гына сорады парланган тәрәзә пыялаларын ап-ак чүпрәк белән сөртеп йөргән Минзифа түти.

– Самат, – дип тагын бер кабатлады кызы, син аңларга тиеш дигәндәй гаҗәпсенүле тавыш белән.

– Сәкинә апаңның малаемыни? Туктале, Самат идемени соң әле аның исеме? Кем әле ул Самат?

– Әни, Гөлфиянең... ире...

– Ә-ә-ә, Саматны әйтәсеңмени син?

Инде Минзифа түти эшеннән бүленми булдыра алмады.

– Балаларның кайтасы килә, ди.

– Балалар белән кайтабыз, димени? И Аллам, чынлапмы? Кайчан?

– Әни, нишләп һаман аңламыйча торасың соң син? Самат әле рөхсәт сорап кына шалтырата. Әби каршы түгелме, ди.

– Аларын әйтмәгән иең бит әле.

– Ярты сәгатьтән соң тагын шалтыратачак. Ни дип җавап бирим?

– Мунча ягарга кирәк, – диде Минзифа түти, кызының соңгы сүзләрен гел ишетмәгәндәй, һәм җәһәт кенә урыныннан кузгалды.

Ашыга-кабалана ишеккә таба атлаган әнисе артыннан Фәридә аптырабрак карап калды. «Картая-картая әллә җиңеләя башлады инде», дип уйлады ул ирексездән. Юк, уйларга кирәк. Нәрсә дип җавап бирергә Саматка? Әни каршы, дип кенә котылыргамы? Әллә дөресен әйтергә – йөзенә бәреп: «Ничек оялмыйча кайтмакчы буласың, без бит барысын да беләбез», дияргәме? Ул шуларны уйлап, төгәл бер фикергә килә алмый тора иде, өйалды ишеге ачылып, әнисенең тавышы ишетелде:

– Фәридә, оеп торма инде, әйдәле, мунчаны ягып җибәрик, мин бер кочак утын алып килдем.

...Фәридә кире өйгә әйләнеп кергәндә, Минзифатти ак алъяпкычын биленә бәйләп, кабалана-кабалана камыр басарга җыенып йөри иде. Әле генә сызланып йөргән карчыкка шул арада каян хәл кергәндер?

– Әни, әллә кайтмагыз, дип кенә әйтикме соң? Кыен булыр бит, – дип җайлап кына сүз кушып карады Фәридә.

– Кемгә?

– Сиңа...

– Ай Аллам, һаман сөйләнүдә бу! Эшең юкмыни соң синең бер дә? Әнә өйалларын сөртеп ал. Теге малай, Камилне әйтәм, галошы белән өй ишегенә кадәр ерып кергән бит. Кем килмәс? Өйалларың һәрвакыт чиста булсын, дип әйтә торганые мәрхүмә әбиең.

– Келт-келт-келт...

– Тек-тек-тек...

Сәгать бер көйгә генә текелдәп, аны бик азга гына ерак үткәннәргә алып китте.

Минзифа түти Мөхәммәтханы белән ике кыз үстерде. Яшьрәк чакларында Пермь якларында яшәделәр. Әй, эчүдән башканы белмәгән ир белән күрмәгәннәрне күрде инде... Аннары кызларының кечесе – Гөлфиякәе, 25 яшен дә тутыра алмыйча, ике баласын ятим калдырып, фаҗигале төстә китеп барды. Шуннан соң Мөхәммәтхан да әллә ни озак тормады инде. Олы кызы Фәридә, рәхмәт төшкере, әнисен ялгыз калдырмады: ире, малае белән авылга кайтып төпләнде. Бергә тату гына яшәп яталар менә, Аллага шөкер. Яшьләрнеке яшьләрчә шул, яңа йорт-җирләр җиткезделәр. Исән-имин генә була күрсеннәр инде.

Шул мизгелдә телефон шалтырады.

– Бу – Самат, – диде Фәридә һәм нишлим дигәндәй әнисенә карады...

Самат Гөлфиядән ун яшькә олы иде. Саматка – 28, Гөлфиягә – 18. Ялынып та карады инде Минзифа түти кызына. «Яшь аермагыз зур бит, кызым, көнләшер», – дип тә үгетләде, «Эчәргә хирыс түгел микән», – дип тә шикләнде. Тик Гөлфия, бичаракай әнисенең кисәтүләрен колагына да элмәде. Хәер, яшь чакта әни сүзен тыңлыймыни инде кеше? «Мине ярата бит ул, әни, – диде Гөлфия. – Мине беркемгә дә бирмәячәк ул».

Өйләнештеләр дә, Саматның эше буенча башка шәһәргә китеп бардылар. Заводтан яшь белгечкә (инженер, ни әйтсәң дә) фатир вәгъдә иткәннәр итүен, тик аңа кадәр яшәп торырга дип завод барагыннан бүлмә биргәннәр икән. Менә шул берничә ай яшәп торырга дип бирелгән бүлмәдә Гөлфияләргә биш ел яшәргә туры килде. Гөлфия пешекчелеккә укыган иде, бер-бер артлы ике бала табып, үз һөнәре буенча эшли дә алмады. Тик эшсез дә утырмады – баракка кушылып ук киткән завод бинасына җыештыручы булып урнашты.

Кызының бәхетле түгеллеген сизде, билгеле, ана йөрәге... Хатларында да ниндидер сагышмы, әйтеп бетерелмәгән сүзме бар иде кебек. Аннары кунакка баргач, кияү кешенең бабасы белән исергәнче эчүе дә күңеленә хуш килмәде Минзифа түтинең, холыксызлыгы да сизелде. Бабасы белән бер-ике тапкыр эләгешеп китә яздылар. Ә соңгы баруында...

Соңгы баруында – каршы йорт подъезды янында утырган карчыклар кибеткә чыгып барган Минзифа түтине, юлыннан бүлеп, үз яннарына дәште.

– Син Гуляның әнисе буласыңмы? – диде арадан берсе, Минзифа түтине баштанаяк күздән кичереп.

– Әйе.

– Үз әнисеме, иренекеме?

– Үз әнисе.

– Алайса, кил әле болайрак, – ул як-ягына карангалап алды. – Кызыңны монда калдырып кайтып китмә инде син, яме. Эт көнендә яши бит ул бала. Эчмәгәндә генә кеше төсле күренә ире. Ну авызына эләксә, юләргә әйләнә инде... Кайсы бер көнне Гуля ике баласын алып тәрәзәдән чыга. Машага – әнә бишенче подъездда яшәгән татар хатынына кереп куна. Әйе-әйе! Качып котыла алмаса, төне буе – тавыш. Калдырма аны монда, ул зверь янында калдырма...

Минзифа түти ни әйтергә дә белмәде. Сизенә иде ул, шикләнә иде, ләкин... Ятлар авызыннан мондый сүзләр бигрәк тә авыр ишетелә икән шул. Тик кызын ничек кенә бергә кайтып китәргә үгетләмәсен, Гөлфиясе үҗәтләнеп баш тартты.

– Ул барыбер безне тынычлыкта калдырмаячак, әни, – диде.

– Ә әтиең белән без сине яклый алмабызмыни? Апаң да бар бит әле, – дип каршы төшеп карады Минзифа түти.

– Саматны бер айдан Мәскәүгә командировкага җибәрергә тиешләр. Шунда иркенләп кайтырмын. Ә үзе монда вакытта безгә китәргә барыбер ирек бирмәячәк. Сиңа да кыен булыр. Бер айдан – туган көнемә кайтып җитәм, көтегез, яме.

Шулай дип вәгъдә биреп калган иде Гөлфия. Тик... бер ай була дигәндә кызының үлем хәбәре килде.

Ул чакларда... Ул чакларда күз яшьләре елга булып акты Минзифа түтинең. Үкенеч хисе йөрәген йөзгә, юк, меңгә телгәләде. Ник алып кайтмадым икән, никләр калдырдым икән, дип такмаклый-такмаклый елады. Эш урынында үлгән диделәр, бассейн җыештырганда ялгыш суга егылып төшкән. Самат аның кайтканын өендә көткән-көткән дә, эш урынына эзләп килгән икән. Килсә, бассейн янында чиләге, лентяйкасы тора, ә үзе юк икән. Ни уйларга да белмәде Минзифа түти. Түзә алмыйча үз гомерен үзе чикләде микән әллә дип тә уйлап карады. Ышанмады. Әмма исемен дә әйтә белмәгән ул медэкспертиза кебек нәмәрсәләр артыннан йөрергә акылы да, тәҗрибәсе дә, урысчасы да җитеп бетми иде Минзифа түтинең. Ә ире кайгысын, гадәттәгечә, аракы белән басты. Фәридәсенең яңа бәбидән котылган чагы иде, барын-югын сөйләп аны борчыйсы килмәде. Кыскасы, үлем-җитем документлары артыннан Самат үзе йөр-





де. Ул да бик бетеренгән, бөтенләй югалып калган кебек тоелды Минзифа түтигә.

– Балаларны үзебезгә алып кайтып китик, – диюгә, Самат шундук каршы төште.

– Юк, балаларны үзем карап үстерәм.

Шулай да беренче мәлләрдә балаларны аңа калдыра алмады әле Минзифа түти. Үзе белән авылга алып кайтты. Аларны карап юанды. Самат ярты елдан соң гына күренде. Ул, законлы опекун буларак, балаларны алып китәргә дип кайткан иде.

– Әби, бер дә борчылма, – дип сөйләнде Самат, күзләрен күтәреп карамый гына. – Эчүне ташладым. Завязал. Казанга кайтып эшкә урнаштым. Бер хатын белән кушылдык. Аның ике бүлмәле фатиры бар. Балаларны алып килүгә каршы түгел. Үзе бала таба торган түгел икән. Минем Гөлфиякәемә җитә торган хатын-кыз заты юк инде ул җир йөзендә. Ну бит... балаларга әни кирәк. Балалар хакына үземне кулга алам, әби. Хаталарым күп булды, бик күп булды, ну хәзер инде синең алда сүз бирәм.

Минзифа түти аның сүз биргәнен сүзсез генә тыңлады. Бер аңа, бер әтиләре янәшәсендә утырган сабыйларга карады. Балакайлар икесе ике яктан Саматка килеп сыенганнар иде. Шунда кинәт кенә үзенең балачагын исенә төшерде Минзифа түти.

Әтиләре ике балалы хатынын ташлап, күрше авылга йортка кергән иде аларның. Сугыштан соңгы ачлык еллар. Әниләре эштә. Үзәкләрне өзеп ашыйсы килә. Өйдә бернинди ризык юк. Менә шунда күрше авылдагы әтисен искә төшергән иде кечкенә Минзифа... Һәм иптәш кызын ияртеп шул авылга чыгып киткән иде. Әтисе аларны күреп сөенүдән битәр көенгәндер, үги әнисенең бөтенләй йөзләре кара көйгәндер. Ләкин ризыклы иде шул алар... Кызларны өстәл янына чакырып ашатканнары, ә әтисенең, озата чыккан булып, аның кесәсенә ярты телем икмәк тыкканы хәтердә. Менә шунда аңлаган иде кыз: аның әтисе бар! Алар янында яшәмәсә дә, эштән куян күчтәнәче алып кайтмаса да, усал малайлардан аркаламаса да, бар икән ләбаса ул. Күңел түрендәге бәләкәй генә өмет, соң чиктәге ышаныч иде бугай әтисе аның өчен...

Шулай итеп, оныкларын киявенә биреп җибәрергә туры килде Минзифа түтигә. Аның башка чарасы юк иде шикелле... Дөрес, башта үзара хәл белешеп тордылар. Беренче елларда каникулга балаларны кайтаргалады да әле Самат. Яңа әниләре рәхимле бәндә булды бугай, начар булса, бала-чага яшермәс, сөйләр иде. Саматның эчүне ташладым дию дә хак булды кебек. Болары башта... Аннары...

Әле Мөхәммәтханы исән вакыт иде, капкаларыннан Самат белән бергә эшләгән күрше рус авылы егете Сергей килеп керде. Керде дә, аптырашып торган картларны – башта Мөхәммәтханны, аннан Минзифа түтине кочаклап алды, өстәлгә күчтәнәчләр – кильки консервасы, ливерный колбаса, бер лимон, батончик, сап-сары мендәр конфетлары, тагын әлләниләр тезде... Сәгать унбер тулып килә, кибеткә ипи кайтыр вакыт җиткән иде – кунакны ире янында калдырып, Минзифа түти кибеткә китте. Анысын-монысын сөйләшә-сөйләшә, озак кына чират торып, ниһаять, үзләренә тиеш ике буханка ипине алып өйалдына кайтып керсә, кече яктан кычкырып-кычкырып сөйләшкәннәре ишетелә. Теге егет белән Мөхәммәтхан лыгыр-лыгыр килеп, эчеп утыралар икән бит! Аракысы да булган икән ул юньсезнең!

Ябылып бетмәгән ишектән исерекләрнең аерым сүзләре дә ишетелеп китә иде: Гөлфия турында сүз барганын аңышып, туктап калды Минзифа түти.

– Ты знаешь, дядя Миша, я никогда не смогу забыть глаза Гули. Ее взгляд тогда... Но он, Самат, не хотел, ей-богу, не хотел. Он нечаянно толкнул ее. Просто так получилось. Он же ревнивый, козел, баран этот е..! Понимаешь, дядя Миша, все это произошло у меня на глазах...

Сергей сүзен тәмамлый алмый калды – икенче мизгелдә ишектән атылып кергән Минзифа түти аны күлмәк изүеннән эләктереп алган иде инде. Күзе-башы тонган карчыкны күрүгә егет айнып китте. Шундук чыгып югалырга кирәген дә чамалады. Тик Минзифа түтинең кулыннан ычкынырга теләп талпынса да, булдыра алмады. Карчык аңа җан ачуы белән ябышкан иде. Инде өстәлдәге буш аракы шешәсен алып куркытыр өчен генә кизәнмәкче дә булган иде Сергей, әле ярый артыннан картлач килеп, зәһәрләнгән карчыгын аннан аерып алды. Картның аңын инде аракы сөреме каплаган иде, күрәсең, егетнең сүз сөрешен ул абайламый да калган булгандыр...

Минзифа түти атна-ун көн беркем белән сөйләшмәде.

– Әни, әйдә милициягә барыйк, Сергейның сүзләрен җиткерик, бу исерекбашлар гына башына җиткән икән бит, – дип үгетләп тә карады Фәридәсе.

Минзифа түти җавап бирмәде. Сизенгән кебек, Самат та шуннан соң күренмәде. Бәлки, Сергей аңа авылга кайтуын, салган баштан нинди хата җибәрүен сөйләгән булгандыр. Шулайдыр әле ул...

– Келт-келт-келт...

– Тек-тек-тек...

– Ничәдә кайтып җитәбез, диделәр?

– Икеләрдә юлга чыккан булсалар, Казаннан ике сәгатьлек юл инде, озакламаслар.

– Исән-сау гына йөрсеннәр, – диде Минзифа түти.


– Әллә көтепләр торасың инде? – Фәридә аңа гаҗәпләнеп карап куйды.

– Оныкларым бар бит, – дип җавап бирде әнисе.

– Ә Саматка берәр сүз әйтәсең килмиме соң, әни?

– Аллага тапшырдык инде, кызым...

Шулчак урамда машина тавышы ишетелде. Фәридәсе җәһәт кенә тәрәзәдән урамга күз ташлады, алар турына кызыл төстәге «Калина» килеп туктаган иде. Ул әнисенә монда гына калып торырга ымлады



Рәсем: Наталья Васильева

да, үзе кунакларны каршы алырга чыгып йөгерде. Хәер, Минзифа түти бик теләсә дә, бу юлы аңа иярә алмас иде. Кинәт кенә үзендә җиңелчә калтырану тойды ул. Моннан чыгып качасы килгәнен тойды! Тизрәк-тизрәк! Алар керeп җиткәнче арт як ишектән чыгарга да югалырга кирәк. Шулайга таба ике-өч адым атлады да бугай әле ул. Һәм туктады... Тып-тын калган өйдә сәгать тавышы гына ишетелә иде:

– Келт-келт-келт...

Берни булмагандай тыныч кына секундларны саный иде сәгать телләре:

– Тек-тек-тек...

Өйалды ишеге ачылды, сәгать тавышын инде тыштан кергән авазлар күмеп китте. Иң алдан чем-кара чәчле, кыйгач кара кашлы, нәкъ Гөлфиянең яшь чагын хәтерләткән үсмер кыз, аннан каратут йөзле буйчан малай килеп керде. Балалары артыннан ияргән Самат бусагадан кыяр-кыймас кына узды. Менә шушы мизгелне, сират күперен кичүгә тиңләп, юлда ук йөз кат күз алдыннан үткәреп, бизмәннәргә салып үлчәп, чишүе авыр мәсьәләгә тиңләп газаплаnып кайтты инде ул. Очрашуны төрлечә күз алдына китереп карады. Юк, Гөлфиясе белән кайткан чакларындагы кайту түгел инде бу! Якын итеп кочак җәеп каршыламаслар... Үз кеше булып түргә үтә алмас... Әллә кереп тормаскамы? Балаларны гына өй янында төшереп калдырырга да... Ни уйлаганын сизгәндәй, ярый ла хатыны беренче булып сәлам бирде. Тыйнак кына елмаеп, Фәридә белән ике куллап күреште: «Исәннәрмесез! Бер көе генә яшәп ятасызмы?» «Ару гына...» Монысы – Фәридә тавышы. «Әйбәт кенә кайтып җиттегезме? Әйдәгез, аш та пешкән, сезне генә көттек...» Фәриданең үзләрен каршылаганда гел әйтә торган сүзләрен кабат ишеткәч, балаларының апаларына сарылуын күргәч, кулындагы бейсболкасын бөтерә-бөтерә йомарлап бетергән Саматның тамагына төер тыгылды...

Ә Минзифа түти җавап кайтармады. Ул бу вакытта кухняда, «гүпчи хәтерсезлеге өчен» үзен әрли-әрли, духовкадан бәлеш алып йөри иде. Көн инде сүрелә төшкән, ә өй эченә кояшның кызгылт, йомшак-җылы нурлары тулган иде.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

*Соңгы вакытта зарланырга да, телефон, телевизор каршында утырырга да вакыт юк безнең. Төрле чаралар уздырып, күңелле вакыйгалар белән мәш килеп яшибез.* Ике ел элек «Бер скандинав таягы ал, икенчесен хакимият бирә», – дигән кызыклы акция узган иде. Шул көннән соң авылда скандинав таягы белән йөрүчеләр бермә-бер күбәйде. Бигрәк тә олы кешеләр күп йөри – сәламәтлекләрен кайгырта! «Сезнең авыл карчыклары мәчеткә дә скандинав таягы белән йөри икән», – ди башка авыллар гаҗәпләнеп. Әйе, кемнәндер, нәрсәдер көтеп тору мәгънәсезлек икәнен әйбәт аңлыйбыз, шуңа хасиятенә үзебез керештек менә. Лаеклы ялда булуларына карамастан, Рузалия Абдуллина һәм медицина хезмәткәре Миңнегөл Кашипова олылар өчен атнага ике тапкыр клубта махсус физик күнегүләр дәресе үткәрә. Тәннәр дә язылала, рәхәтләнеп сөйләшеп тә утырабыз, күңелле! Ә ир-егетләр бик яратып шугалакка итекле хоккей уйнарга йөри. Безнең Ядегәр авыл җирлегенә кергән дүрт авылның командалары үзара ярышлар да оештыра. Әле бу көннәрдә клубта бер-бер артлы концертлар уза. Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр, мәктәп укучылары һәм укытучылар... Атна саен җирлеккә кергән дүрт авыл үзешчәннәре концертлар куя. Күптән түгел генә яшьләрнең КВН уеннарын карадык. Соңгы елларда олысы-кечесенең спортка карашы уңай якка үзгәрде. Теннис, волейбол, шахмат, шашка, көрәш... Оныклар өчен бик шатланам инде мин, мондый яшәү рәвеше бигрәк тә яшь буын өчен үрнәк бит ул! Мөмкинлеге чикләнгән кешеләр дә читтә калмый, араларында төрле ярышларда җиңүләр яулап, Мәскәүгә кадәр барып җитүчеләр дә бар. Авылыбызның чын горурлыгы алар! Сездә ничектер, безнең якта кышы да булды, кары да яуды. Чөнки бездә чана, чаңгы шуучылар күп! Авыл җирлеге башлыгы Айдар Фәйзуллин икенче елга чана шуу бәйрәмен тагын да зуррак итеп уздырабыз әле, ди. Иганәчеләребез турында да әйтеп китәргә кирәктер. Алар ярдәме белән безнең авыл җирлегенә караган авыллардагы чишмәләрне карыйбыз, төзекләндерәбез – игелекле эшләр исәбе дә арта бара.

Менә шулай күңелле итеп, шау-гөр килеп яшәп ятыш. Ядегәргә кунакка килегез, үзегез күреп китәрсез!

*Вәсилә ӘСХӘДУЛЛИНА.*
*Ядегәр авылы, Кукмара районы.*

РЕДАКЦИЯДӘН: Ядегәр авылындагы мондый матур күренешләргә сокландык та, гаҗәпләндек тә. Ә сезнең авыл ничек яши, сездә нинди яңалыклар бар? Безгә дә языгыз!

*Хәләл җефетем белән очрашкан мизгелләрне, нарасыйларымның бу дөньяга аваз салуларын, тәпи атлап китүләрен искә төшереп утырдым да, бер генә вакыйганың да юкка гына булмаганына инандым.*

Ирем белән институтта таныштык. Башта мин аңа игътибар да итмәдем. Әмма күпмедер вакыт үткәч, кай ягы беләндер ул минем күңелемне яулады. Яратышып, гомергә бергә булырга сүз биреп, зур тормышка аяк бастык. Озакламый, беренче мәхәббәт җимешебез – кызыбыз Лира якты дөньяга аваз салды, аннары улыбыз Әмир туды. Шулай әкренләп кенә тормыш йомгагы сүтелә барды. Өченче балага узу теләге ничек кенә көчле булмасын, бу хыял гына булып кала бирде. Шулай да, мин өч бала әнисе булачагыма чын күңелемнән ышана идем...

Беркөнне кызымны мәктәптән каршы алдым да, үзем белән эшкә алып киттем. Урамда кызым миңа бик матур күбәләк күрсәтте. Кыш көне күбәләк күрү гаҗәп хәл иде, әлбәттә, бераз аптырап калдым. Без аны эшкә алып килдек, җылы бүлмәгә җибәрдек. Ә икенче юлы – туган көнемдә тәрәзәдән

Фото: www.pixabay.com

күбәләк очып кереп җилкәмә кунды. Мин серле күбәләкне өченче балам буласына юрадым. Күпләр мондый хәлләргә игътибар да бирмидер, ә менә мин һәрнәрсәне күңелем аша үткәрәм шул.

Без Алабуга шәһәрендә яшибез. 2016 елның җәендә Мамадыш районында яшәгән туганнарыбызга, Урта Шүләңгер авылы зиратындагы әбием һәм бабамның каберләрен тәртипкә китерергә дип кайттык. Ел саен июнь аенда шулай өмә үткәрәбез. Чистартып, чардуганнарын буяганнан соң, чишмә буена юынырга төшеп киттек.

Язмыш шулай хәл иткән булгандыр инде, шунда мине нәрсәдер тешләгәнен сизеп алдым. Башта игътибар бирмәсәм дә, берничә минуттан аңым томалана башлады, аннары инде нәрсә булганын хәтерләмим дә... Мине елан чаккан булып чыкты. Хастаханә шактый ерак булганлыктан, мине анда бик авыр хәлдә китереп җиткергәннәр. Биш кенә минут соңга калынган булса да, ахыры бик аяныч тәмамланган булыр иде. Могҗиза белән генә исән калдым. Ирем бүген дә бу көнне дулкынлану белән искә төшерә.

Күп дәваланулар узарга туры килде, бер айга якын йөри алмадым. Бу вакытта миңа якыннарым ярдәм итеп торды. Әлбәттә, авыр вакытта гына кемнең нинди кеше икәнлеген аңлыйсың. Ходай тарафыннан җибәрелгән сынаулар кешеләрнең сиңа булган мөнәсәбәтен, кемнең кем икәнлеген аңларга мөмкинлек бирә. Эч серләреңне уртаклашкан якыннар югала, синең артта әллә нинди сүзләр куерта, ә бөтенләй чит кешеләр яныңнан да китми, ярдәмгә әзер тора. Гаиләдә өч кыз туган үссәк тә, иң якыны кечкенә сеңлем Розалина. Киңәшеннән, акыллы уй-фикерләреннән, ярдәменнән ташламый ул мине. Реанимациядә ятканда да һәр көн диярлек янымда булды.

Хастаханәдән кайтып озак та узмады, үземне бик начар хис итә башладым: ашый алмадым, ябыктым. Бик нык борчылдым, миндә яман шешләр дигән шикләр туды. Тагын хастаханә юлларын таптый башладым. Табиблар бар да яхшы диләр, ә мин куркам... Шулай да, бер табиб киңәшенә колак салып, балага узу-узмавымны тикшереп карадым. Әйе... Үземнең авырлы икәнемне белдем. Кинәт бер чиләк салкын су сиптеләрмени! Әлбәттә, табиблар бала табарга киңәш итмәде, чөнки елан чагып, хастаханәдә ятып чыкканнан соң вакыт бик аз узган иде. Әмма ул бит Ходай бүләге, карынымда тагын бер җан ярала. Бу бәхет түгелмени?! Иребез белән икебез өчен дә зур сөенеч иде!

Йөклелек бик авыр узды. Казаннан кайтканда көтмәгәндә тулгагым башланды. Мине Чаллыга китерделәр, күтәреп алып керделәр, менә ак халатлы шәфкать туташлары... Улым Айнур җитлекмичә, сигез айлык булып туды. Иң зур куаныч: ул саусәламәт иде!

Бүген дөньябыз түгәрәк, Аллаһка шөкер. Журналга язуымның төп сәбәбе – «Объективта – әни» бәйгесендә катнашып, җиңү яулавым. Кечкенәдән үк зур хыялым бар иде – «Сөембикә» журналы редакциясе белән очрашу. Һәм ул тормышка ашты! Әбием кечкенәдән үк миндә «Сөембикә» журналына карата мәхәббәт уятты, 11 оныгы арасыннан ул мине аеруча нык яратты. Бәлки, татарча сөйләшә белүем йогынты ясагандыр. Сезнең журнал битләрендәге язмаларны укыйм, һәр санын көтеп алам, берсен дә югалтмыйча саклыйм.

Хыяллар кайчан булса да чынга аша икән. Тормышымдагы якты мизгелләргә, Ходайның биргән һәр көненә, сынауларына, шатлык-куанычларына, шушы җир йөзендә яшәгәнем өчен чиксез рәхмәтлемен.

*Лилия КАШАПОВА.*
*Алабуга.*

## *Интернет заманында,*
### *төрле яклап мәгълүмат килеп торган заманда яшәсәк тә, авылдагы китап кибетләре сагындыра...*

Апас элек-электән китапны үз күреп яшәгән. «Таткниготорг» кибетенең 1930 елда ук ачылганлыгы мәгълүм. Мин үзем дә нәни чагымнан ук китап белән тылсымланып үстем. Матур хыялларга бирелә-бирелә базар янындагы кибеттән китаплар алырга йөрүем бүгенгедәй күз алдымда. Соңрак китап кибете үзәккәрәк күчеп, район кешеләре һәм читтән татар китабын сагынып кайтучылар өчен тагын да мулрак рухи азык чыганагына әйләнде. Берара, китапка ихтыяҗ бик нык үсеш алган заманда, яңа китаплар кайтуның икенче көнендә кибет ачылганны чиратка тезелеп көтеп тора идек бит! Кайсы авторның яңа китабы чыккан, анысын да белеп тора идек! Заманалар үзгәрде. Китап кибетләре күптән ябылды инде.

Базарда китап-дәфтәр сатучы киосклар эшләп ала алуын, әмма андагы китаплар фәкать рус телендә генә, өстәвенә, бәяләре дә «тешли» торган. Ә бит татарча китаплар аз нәшер ителми, бәяләре дә кесәгә суга торган түгел. Әмма алар, игътибар һәм кызыксыну күрсәтүче булмаганлыктан, район үзәкләренә килеп җитә алмый. Казанның китап кибетләрендә татар китаплары тулып ята, алучылары да ябырылып тормый, ә авыл халкы татар китабына сусаган! Китап кирәк булган саен Казанга килеп буламыни?! Мәшәкате – бер хәл, юл чыгымнары да бар бит әле...

...Һәр көн диярлек элеккеге китап кибетләре яныннан узам. Китап сатучы апаларны искә төшереп сагышланып алам. Китап кибетләрен, китап исен үлеп сагынам!

*Миләүшә ВӘЛИУЛЛИНА.*
*Апас районы.*

***Хөрмәтле укучыларыбыз!***
***Сездән хатлар көтеп калабыз.***
***Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.***
***e-mail: ssuum@yandex.ru***

PRESSA



# СӨТ ӘНИСЕ

Ул елны март буранлы килә. Унысыннан башланган күз ачкысыз буран атна буе тынмый. Районга түгел, күрше авылга бару да олы бер мәшәкатькә әйләнә. Розаның тулгагы сайлау көнне көтмәгәндә башлана. Әле җиденче ае гына киткән була. Аның игезәк балалар көткәнен беркем дә белми. Карынында сабыйлары тибенә башлагач, үзе тотып карый-карый аңлый ул анда ике җан барлыгын. Игезәкләр шулай ашыга микән? Берсеннән-берсе кечкенә ике сабыен калдырырга өйдә кайнанасы да юк. Җитмәсә, каенсеңлесен кечкенә баласы белән «бәби кунагы»на алып китерткән иде, Исламы сайлау комиссиясендә утыра... Игезәкләрен өйдә таба ул. Таба һәм... берсен югалта... Тик Тәтеш районы Олы Әтрәч авылында яшәүче Роза апа Фәйзуллина тормышындагы югалту-табуларның соңгысы булмый әле бу.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Бик авырдан таба ул сабыйларын. Кендек әбисе – авыл фельдшеры бәбиләрне ак биләүгә били дә: «Җитлекми туганнарга җылы кирәк. Мин килгәнче тимәгез», – дип, мич башына куя да кайтып китә. Роза хәл эчендә була. Әле каядыр оча ул, әле балаларының елаган тавышын ишетә. Яшь ананың күзен ачарга да хәле юк. Бик тә кочагына аласы килә дә соң... Игезәкләр бит алар! Җитмәсә, күкрәген авырттырып сөт төшә башлый. Рәхәтләндереп имезәсе иде сабыйларын... Юк, ул бит яшь-яшь кыз. 14 яшьлек үсмер кыз тавык фермасына эшкә килә... Менә аңа инде – 18... Әнә, фермада кызлар белән җырлый-җырлый сыер сава. Эшләрен төгәллиләр дә йөгерешеп болынга төшеп китәләр, җырлый-җырлый җиләк җыялар... Чү! Җыр тавышы түгел, бала елый лабаса... Сабыйлары елый! Ник алып килмиләр соң аларны янына?.. Төнне шулай саташып чыга ул.

Ә иртән... иртән игезәкләренең берсе үлүен әйтәләр. Бер тапкыр да күкрәгенә куя алмаган кечкенә улын әнә шулай җир куенына сала ана. Бала хәсрәтеннән дә авыррак кайгы юк – хәле тагын да начарлана. Игезәк сыңары – кызы Гөлнур да һаман мантып китә алмый. Дүрт көннән соң аларны юрганнарга төреп, ат чанасына салып, район больницасына алып китәләр. Роза юл буе баласының исән калуын теләп бара: «Берсен алдың, инде монысын калдыр», – дип елый яшь ана... Больницада аны – изоляторга, баланы җитлекми туган сабыйлар янына салалар. Ике көннән палатага өлкән яшьтәге акушер кереп, хәлсез яткан анага кызын мактый башлый: «Үсәргә әрсезләнә ул синең. Әле менә ике кечкенә шешә сөтне суырып бетерде». Ана өчен моннан да яхшы дару бар микән?! Акушер сүзләре аңа канатлар куйгандай итә. Сөенеченнән күз яшьләре бәреп чыга. Шул көннән соң үзенең дә хәле җиңеләя башлый.

Кызын имезгәндә колагына гел бер бала елавы керә аның. Бөтен бала да әнисе куенында лабаса, ә нигә аны әнисе имезми икән? Икенче көнне елаган нарасыйны кемнең сөте кала, шуңа имезергә биргәннәрен күрә ул. Бала имезүдән дә татлы нәрсә юк бит. Их, Илнуры да исән булса, икесен ике күкрәгенә куеп, рәхәт бер дулкында оеп утырыр иде. Сөте җитәрлек: Гөлнурын имезеп йоклаткач та сулык-сулык килеп сөт төшкәнен тоя ул.

Икенче көнне теге нарасыйны Розага имезергә китерәләр. Әй сөенә, әй шатлана яшь ана. Күзләреннән яшь бөртекләре мөлдерәп чыга. Бит уртасында миңе булган бик сөйкемле бала икән... Илнуры кире кайткан кебек тоела. Рәхәтләнеп сыйпап-назлап имезә. Шул көннән башлап башка хатыннарга бирми дә ул аны. Ашата, карый, су коендыра... Бик ярата ул баланы. Әнисе кем икән, бала тәрбияләрлек кеше булмаса, үземә алыр идем дип хыяллана. Исламы да каршы килмәс, мөгаен. Ислам...

## Бер тапкыр да сөя алмаган улын җир куенына сала ана.

...Розаның абыйсы армиядән кайткач, колхозда шофер булып эшли башлый. Казаннан өр-яңа йөк машинасы алып кайта. Озак та үтми, акыллы, тәртипле егетне парторг итеп сайлыйлар. Машинасын күрше авыл егетенә бирәләр... Эштән кайтып чәйләп алгач, Роза, гадәттәгечә, чигү эшенә утыра. Берзаман өйләренә елмаеп-көлеп бер егет килеп керә. Хром итекләр кигән, матур итеп киенгән. Хәл-әхвәл сорашкач, абыйсы машинасының хәзерге хуҗасы икәнен әйтә. Запчастька килгән икән. «Үскәнем, карап кына алыймчы шуны», – дип, ап-ак тешләрен күрсәтеп елмая. Ризалык алгач, тимер-томыр арасында актарына да, кирәген алып, рәхмәтен әйтеп чыгып китә. Эх, шундый егетең булса икән ул! Уйларыннан оялып, ике бите ут янган Роза кабат кул эшенә керешә.

Күрәсең, егетнең дә җиләк кебек кызга күзе төшә. Әлеге очрашудан соң авылларына гел килә башлый. Розалар өе янынарак туктый да, аның клубтан кайтуын көтә. Иптәш кызларыннан аерып алып калмакчы, сөйләшмәкче була. Җитез кыз егет кулыннан ычкына да, йөгереп кереп китә. Үзеннән алты яшькә зуррак егеттән бик ояла ул, олысытып карый. Клубка да килә, тик Роза чыга да йөгерә. Артыннан үкчәсенә бастырып егет машинасында куа. Шулай куышып-чабышып йөргәннән соң, сөйләшеп китәләр.

Өч еллап очрашканнан соң, Ислам өйләнешү турында сүз башлый. Роза ризалык бирми. Әниләрне ничек калдырып китәрмен дип тә уйлый. Аннан яшерен хыялы да бар бит әле: читкә китеп белем алып булмасмы? Күрәсең, барысын да мәхәббәт үзе хәл итә. Аллага тапшырып, Роза тәвәккәлли. Ул вакытларда ак күлмәкләр киеп кияүгә чыгу юк бит әле. Ислам аны төнлә клубтан алып китәргә тиеш була. Гореф-гадәте шулай. Кыз ризалыгын алгач, егет аны урлап алып кайта. Кече Әтрәч яшьләре Розаны Олы Әтрәч егете урлыйсын сизгәннәр бит. Югыйсә танытмыйм дип, иптәш егете белән башка машинада да килә Ислам. Ә монда – әнә нинди каршылыклар! Кыз утырган машинаның юлын кисәр өчен авыл башына берәүнең мунчасын сүтеп өйгәннәр. Яшьләр, машинадан төшә дә, җитәкләшеп, авылның икенче башына юнәлә. Имеш, урлый алмады, кызны озатып куя Ислам. Тик өйләрен узып киткәч, урам очыннан кырга чыгып, күрше авылга җәяүләп атларга ниятлиләр. Ноябрь ае. Җиргә яңа гына ап-ак кар яткан. Яп-якты ай нуры юл сала кебек. Берзаман бер төркем яшьләрнең артларыннан чапканын күрәләр. Ферма янындагы артезиан коесы башнясына менеп күзәткән икән егетләр. Янәсе, күрше авылга кыз бирмиләр. Ислам, минем көчтәнәчем

Фото: Анна Арахамия

PRESSA



## Язмыш аларны 40 елдан соң гына очраштыра.



Бер-берсенә терәк булып, яратышып яшәгәннәр өчен 56 ел гомер бөтенләй аз ул...

бар иде бит, дигәч кенә, яшьләр күнә тагын. Ике авыл арасында көтеп торган машинага утырып егет өенә кайталар. Ә анда булачак кайнанасы Розаның аяк астына ап-ак мендәрләр салып каршы ала. Яратышып кавышканнарны сөендереп, бер бер артлы уллары Илһам белән Исхак туа. Аннан менә Роза игезәкләр алып кайта. Тик сыңарына гына яшәү насыйп булмый. Әллә үлгән баласын алыштырыр дип, Роза караучысыз яткан балага шулкадәр нык тартыла. Бирсәләр, Исламы белән бик әйбәтләп тәрбияләрләр иде...

Беркөнне Роза яткан палатага гөлдер-гөлдер килеп бер яшь хатын керә. Түгәрәк йөзле, кара кашлы, кара күзле Зөлфирә исемле бу мөлаем хатын Роза имезгән баланың әнисе булып чыга. Аны күрү белән бөтен хыялы чәлпәрәмә килә. Зөлфирәгә куна калырга рөхсәт бирәләр. Йокы булмый инде ул, төне буе серләшеп чыгалар. Рафис (балага шулай дип исем кушканнар) Зөлфирәнең икенче баласы икән. «Больницада озак ята алмыйм, өйдә авыру кызымны карарга кеше юк», – дип елагач, табиблар Зөлфирәне өенә кайтарып җибәргән. Җитлекми туган баласы авырлыгын җыйгач, дәшәрбез дип калалар. Һәм менә ана бала артыннан килгән. Әнкәсе бик әйбәт икән, дип, бөтен йөрәге белән тынычланып, Роза аларны озатып кала.

Әмма бала аның яныннан китсә дә, җаныннан китми... Өйгә кайткач, Исламына да сөйли. Гөлнур тәпи киткәч тә, сөйләшә башлагач та, Рафис та үскәндер инде, дип, һәрвакыт искә алып яши. Сабыен югалтуына җаны әрнегәнен Аллаһы Тәгалә дә күргәндер: игезәк уллары – Алмаз белән Айрат дөньяга килә. Алардан соң Гөлназ, Инсаф туа.

Тормыш әнә шундый күңелле мәшәкатьләр белән уза. Лаеклы ялга чыккач, тынгы белми торган Роза апа авылда мөслимәләр оешмасы төзи. «Буран әбиләре» популярлашкан чаклар бу. Алардан кимме әллә без, дип, «Кызыл миләш» җыр ансамбле төзергә ниятлиләр. Роза апа «Кызыл миләш» дигән шигырь язып, аны үзе көйгә сала. Сәхнәгә чыгар өчен пардан күлмәкләр тектерәләр. Алъяпкыч булса, тагын да күркәмрәк булыр иде дип уйлыйлар. Беркөнне әзерләп куйган үлемтегенә күзе төшә Роза апаның. «Әле үләргә кем җыенган?!» – дип уйлый да, шул тукымадан алъяпкыч тектерә. Аларга аллы-гөлле чәчәкләр дә чиксәң... Тик вакыты тар. Тукта... акка роза чәчәкләре төшкән матур күлмәге бар бит! Төнлә уйлап ятканнан соң, сикереп тора да күлмәктәге чәчәкләрне саный башлый. Җитә! Бер күлмәкне җил дә очыра, дип, алъяпкычларга роза чәчәкләрен кисеп тегәләр. Әнә шулай күңелле яшәп яталар.

«Кызыл миләш» төркемен «Җырлыйк әле» тапшыруына чакыралар. Тәтеш мәктәбенә барып тыңлаулар узарга кирәк икән. Чыгыш ясаганнан соң, җыелышып, соңгы сүзне көтеп утыралар. Шул вакыт берәү әкрен генә Роза апаның аркасына килеп кагыла. Борылып караса – бит уртасында миңе булган ир-ат елмаеп тора. Яшен суккан кебек чайкалып китә. Ул бит бу! Улы! «Сез Роза апа түгелме? Мин – Рафис...» Кочаклашып, елашып күрешәләр. 40 елдан артык вакыт узган югыйсә, ә кичә генә кебек. Роза апасы турында әнисе сөйләгән булган Рафиска. Рафисның үзенең туган авылында мәдәният йорты җитәкчесе булып эшләгәнен Роза апа да белеп яши. Ә бу күрешүдән соң, 70 чакрымлы ике авыл арасы якыная да куя. Телефон аша һәрвакыт сөйләшеп торалар.

Икенче әнисен Рафис юбилеена да чакыра. Мәҗлес вакытында, минем ике әнием бар дип, урталарына басып өздереп җырлый. Ярты гасырдан соң Роза апа Зөлфирә ападан кабат рәхмәт сүзләре ишетә: «Минем сөтем кермәде, синең сөтең белән шундый изге җанлы ул, бар яхшылыклары синнән күчкән», – ди. Бәлки, җырга мәхәббәте дә күчкәндер. Әнә ничек оста җырлый бит Рафис.

Аны үзенең 75 яшьлек юбилеена чакыра Роза апа. Кабат очрашалар. Исламы, балалары белән таныштыра. Икенче әнисенең иңнәренә ап-ак яулык яба Рафис. «Бик тәрбияле, ягымлы бала ул», – дип сөйли аның хакында Роза апа. Бу мизгелдә күзләрендәге яратуны күрсәгез икән...

– Мин бит ул баланы, үскәч, мине хөрмәтләр әле дип имезмәдем. Кылган изгелегең әйләнеп кайта икән ул... Рафисны миңа Аллаһы Тәгалә Илнур урынына биргәндер дип уйлыйм. Читтә булса да, йөрәгемдә бит ул... Алтынчы улым...

75 ПОБЕДА! 1945–2020

**Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без – балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә. Ләкин без барысына түздек...**

# СЕЗГӘ КҮРЕРГӘ ЯЗМАСЫН!



Миңа чаклы әнкәй дүрт бала тапкан, ләкин алар тугач та үлә барган. Шуңа күрә әткәй белән әнкәйнең бик кадерле беренче баласы булганмын. Миннән соң энем Гыйльфан һәм сеңлем Фәһимә туган. Әткәй үзе – Торнаташ авылыннан, Мөсәвәрә әбием белән әни янына йортка кергән ул. Әтинең туганы Дөрли апа сугыш чыгар алдыннан вербовка белән Мәскәүгә эшкә җибәрелгән иде. Берничә ай эшләгәч, ул әткәйне дә үз янына чакыртып алды. Әткәйнең безгә посылкалар салганы әле дә балачагымның матур хатирәсе булып саклана. Эшләгән җирендә: «Фатир бирербез, гаиләңне алып килерсең», – дигәннәр. (Татарларның эшчән булуын бөтен җирдә дә тиз күреп алганнар шул!) Ләкин безгә Мәскәүгә китеп яшәргә язмады: сугыш чыгып, немецлар башкалага якынлаша башлагач, алар янә авылга әйләнеп кайтты.

Яше зур дип, әткәйне сугышка алмаганнар иде башта. Ул Чаллы элеваторына эшкә урнашты. Әйбәт кенә эшләп йөргән җиреннән гаиләбезгә зур кайгы килде – икмәк илтеп кайтканда, арыган атларын ял иттереп артта калган, иптәшләреннән бер сәгатькә соңарган өчен әткәйне суд карары белән ике елга төрмәгә утырттылар. Сугыш чоры законнары кырыс иде шул... Әмма озак тотмадылар, фронтка җибәрделәр. Ул китүгә үк сыерыбыз үлде. Болай да хәерчелек көчле чак, сыер – ачлыктан бердәнбер коткаручыбыз иде, аннан да колак кактык. Әнигә өч бала, сукыр әбиебез белән көн итү бик авыр иде: икешәр көн буе авызга бернәрсә капмаган чакларыбыз да булды.

Басуда ашлык суккан җирләрдә башаклар калып, язга чыккач шуларны суырып, ярмалык бодай чүпләре алып кайта идек. Шуннан шулпа кайнатабыз. Черегән бәрәңгеләрне казып алып, аларны төеп, көлчә пешерәбез. Ягарга юк, кура җыеп, шуны җилкәгә күтәреп алып кайтабыз, өй түбәсенең кәрнизләрен, капка-коймаларны кубарып ягып, өй җылытабыз.

Ир-атлар сугышка китеп беткәч, тракторда эшләү хатын-кызлар җилкәсенә калды. Хөббенисәттәй, Саймә апа, Һаҗәр апа, Мөнәзҗәһә апа, Фәхерлегаләмтәй, Мөдәрисә кебек уңган хатыннар кабинасыз, тәгәрмәчле «Нати»лар белән салкында да, яңгыр явып торганда да, эссе чилләдә дә эшләделәр. Безне шуларга плугарь итеп җибәрәләр иде.

МТСтан тракторлар бирелә башлагач, молотилкалар белән ашлык сукттырдылар. Мин көне буена олы әрҗәгә җыйналган ашлыкны бер урынга илтеп өям. Маһирәвәнттәй, Сорурттәй, Фатыйхәттәйләр кебек ударник булыр өчен тырышам. Көлтә бәйләү эше аеруча кыен иде.

1944 елда авылыбызга зур афәт килде – кырда кышлаган бодай агулы булган, шуннан ипи пешергән халык агуланып кырыла башлады: көненә өч-дүрт кеше үлә, кабер казып җитешә алмыйлар, бер кабергә икешәр-өчәр мәетне салган очраклар да булды. Чират безгә дә килеп җитте... Гыйльфанның авыз-борынынннан кан китеп, хастаханәгә илттек. Шуннан энем үз аягы белән чыкмады инде. Аны җирләп кайткан көнне әнкәй чирләп егылды һәм унбиш көн эчендә ул да гүр иясе булды. Кәфенлек ситсы да юк, иске паласка төреп озаттылар аны. Әбиебез дә үлеп киткән иде инде. Шулай итеп, мин – 13, Фәһимә 4 яшендә ятим калдык. Безнең кебек ятим балаларны Шыгай балалар йортына илттеләр. Аннары мине – Иске Абдул, Фәһимәне Теләнче Тамак Балалар йортына күчерделәр.

Әтиебез Җиңү көненнән соң ук кайта алмады, Суслонгерда тотканнар икән. Дошманны илдән куып чыгаргач, сугыш узган җирләрдә трофейлар җыйдыртканнар. Ә ул кайткан көн иң бәхетле, якты көн булып хәтеремдә сакланган. Сеңлем белән икебезгә дә пальто, күлмәк ише киемсалым алып кайткан иде. Ак самавыр һәм хуҗалык өчен башка кирәкле вак-төяк әйберләр дә ярады: самавырны – бозауга, бутәннәрен бәрәңгегә алыштырдык.

Бишенче сыйныфта укыган вакытта мәктәпне ташлап кайткан җирдән укуымны дәвам итә алмадым. Юкса мәктәптә «дүртле-бишле»гә генә укыган идем. 12-13 яшемнән олылар белән бергә җиң сызганып колхозда эшләргә туры килде.

Әткәй, чит хатын балаларыма ана була алмый дип, өйләнмичә гомер итте, 63 яшендә дөнья куйды. Димчеләр миңа да күп килде, әмма сеңлем Фәймәне кияүгә озатып, ялгызым калгач, өемне ташлап китәргә теләмәдем. Шулай язгандыр инде... Үз тормышымны үзем алып бардым, эштән башканы белмәдем, тырыш идем. Хәзер Фәймәнең балалары, оныклары яныма килеп тора, ярдәмнәреннән ташламыйлар. Кайчан, нинди үтенечем бар, булышырга һәрвакыт әзерләр. Кызы Нәзирәне үзем үстердем, киявебез Зөлфәт тә – бик акыллы, булдыклы кеше. Алар гаиләләре белән Иске Абдулда, ә улы Илдар Чаллыда яши.

Нәзилә МОГЫЙНОВА.
Тукай районы Мерәс авылы.



# «ЙӨРӘККӘ МӘКЕР КЕРМӘСЕН»



Вахит ИМАМОВ,
язучы, Г. Тукай
премиясе лауреаты;
гаилә стажы – 42 ел;
ике бала атасы.

**Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...**
**Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.**

**1 Иң элек хатын-кызның сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...**

– Ир-ат, гадәттә, боларның бөтенесен дә күрә... Кадыйр Сибгатуллин бер шигырендә «тормышта ике мәхәббәтем бар: берсе – чыны, икенчесе идеалы» дигән иде. Идеал бөтен кешедә дә бардыр. Әмма тормыш хыялдан күпкә аерыла... Башта, яшьрәк чакта, безгә хатын-кызның йөз матурлыгы күбрәк кирәк. Чибәрлеккә алданасың... Аннары үзгәрәсең, юк, хатын-кызның акылы да кирәк икән дисең.

**2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?**

– Минем хатында хәйләкәрлек җитеп бетмәде дип саныйм. Гаиләдә акча чутлы булырга һәм аның исәбен хатын-кыз алып барырга тиеш. Мин үзем, кайтарып, өстәл тартмасына гына салучы... Хатын-кыз кара көн турында уйларга, шул акчадан ай саен аз-аз алып, мая җыярга тиеш. Иренә белгертеп тормыйча гына. Зуррак әйбер алганда кирәк ул. Бурычка, кредитка батмас өчен.

**3 Ә нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?**

– Хыянәт өчен! Беркайчан да! Мин аңлыйм, ир-ат сулга йөреп ала инде ул. Моны хәтта минем хатын да аңлый. Йөргән хәбәр барыбер ишетелә, ул кайтканда ук маңгайга язылып кайта, күзгә язылa... «Минем Вахит та йөрмәсә, тагын кем йөрсен?!» – дигәне булды аның... Балык Бистәсендә 84 яшьлек Степан Петровичта фатирда тордым. Карчыгы үлгән, ялгызы яши иде. Кышкы Сарайда хезмәт иткән, Керенский, Троцкий, Ленин белән кул биреп күрешкән. «Чүмечне инешкә куеп, агым буенча агызып җибәрсәң, борылып-борылып акканда, ул әкренләп су җыя һәм батмыйча калмый, – дигән иде ул миңа. – Хатын-кыз да шулай: гөнаһысы күп җыела икән, су төбенә китә».
Мин аңлыйм: хатын-кыз да мәхәббәт кичерергә мөмкин. Яки башка очрак. Баласын төрмәдән коткару өчен әллә кемнәрнең түшәгенә ятучыларны беләм. Тормышның үз законы. Ул син уйлаганча бармый – тәкъдир усалрак. Хатын-кыз иргә үч итәм дип андый адымга барырга тиеш түгел ул. Йөрәгенә мәкер керсә, хис тә, мәхәббәт тә үлә.

**4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?**

– Аның икесе дә якын. Эш кабинетым бик озак булмады. Аның миңа никадәр кирәк икәнен өйдәгеләр 50 яшем тулганда гына аңлады. «Сәет батыр»ны язганда, залдан телевизорны чыгардым, бөтен архивны таратып ташладым. Дүрт ай буе залга берсе дә керә алмады... Шуннан соң миңа дүрт бүлмәнең берсен бушаттылар. Ә алиһәгә килгәндә... Хатын туйдырмаска тиеш ул. Азрак киемен алыштырса, азрак чибәрләнеп йөрсә, ир-атка шул җитә.

**5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?**

– Әйе! Синең авыр хәлгә калган көннәрең була. Кайбер нәрсәләрне хәтта туганыңа да сөйли алмыйсың, сөйләргә тиеш тә түгел... Ә хатынга бар да сыя... Глүзә гел ераккарак карый белде. Балык Бистәсеннән мине ул алып китте. Дус кызы Чаллыда аңа эш тәкъдим итте. Ул чыгып китмәсә, кузгала алмас идем әле. Казанга күчкәндә дә шулай булды. Иҗатым өчен, әлбәттә, Казан кирәк иде миңа. Ул шуны яхшырак аңлады.

**6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме әле?**

– Без икебез дә бер мәктәптә, күрше классларда укыдык. Бер спектакльләрдә уйнап, җырлап йөрсәк тә, аңа гашыйк булырга өлгермәдем. Чибәрлеген күрә идем, ләкин беренче мәхәббәтем белән мавыккан чак... Аттестаттагы бер хаталы язу өчен беренче елны укырга керә алмадым. Кайтып, тиз генә РОНОдан белешмә алып кил диделәр дә... Актаныштан Казанга пароход белән киләбез ул чакта, әни 100 сум акча белән чыгарып җибәрде: адым саен район белән шәһәр арасын урый алмыйсың. Заводка эшкә урнаштым. Ә үзем студент классташларым янынннан кайтып кермим – җан тарта. Алар белән аралашу, танцыга төшү, китапханәгә бару миңа рәхәт. Җомга кич китәм алар янына тулай торакка, дүшәмбе иртән эшкә генә кайтам. Химфакта укучы классташым Фәнис берсендә киногa чакырды. Киттек. Тик ул вакытын бутаган, ике сәгать алданрак килгәнбез. «Мин җәй көне студентларның төзе-

леш отрядына командир булып барам. Шәфкать туташы итеп мединститутта укучы бер кызны чакырган идем. Кереп, документларын алып чыгыйк әле», – ди. «Әйдә соң», – дим. Ул кыз әле дәресләрдән кайтмаган икән. «Классташ Глүзә янына керик алайса», – ди Фәнис.

Тәрәзә төбенә менеп баскан – кышка тәрәзә җылыталар болар. Күрдем дә авызымны ачып калдым... Минем белән мәктәптә спектакль уйнап йөргән Глүзә түгел инде бу! Институтның җыелма командасына алганнар, спорт мастерына кандидат. Андагы буй-сын! Фәнис ул көнне: «Киногa икәү генә барыгыз», – дип, билетларны безгә калдырды. Әбсәләмова белән йөреп киттек шулай... Мин армиядән кайтканда, ул институтны тәмамлап, Воронежга эшкә киткән иде. «Миңа чыгасыңмы?» – дип сорап торулар булмады. Болай да билгеле иде бит...

**7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар.**

– Мин алардан көнләшмим... Андый гаиләләрдәге иратлар, гадәттә, күзгә-башка чалынмый. Тавыш-тыннары чыкмый. Анда нидер әйтү хокукы – хатын-кызда гына. Мин белгәннәрнең күбесе шундый... Байлыкны туплап бетерә алмыйсың. Ул хатыннар аналык хисен баласына да күчерергә тиеш бит әле. Үзе белән янәшә бастырып, аны аш-су пешерергә өйрәтергә тиеш. «Кәбестә бөккәнен менә шулай ясыйлар аны», – диярга. Ә алар иртәнге сигездән төнге унбергә кадәр эштә. Шуннан тәм табып яшәүчеләр бар... Глүзә дә мэриядә бүлек начальнигы булып байтак еллар эшләде. Кайтып тавыш күтәргәнен белмим. Беренчедән, мин буйсына торган кеше түгел. Икенчедән, дәүләт иерархиясендә пүчтәк кеше булсам да, җәмгыятьтәге урыным саллы: Чаллы Язучылар берлеге рәисе, «Мәйдан» журналы редакторы. Татарча чыгыш ясарга кирәк булганда, шәһәр башлыклары үзләре миңа эндәшә иде. 20 шәр мең халык каршында нотык сөйләгән чаклар булды.

**8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?**

– Хәтта кирәк дип саныйм! Туксанынчы елларда Чаллы «Энергетиклар» мәдәният сараенда «Пар канатлар» дигән кичәләр үткәрә идек. Бер матур мисал эзләп табабыз, шуны сәхнәгә чыгарабыз. Бер шундый пар таптык. Бер кыз Чаллы үзешчәннәр театрында уйнаучы егеткә гашыйк була. Тик моны ничек белгертергә? «Мин дә сәхнәдә уйнарга телим», – дип, коллективка килеп кушыла. Башта кечкенә генә роль бирәләр, аннан – зурракны. Сәхнәдә теге егет аның битеннән үбәргә тиеш була. Уйныйлар бу күренешне. Ә пәрдә артына чыккач, кыз аны үзе үбеп ала. Шуннан аңлашалар. Ул төшеп калган кыз түгел иде, сәхнәдә уйнау, бәлки, яшерен бер күңел халәте дә булгандыр. Әмма барыбер... Күктә язылып куелган икән, бу якынаюны кемдер башларга тиеш.

**9 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**

– Хатын бервакыт: «Балаларны Мәскәүдә укытабыз», – дия башлады. Хыяллану әйбәт анысы, тик... Шул елны архивка баруны сылтау итеп Мәскәүгә киттем, җай табып, Мәскәү дәүләт университетын да урап килергә булдым. Ремонт бара, төп ишек ябык икән – арырак уздым. Мине бер ир-ат куып тотты. Сөйләшеп киттек. «Кыз мәктәпне тәмамлый, юрфакка разведкага кыләм әле», – дим. Абитуриентларга белешмәләрне кайдан аласын күрсәтте, сораулар калса, миңа керегез, ди. Чакырды бит, янына меним дип ул әйткән кабинет янына килеп бассам – юрфакның деканы дип язылган! Ул арада ишек ачылды... 45 минут сөйләшеп утырдык. Мондый очрак тормышта бер генә була! «Ачыктан-ачык әйтәм, – диде ул. – Мондагы фатир, яшәү хакларын үзең чамалыйсың. Ярый, укыттың да ди. Башкалада яхшы эшкә урнашыйм дисәң, 60 мең доллар кирәк. Монысын күтәрә алырсыңмы?» Өйгә кайтып түкмичәчми сөйләдем боларны. Хатын мине узып, кызны МГИМОга барыбер алып китте. Имтиханнар тәмамлангач, әнисен чакырткannар: «Биш мең түләсәгез, сез студент», – дигәннәр. Глүзә башта доллар сораганнарын аңламаган әле... Машина алган гына чагым иде, сатарга була иде, билгеле. Тик нәрсә өчен? Диплом алгач, барыбер Чаллыга кайтып урнашасы булса, нигә кирәк бу кадәр акча түгү? Хатын-кыз кайчак нигәдер аякны юрганга карап кына сузасы икәнен онытa.

**10 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.**

– Җиңелгән очраклар да бар – мин дә әүлия түгел, хаталанам да. Кайчак баш җитми. Чаллыда, шәһәр читендә йорт төзибез шулай. Киров өлкәсеннән бура кайтарттык. Икенче катын нишләтергә белмим генә. Төзүчеләрне туктаттым. Хатын кырыйда нидер эшләп йөри. Мин кычкырып ук уйлый башлаганмын... «Ә нигә брустан төземисең?» – ди бу үтеп барышлый. Бөтен өстенлекләрен санап күрсәтте. Шаккаттым! Ике икең дүрт икәнне ничек үзем белмәгәнмен?! Нәкъ ул әйткәнчә эшләттем.

**11 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.**

– Әйе, андый хәлләр сирәк кенә булгалый. Болай Глүзә гел запас белән пешерә. Әмма мин тәҗрибәле! Тушенка, балык консервасы алып кайтып куям. Казылык алдым әле менә. Төнлә торып, йоклый алмый уйланып утырган чаклар бар. Кайчак капкалап, ашап, чәй эчеп куясы килә. Хатынны уята алмыйсың бит. Ашаудан проблема ясамыйм. Казанга күчеп килгәч, өч елга якын башта берүзем тордым. Гел кеше пешергән өчпочмакны гына ашап яши алмыйсың.

**12 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.**

– Мин хатыннан сорамыйча аңа бизәнү әйберләре алмыйм. Йөзек, алка, муенса... Боларны алырга хакым юк: ул тагасы. Глүзә сайлаганда, мин янында басып торып акчасын түләүче генә. Эзләп табу – аннан, «Әйдә, алабыз, сиңа бүләк булыр», – дию – миннән. Ул да шулай. Кеше арасында йөргәч, өс-башымның пөхтә булуын яратам. Бер шагыйрә: «Өйдә әллә нәрсәм булмады, әмма яхшы киенергә тырыштым. Киемемә карап, гомер буе «син бай» дип әйттеләр», – дигән иде...

Ә чәчәк бүләк итә белмим... Сирәк кенә алсам да, чын күңелдән килеп чыкмый. Матур итеп бирә белмим...

Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru »





**Әле кайчан гына остеопороз фәкать өлкән яшьтәгеләр авыруы гына булып саналды. Әмма тикшеренүләр күрсәткәнчә, сөякләрнең зәгыйфьлеге балалар һәм яшүсмерләргә дә янарга мөмкин. Без бүгенге сәламәтлек сәхифәсен тулысы белән әлеге патологиягә багышларга булдык. Бер чир дә көнендә генә килеп чыкмый, нигездә, ул күпкә алданрак, хәтта балачактан ук башлана. Балаларда остеопорозның барлыкка килү сәбәпләре хакында Республика клиник балалар хастаханәсенең 3 нче «Азино» поликлиникасында травматология-ортопедия бүлеге мөдире, медицина фәннәре кандидаты, Казан дәүләт медицина университетының травматология, ортопедия, хирургия һәм экстремаль хәлләр кафедрасы доценты Гөлнара ФӘЙЗРАХМАНОВА белән сөйләшәбез.**

# БАЛАЛАР ЧИРЕ ТҮГЕЛ ДИСӘК ТӘ...

Велосипедтан яки таганнан егылып төшмәгән, тез башларын, терсәкләрен канатмый калган бала юктыр. Күпчелек очракта бераз сызлап, сыкрап тора да үтеп китә ул. Ә кайбер балалар өчен аз гына бәрелү дә гипс салу белән тәгәлләнә. Сөякләрнең болай тиз сынып китүенә остеопороз сәбәп булырга мөмкин.

Балалык чорында буыннар сызлау, умырткалыктагы авырту-сыкранулар, баланың аяк-кулларын еш сындыруы әти-әниләрне сагайтырга тиеш.

Үсеп килүче организмда сөяк структурасы җенси җитлегү чорына кадәр формалаша. Әлеге чор тәмамланганда гәүдә скелетының күп кенә өлешләрендә сөяк массасы 86 процентны тәшкил итә. Шуның өчен дә әлеге чорда баланың яшәү рәвешенә һәм туклануына аеруча игътибарлы булырга кирәк.

Остеопороз бүген мультифакторлы патология булып санала. Әлеге чирнең килеп чыгуы 75–80 процент генетик факторларга бәйле.

**Балаларда остеопорозның еш очрау сәбәпләре һәм факторлары:**

- организмның сөт ризыкларын кабул итмәве;
- рационда кальцийга бай ризыклар булмау;
- ит ризыкларын күп куллану;
- нерв анорексиясе;
- артык зур физик көчәнеш;
- эчәклекнең ялкынсынуы;
- озак вакытлар глюкокортикоидлар белән дәвалану;
- бәвел кудыргыч препаратлар куллану;
- җенси җитлегүнең тоткарлануы (аеруча кызларда);
- онкологик чирләр булу;
- шикәр диабеты;
- муковисцидоз.

✓ **Кальцийга бай ризыклар:**



- сөт һәм сөт ризыклары;
- соядан әзерләнгән ризыклар;
- балык һәм диңгез продуктлары: майлы сардина, тюлька, хамса;
- сельдерей;
- зәйтүн;
- кәбестәнең барлык төре;
- курагә, йөзем;
- миндаль;
- кунжут, кабак орлыклары;
- дөге.





**Остеопорозны кисәтү:**

- сөякләр нык булсын өчен кальций кирәк. Бигрәк тә балаларның интенсив үсеш чорында. Ә менә аның үзләштерелүе өчен D витамины җитәрлек булырга тиеш. D витамины ул – кояш. Җәйге-язгы айларда тәннең ачык урыннарын 15 минут кына кояшка күрсәтү дә җитә;
- табиб белән киңәшеп, кышкы-көзге чорда D витаминын куллану нәтиҗәле;
- рационда терлек продуктлары һәм үсемлек майлары – А витамины чыганаклары булсын;
- фосфор һәм фосфатларга бай ризыкларны мөмкин кадәр азрак кулланырга тырышыгыз (кызыл ит, ысланган ризыклар, газлы сулар, иттән әзерләнгән фабрикатлар);
- физик активлыкка игътибар итегез. Бала мөмкин кадәр урамда – саф һавада күбрәк уйнасын.



Материал ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



**Әлеге чиргә табиблар әнә шундый атама биргән – «XXI гасырның тын эпидемиясе». Остеопороз – 45–50 яшьтән узган һәр өченче хатын-кызга, ир-атларның яртысына яный. Кешене инвалидлыкка чыгаручы һәм иртә үлемгә китерүче чирләр арасында дүртенче урында торган бу мәкерле авыруның билгеләре һәм аны булдырмый калу юллары турында югары категорияле табиб-ревматолог, Казан дәүләт медицина университетының госпиталь терапиясе кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты Светлана ЛАПШИНА сөйли.**

# ЧОРЫБЫЗНЫҢ ТЫН ЭПИДЕМИЯСЕ

Остеопороз – сөяк тукымасының тыгызлыгы кимү аркасында килеп чыга. Шул сәбәпле, сөякләр нечкәрә, уалучанга әверелә, аз гына бәрелү-сугылудан да сынып китү ихтималы арта.

**Остеопороз аеруча кемгә яный:**

• 65 яшьтән өлкәнрәкләргә (35 яшьтән соң сөякләрдән кальций юыла башлый, аларның ныклыгы кими).

• Бала табу яшеннән чыккан хатын-кызларга (эстроген гормоны организмда кальцийның үзләштерелүенә ярдәм итә. Аның кимүе сөяк массасының да кимүенә китерә).

• Нәселләрендә әлеге чир белән авыручы булганнарга (остеопорозга бирешүчәнлек нәселдән дә килә).

Кызганыч, остеопорозның күзгә күренеп торучы билгеләре юк. Сөякләрнең зәгыйфьлеге күп очракта травмадан соң гына ачыклана.

**Билгеләре:**

• сөякләр сызлый (аеруча умыртканың күкрәк һәм бил өлешендә);
• буй кыскара (4 см һәм аннан да күбрәк);
• гәүдә торышы үзгәрә;
• тырнаклар сынучанга әйләнә;
• чәчләр юкара, коела;
• тешләр зәгыйфьләнә;
• талчыгу барлыкка килә.

Остеопорозның булу-булмавын ачыклау өчен денситометрия кулланыла. Ул башлангыч стадиядә үк сөяк тукымасының тыгызлыгын билгеләргә һәм сынуларны кисәтергә мөмкинлек бирә. 40 яшьтән узучылар сөякләрнең ныклыгын FRAX шкаласы белән дә тикшереп карый ала. Ул интернетта бар.

Сөякләрнең тыгызлыгына бәйле шик туса, терапевтка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ул барлык факторларны барлап, ревматологка яисә, остеопорозга китерүче төп сәбәпнең нинди булуына карап, башка белгечкә юллама бирә.

**Сәбәпләре:**

■ эчке секреция бизләренең дөрес эшләмәве (калкансыман бизнең эшчәнлеге бозылу, диабет, озак вакытлар гормональ препаратлар куллану);
■ бөерләрнең сәламәт булмавы (бөер чирләре сөякләрдән кальцийның юылуына китерә);
■ дөрес тукланмау (катгый диеталар, кальцийга бай ризыкларны аз куллану);
■ Д витамины кытлыгы;
■ аз хәрәкәтләнү (хәрәкәтнең аз булуы кальцийның юылуын тизләтә);
■ гәүдә авырлыгының артыклыгы яки кимлеге;
■ тәмәке һәм алкоголь, газлы суларга хирыслык. Болар организмдагы матдәләр алмашын боза, кальцийны үзләштерүгә комачаулый.



**Дәвалау:**

■ җитәрлек күләмдә кальций (тәүлегенә 500–1000 мг) һәм D витамины (тәүлегенә 800 МЕ) кулланырга;
■ сөякләрнең тыгызлыгын арттыручы препаратлар эчәргә;
■ физик күнегүләрне даими ясарга.

Спорт һәркемгә кирәк. Әмма 65 яшьтән өлкәнрәкләргә ул аеруча мөһим. Физик күнегүләрне даими үтәү сыгылмалылыкны арттыра, тигезлекне сакларга ярдәм итә.

Физик күнегүләр, бию, йөзү, аэробика, йөгерү кебек, төрле группа мускулларын эшкә җигә торган булсын. Шулай ук тигезлекне саклауга юнәлтелгән күнегүләрне дә даими ясарга кирәк. Әмма физик күнегүләрне табиб белән киңәшеп кенә ясау зарур.



Материал Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат хезмәте җитәкчесе Әлфия Хәсәнова ярдәме белән әзерләнде.





# Вакыт ашыктырамы, әллә...



**Чәчләргә чал төшү яшәгән еллар артта күбрәк калу, инде өлкәнәя баруны аңлата дисәк... Кемнеңдер 30–35 яшьтә үк ак чәчләре күзгә чалына башлавын һәм аларның торган саен арта, күбәя баруын нәрсә белән бәйләргә соң алайса? Чәчләрнең матурлыгын, төсен озаграк ничек сакларга? Бу, гомумән, мөмкинме? Толымында беренче ак юллар күреп, моны фаҗига итеп кабул иткән хатын-кызларны өметләндереп нәрсә әйтеп була? «Resedaodor» молекуляр косметика компаниясенең генераль директоры Резеда НУРИСЛАМОВА шул хакта сөйли.**

Әйе, чәч агару – шактый җитди проблема ул. Моны өйрәнү белән дөньяда бик зур корпорацияләр шөгыльләнә. Рәсми рәвештә игълан иткән мәгълүматлар буенча, 2011 елдан башлап Lucas Meyer компаниясе һәм тагын биш корпорация бу тикшеренүләр өчен 800 мең евро тоткан. Алар беренче чиратта чәч агаруның нәрсә икәнен, нигә аның барлыкка килүен ачыкларга тырышты. Моңарчы бу күренеш яшь белән бәйле булган үзгәрешләрнең берсе дип кенә санала иде. Еллар буе алып барган тикшеренүләр менә нәрсә күрсәтте: чәч агаруга ике фактор тәэсир итә.

- Беренчесе аның, чыннан да, организмның өлкәнәюе белән бәйле. Чәчнең төсе өчен меланин җаваплы: шул пигмент чәчләргә тула һәм чәч «күтәрелә». Яшь барган саен исә күп процесслар акрыная, меланин да азрак эшләнеп чыгарыла башлый: чәч «бушый» – үтә күренмәлегә әйләнә.
- Икенче зур сәбәп – оксидатив стресс. (Моңа әйләнә-тирә мохитнең пычрануы, зыянлы эш шартлары, тәмәке тарту, эчү кебек начар гадәтләр, генетика, чәчне дөрес тәрбияләмәү, озакка сузылган депрессия, стресслар һәм башкалар керә.) Чәч тамыры тирәли водород пероксиды туплана, чәчнең төсен шул ала. Кешенең чәче кинәт чаларган чакларда шушы механизм хәрәкәткә килгән була. Әкрен генә барган физиологик процесстан үзгә ул. Аны кеше кичергән бик көчле стресс китереп чыгара, андый вакытта: «Төн эчендә чәчем агарды», – диләр.

Бу ике механизмны ачыклагач, аларга тәэсир итүче пептид эшләргә тотындылар. Greyverse молекуласы шулай барлыкка килде. Соңгы өч-дүрт елда Франциядә бик күп клиник тикшеренүләр үткәрелде. Соңгы тикшеренүләрнең фотолары да килде. Анда йөзгә якын кеше катнашкан, һәм аларның барысы да нәтиҗәләрне үз күзләре белән күрүләрен әйтәләр. Безнең компания Greyverse молекуласын актив молекула буларак куллана. Ул оксидатив стрессны баса: чәчне чаларудан саклый. Әлеге молекула организмда меланин эшләп чыгаруны арттыра: пигмент тизрәк бүленеп чыга һәм чәчне тизрәк тулыландыра.

Меланин инде күптән эшләнмәгән очракта да бу молекула булышачак дип әйтү авыррак, әлбәттә. Әгәр кешенең әле 20 процент чәче булса да үз төсен саклаган икән, нәтиҗә күренәчәк. Тик без тәкъдим иткән «Аргентум» спрее бер көн куллануга чәчне кире үз төсенә кайтарыр дип көтәргә кирәкми. Бу – чәч буявы түгел, нәтиҗәне күрер өчен вакыт кирәк.

Спрейның иң зур өстенлеге – аңарда «синдром отмена» юк: күп продуктларны кулланудан туктауга, бар да элеккеге хәленә кайта. Ә монда алай түгел – нәтиҗәләр сакланачак. Ким дигәндә – ярты ел. Әмма барысы да кешенең организмында матдәләр алмашынуы ничек торуга бәйләнгән.

Greyverse (Грейверс) молекуласын Европада берничә компания чыгара башлады, Россиядә исә – без беренче. Бу молекула белән иң элек... ир-атлар кызыксынды. Яшь кенә ир-егетләр: «Инде өч-дүрт ел чәчемне буяп йөрим, арыдым», – дип киләләр. Әйе, чәчне буяу мәшәкатьле дә, зыянлы да шул.

Чәч буяу дигәннән. Ел башында Төрекмәнстанда кызык кына хәл булды: кинәт анда барлык җитәкче ир-атлар чаларды. Сәбәбе дә билгеле: моңарчы Илбашлары чәчен буяп йөргән икән. Бу аны ялыктырган, күрәсең. Быел кинәт кенә үзе дә буямый башлаган, кул астында эшләүчеләрне дә буяудан тыйган.


ПРОФЕССИОНАЛЬНАЯ МОЛЕКУЛЯРНАЯ КОСМЕТИКА




* гипоаллергенная
*без содержания:
- парабенов
- минеральных масел
- силиконов и других
- агрессивных компонентов

Россия, РТ, г. Казань,
ул. Калинина, 48, 318 офис
+7 (987) 232 08 88;
г. Н. Челны, проспект Мусы Джалиля, 51-111;
г. Ижевск, Северный переулок, 61 в;
г. Сочи, ул. Виноградная, 139;
г. Екатеринбург, ул. 8 Марта, 149



info@resedaodor.com resedaodor.com @resedaodor

РЕКЛАМА




# Балдан тамган нәфислек

**Казанның Иске татар бистәсендә үзенчәлекле «ShikӘR» салоны бар. Анда килеп керүгә үзеннән-үзе татар мохитенә чумасың.**




– Исеме татарча булгач, җисеме дә татарча булсын дип теләдек. Матурлык үзәге булгач, әлбәттә инде, безгә ханымнар, яшь кызлар килә, аларны милләтебезнең киләчәген тәрбияләүчеләр дип кабул итәбез. Алар бирегә килгәч, төрле процедуралар үткән арада татарча журналлар, китаплар укый, үзебезчә җырлар тыңлап утыра. Татар теленең көнкүрештәге кулланылышына да игътибар итәләр. Аларга әнә шундый җылы атмосфера тудырып, «ShikӘR»дән чыгып киткәч тә татарча аралашу теләкләре калсын иде дип телибез, – ди әлеге үзәкнең җитәкчесе **Зөлфирә ВАФИНА**.

Үзәкнең бер юнәлеше – шикәрле эпиляция (шугаринг). Шугарингның хатын-кыз тәненә ничек тәэсир итүе турында бу хезмәтне күрсәтүче тәҗрибәле осталар **Эльвина КОРБАНОВА** һәм **Марина ГАЛИМҖАНОВА** сөйли.




Шугаринг элек-электән хатын-кыз матурлыгына аерым игътибар бирә торган көнчыгыш илләрендә барлыкка килгән дип санала. Тәнне төкләрдән чистарту өчен Нефертити бу ысулны үзе кулланган, диләр. Шикәрле эпиляциянең ничә гасыр үткәч тә популярлыгын югалтмавының сере: зарарлы матдәләр кулланмый гына, тән өслеген нәфисләндерү. Ә тәннең тәрбияләнгән, нәфис һәм матур булуы – хатын-кызның яхшы кәефе өчен иң югары күрсәткеч ул. Бүгенге заман хатын-кызлары да бик теләп шугарингны сайлый, чөнки:

- бу процедураның гормональ системага, гомумән, хатын-кыз сәламәтлегенә зыяны юк;
- башка төр эпиляцияләр белән чагыштырганда, арзанлы һәм тәнне төкләрдән арындыруның шактый нәтиҗәле юлы;
- шугаринг ясаганда тән үле күзәнәкләрдән арына, чистарынып кала, үзенә күрә СПА процедурасы уза;
- шикәрле эпиляцияне гадәттә аякларга, беләкләргә, култык асларына, бикинига ясыйлар (процессның нәтиҗәсе өч-дүрт атнага кадәр җитә);
- калкансыман бизгә операция ясаткан хатын-кызларга лазерлы эпиляция ысулын кулланырга ярамый, шуңа да алар шугарингны сайлый.




Шугаринг ясатырга ярамый торган очраклар:

✓ шикәр авыруы; ✓ көчле варикоз; ✓ йөклелекнең беренче триместры.

Шуны да белеп торырга кирәк: шугаринг ясатыр алдыннан тәндәге төк озынлыгы 4-7 мм булсын. Процедурага барасы көнне тәнгә төрле кремнар, майлар сөртмәскә киңәш ителә. Шугаринг ясаткан көнне гель, сабын белән юынмау хәерле. Шулай ук өч көн дәвамында кызынмаска, солярийга бармаска киңәш ителә.

Озак еллар дәвамында сыналган, күпләр өчен килешә торган шугарингны сезгә дә тәкъдим итәбез, кадерле хатын-кызлар!

РЕКЛАМА

*Матурлык һәм сәламәтлек студиясе*

ShikәR

ШУГАРИНГ

Маникюр Массаж

Маникюр • Шугаринг • Массаж

ShikәR

239-13-55

ул. Тукая, 58

@Shikar.epil

@Shikar.nail

# Тутырылган карп балыгы

**Илнур ЗАКИРОВ – Г. Камал театры артисты. Сәхнәдә генә түгел, балык тоту буенча да талант иясе! «Балыкка йөрергә әтидән өйрәнеп калган идем. Әле малай чакта көтү көткән вакытларда елгадан балык тотып, учакта кыздырып ашый идек. Тормыш иптәшем Динәнең (скрипкачы Динә Закирова) әтисе дә оста балыкчы булып чыкты. Хатыным ягына Мөслимгә кайткач, бабай белән балыкка – эшкә йөргән кебек йөрибез кайчак. Үзебез тоткан балыкны төрлечә әзерлибез: шашлык та ясыйбыз, кыздырабыз, киптерәбез, каклыйбыз, фольгага төреп пешерәбез... Балыкны бакчада – учак ягып әзерләү күңелле. Тырышканда өй шартларында да тел йотарлык итеп пешереп була», – ди Илнур. Ә безгә ул үзенчәлекле итеп карп балыгы белән бәрәңге әзерләп күрсәтте. Хатын-кызлар бәйрәменә табын әзерләгәндә ир-егетләр нәкъ менә шушы рецептны кулланып, сөйгәннәрен шатландыра ала.**





***Кирәк***

- карп балыгы;
- 1 помидор;
- 1 лимон;
- аджика;
- ярты стакан натураль йогурт;
- яшел тәмләткечләр: укроп, петрушка;
- уртача зурлыктагы 6-7 бәрәңге (4 кешегә исәпләп);
- 1 аш кашыгы «кипкән сарымсак» тәмләткече;
- 2 аш кашыгы кукуруз ярмасы;
- бәрәңге өчен махсус тәмләткеч;
- суган;
- тоз һәм борыч;
- 5 аш кашыгы рафинадланган зәйтүн мае (көнбагыш мае да ярый).

***Эш барышы***

■ Балыкны чистартабыз. Эчен алыр өчен корсак турысыннан берәр сантиметр өстәнрәк ярабыз. Болай иткәндә балык үз шулпасы белән пешә, мае кырыйга агып чыкмый. Чистартканнан соң, балыкка тоз тидереп куябыз.

■ Балыкның эченә түгәрәкләп киселгән помидор кисәкләре, күп итеп яшел тәмләткеч һәм 3 телем лимон кыстырабыз.

■ Йогуртка аджика, тәменчә тоз, борыч кушып, болгатабыз һәм шуны ике яклап балыкка сөртәбез. Ул шул килеш 15–20 минут торырга тиеш.

■ Шул арада бәрәңгене әзерли торыйк. Бәрәңгене әрчеп, сигез өлешкә бүләбез.

■ Бәрәңге өстенә кукуруз ярмасы, 4–5 кашык зәйтүн мае, «кипкән сарымсак», бәрәңге өчен махсус тәмләткеч, тәменчә тоз, борыч салабыз да барысын бергә болгатабыз. М-м-м... Бу вакытта аш бүлмәсенә нинди хуш ис таралганны белсәгез икән!

■ Суганны чистартып, алкалап кисәбез.

■ Противеньга пергамент кәгазе җәябез һәм балык ятасы урынга алкалап туралган суганны тезәбез. Балыкның противеньга тигән өлеше көймәсен өчен шулай эшләнә. Суган өстенә балыкны куябыз.

■ Балык янына бәрәңгеләрне тезәбез.

■ Духовкада 40–45 минут пешерәбез.

■ Табынга балык белән бәрәңгене аерым савытларга салып чыгарабыз. Балыкны салат яфрагы, черри помидоры, лимон белән бизәргә була.

Бәйрәм табыннары түгәрәк, ашларыгыз тәмле булсын!













Фото: Анна Арахамия

PRESSA



Хатын-кызлар бәйрәме якынлаша. Тәмле торт белән дә сыйланмагач, ул нинди бәйрәм инде?! Менә без дә традициядән тайпылмыйбыз, һәм бәйрәм хөрмәтенә торт пешерербез. Ә Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА аны безгә кишердән әзерләргә тәкъдим итә.



# «Дөрес» торт

**Кирәк:**
- 2 кишер;
- 1 банан (мәҗбүри түгел);
- 1 әфлисун;
- 150 г чистартылмаган бөртектән тарттырылган он;
- 50 г солы көрпәсе;
- 100 г кефир;
- 3 йомырка;
- ярты чәй кашыгы чәй содасы;
- тәменчә дарчин һәм мөшкәт чикләвеге;
- шикәр алыштыргыч (заменитель сахара).

**Крем өчен:**
- эремчек һәм шикәр алыштыргыч.

**Эш барышы:**

■ Кишерне һәм әфлисун кабыгын угычтан уабыз. Шуңа кефир, әфлисун суты, чәй содасы, көрпә, он, шикәр алыштыргычны кушабыз, барысын да яхшылап туглыйбыз. Йомырканың сарысын өстибез. Ә йомырка агын исә кашыктан төшмәслек булганчы күпертәбез һәм сак кына камырга кушып, болгатабыз. Баллырак яратучылар бер банан өсти ала.

■ Коржларны 180 градус кызулыктагы мичтә 40 минут чамасы пешерәбез. Таба кечерәк булган саен, торт биегрәк була. Коржларны аерым-аерым пешерергә дә, берьюлы берне пешереп, 2-3 өлешкә бүләргә дә мөмкин.

■ Крем өчен йомшак эремчек белән шикәр алыштыргычны туглап, корж араларына һәм тортның кырыйларына ягабыз. Тортны төнгә яисә 5-6 сәгатькә суыткычка куеп торабыз.

**Шикәр алыштыргычлар ясалма һәм табигый төрләргә бүленә.**

■ Табигыйләреннән фруктоза, сорбит, эритрит, стевияне атарга була.

**Фруктоза** – табигый углевод. Җиләк-җимеш, яшелчәләр составында бар. Шикәргә караганда, якынча 1,5 тапкырга баллырак. Тәүлеклек куллану нормасы – 30–45 г. Артыгы исә йөрәк-кан тамырлары чирләренә китерергә мөмкин.

**Сорбит** – углевод саналмый. Аның үзләштерелүе өчен инсулин кирәк түгел. Баллылыгы шикәрдән ике тапкырга ким. Тәүлеклек нормасы – 15–40 г.

**Эритрит** – кандагы шикәр күләмен арттырмый, тешләргә начар тәэсир итми калмый, калориясе бөтенләй дә юк. Баллылыгы шикәрнең 70 процентына бәрабәр.

**Стевия** – бүген иң популяр табигый шикәр алыштыргыч. Шикәр белән чагыштырганда, баллылыгы 200 тапкырга артык, ә калориясе бөтенләй дә юк.

■ Ясалма шикәр алыштыргычлар – сукралоза, аспартам, натрий цикламаты, калий ацесульфамы. Болар барысы да диярлек җылытканда, эндокрин системага зарар китерергә мөмкин булган матдәләргә таркала. Ә натрий цикламаты организмда бөтенләй үзләштерелми. Әлеге матдә Америкада инде 1969 елдан тыелган.

■ Өйдә тәм-том әзерләгәндә табигый шикәр алыштыргычларны сайларга тырышырга кирәк. Шикәр урынына топинамбур яки финик ширбәте, бал кулланырга мөмкин.

***Кучкар.*** Ай башы бераз киеренке булыр. Соңрак бар да уңай якка үзгәрер. Туганнарыгыз белән көтмәгәндә мөнәсәбәтләр катлауланса, борчылмагыз, тиз арада бар да җайланыр. Вакытны һәм вакыйгаларны ашыктырмагыз.

***Үгезбозау.*** Әлегә кадәр тынгылык бирмәгән сорауларга җавап табылыр. Шуңа күрә катлаулы булып тоелган бурычларны ай башында үтәсәгез, күңелегез тынычланып калыр. Акча белән сак эш итегез.

***Игезәкләр.*** Танышларыгызның гадәти булмаган тәкъдимнәре сездә кызыксыну уятыр. Аларга карап үзегездә көч табарсыз. Яллардагы сюрпризлар гаҗәпкә калдырыр, әзер булыгыз!

***Кысла.*** Суынган хисләр кабат яңарыр. Тормышның иң матур бизәге – мәхәббәт икәнен аңларсыз. Романтика өчен акчагызны кызганмагыз. Яраткан кешегезгә, ачылып, хисләрегез турында сөйләгез.

***Арыслан.*** Яшеренеп, талантыгыз ачылыр һәм ул сезгә ел әйләнәсе өстәмә керем алырга ярдәм итәр. Бу айда мәхәббәт хисләрен, гаилә мөнәсәбәтләрен ныгытуга көчегезне кызганмагыз.

***Сөмбелә.*** Финанс һәм дуслык өлкәсендә үзгәрешләр башланыр. Берничә ел элек җибәргән ялгышыгызны искә төшерсәләр, үпкәләр белдерми генә төзәтергә тырышыгыз. Сезгә ачулы дусларыгызның күңеленә тынычлык килер.

***Үлчәү.*** Йолдызлар яңалыклар вәгъдә итә. Алар тормышыгызга нәкъ кирәк вакытта килер һәм дөньяга карашыгызны үзгәртер. Алдыгызга башка максатлар куеп, яңа юллар ачылыр. Җанга рәхәтлек бирүче хисләргә төренерсез.

***Чаян.*** Барысы да үз тәртибе белән барганны яратсагыз да, язмыш көтелмәгән вакыйгалар әзерли. Әлегә кадәр сезнең яклы булган кешеләрнең тәнкыйтенә юлыгуыгыз бар. Кәефегез төшмәсен, алар үз хаталарын тиз аңлар.

***Укчы.*** Март аена куйган максатларыгызга ирешү өчен катлаулы юллар узарга туры килер. Гаиләгезгә карата яхшы мөнәсәбәттә булыгыз, аларга вакытыгызны кызганмагыз. Эшлекле мөнәсәбәтләрнең романтик төсмер алуы ихтимал.

***Кәҗәмөгез.*** Бик күп эшләргә туры килер. Берьюлы бөтен нәрсәне колачларга тырышмагыз, уңышка илтә торган юлларны ябарга мөмкин. Китаплар уку, кино карау кебек үзегезгә рәхәт ял оештырырга да тырышыгыз.

***Сукояр.*** Тормышыгызны тамырдан үзгәртергә тотыначаксыз. Уңышсызлыкларга очрап, төшенкелеккә бирелмәгез. Чөнки алда сезне сөекле кешегез белән бергә маҗараларга бай романтик сәяхәт көтә.

***Балык.*** Вакытны тигез бүлергә өйрәнегез. Сәламәтлек һәм ял итү өчен дә җай таба белергә кирәк. Табигатькә чыгыгыз, балалар, туганнар белән аралашу сезне ныгытыр, күңелегезгә җылылык бирер.



# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

**Без журналыбызны сезнең өчен чыгарабыз, аның сезгә ошавын, кирәкле, файдалы булуын телибез. Ахирәт, якын дус, киңәшче, сердәшче булуын! Тәкъдим иткән бу сорауларга биргән җавапларыгыз безнең араларны тагын да якынайтыр дип өметләнәбез.**

Сезгә ничә яшь? ______

«Сөембикә»не ничә ел алдырасыз? ______

Сездән кала, журналны тагын кемнәр укый?

______

«Сөембикә» журналы рубрикалары рейтингы булдырылса, беренче өчлеккә кайсыларын кертер идегез?

______

Замана хатын-кызларын борчыган темаларның кайсылары журналда ачылмый кала дип санийсыз?

______

Журнал тышлыгында сез күрергә теләгән хатын-кызлар бармы?

______

Журналны кулга алгач, аны, гадәттә, кайсы сәхифәдән укый башлыйсыз?

______

«Без һәм алар» сәхифәсендә тагын кемнәрне күрәсегез килә?

______

Кайсы рубрикаларны үзгәртергә вакыт җитте дип санийсыз?

______

«Сөембикә» журналын кемгәдер бүләк итә алыр идегезме? Туган көнгә, юбилейга, 8 Мартка?

______

Якын-тирәгездә «Сөембикә» герое булырлык хатын-кызлар бар дип санийсызмы? Булса, кемнәр?

______

Сез безнең сайт белән танышмы? ______



анкета

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Раилә ХӘЯЛИЕВА әзерләде.









# ФИРҮЗӘ БАТИКЛАРЫ

Кояш якты һәм җылы гына булып калмыйча, кайчак рәхимсез дә була белә шул... Көйдереп алырдай эссегә кешеләр генә түгел, агачлар да түзалмый башлый. Үз гомерендә күп тапкырлар климат алышынуларны кичергән зур карт агач та сумала тамчылары белән елый хәтта. Һәм тикмәгә түгел бу.

Бер төргәк тукыма өстерәп барган егет нәкъ менә шушы агач күләгәсенә ял итәргә утыра. Әмма озаклап утырырга туры килми. Тукымага тамган сумала тамчыларын шәйләп, егет тәмам хафага төшә. Сикереп торып, төргәкне читкәрәк куя, бозылган товар өчен хуҗадан эләгер дип коты чыга. Ләкин бу хәл турында сөйләп бирергә батырчылык итми... Зур мичкәдән тукыманы чыгарганда буяучылар хәйран кала: тигез буяу төшәсе урында матур булып йолдызлар чәчелгән! Спираль буенча сибелеп, күз явын алып җемелдиләр. Көн саен һаман бертөрле тукыма күреп күнеккән осталар бу көтелмәгән күренештән җанланып китә. Акыллы башлар киңәшмәгә җыелгач, тукыма алып кайткан егетне искә төшерәләр, чакырып алалар. Ни куркырга, ни сөенергә белмәгән егет барысын да сөйләп бирә. Ә зирәк акыл ияләре, спираль ул – җил эше дигән фикергә килә. Батик турында менә шундый риваять.

Фирүзә Алиева үзенең кабатланмас иҗаты белән тамашачыга сәнгатьнең бу төре никадәр сыгылмалы булуын күрсәтә алган. Фирүзә эшләренең үз теле, үз стиле бар, аларда тукымага бизәк төшерүнең чикләнмәгән потенциалын тоеп була.

Ташкентта яшәүче милләттәшебез картиналарында табигый мотивлар һәм декоративлык бербөтен хасил итеп, тамашачыны үзенә тартып тора. Милли орнамент, колористика – барысы да батикка барып тоташа. Фирүзә Алиева Беньков исемендәге сәнгать училищесында костюм рәссамнары әзерләү бүлеген тәмамлый. Шуңа да киндердә картина язучы рәссамнар киңлеге аңа кысан тоела. Ул үзенең рәссам талантын күндә дә, ефәктә дә куллана. Киемнәргә бизәкләр төшергәндә, ефәккә рәсемнәр ясаганда кабатланмас образлар тудыра. Фирүзә күпсанлы күргәзмәләрдә һәм арт-лабораторияләрдә катнаша. Үзбәкфильм студиясендә костюмнар буенча художник булып эшли. Аның костюм эскизлары буенча Шәүкәт Джунайдуллаевның «Чархпалак» һәм режиссер Рөстәм Сәгъдиевнең «Мәхәббәт сыйныфлары» фильмнары төшерелә. Фирүзә Алиева 2014 елдан Үзбәкстан Рәссамнар академиясе әгъзасы. Эшләре Германия, Төркия, Италия, Корея, Америка, Швейцария һәм башка илләр галереяларында саклана.

Нечкә колористик эффект һәм катлаулы фактура кулланып ефәккә бизәк төшерү техникасы экспериментларга юл ача. Эксклюзив чапаннар, бизәк төшерелгән күн әйберләр, агач токталы, сырлап ясалган милли бизәкле кабатланмас сумкалар иҗат итә ул. Кайбер эшләре үтә күренмәле, буяулары тыйнак тоелса да, аларда төсләр һәм сюжет бер гармониядә.

«Анар чәчәк атканда» дип аталган беренче зур күргәзмәсе 2017 елда Мәскәүдә уза. Тәнкыйтьчеләр һәм сәнгать белгечләре Фирүзә эшләренә аерым игътибар күрсәтә. Ефәккә бизәкләр төшерү стилендә ясалган картиналары Мәскәүнең сәнгать сөючеләре күңеленә аеруча хуш килә.

Бүгенге көндә Фирүзә Татарстанга багышланган коллекцияне эшләү белән мәшгуль. ТАССРның 100 еллык юбилее рәссамны «Минем тамырлар» коллекциясен иҗат итәргә этәргән. Киңкырлы авторның яңа эшләрен түземсезлек белән көтәбез.

Рәмзия КАШАПОВА










ФИРҮЗӘ АЛИЕВА

ТАССР

Празднование 100-летия
Татарской АССР

Татарстан АССР төзелүнең
100 еллыгын бәйрәм итү

1920-2020



Михаил АФАНАСЬЕВ,
Татарстан Республикасы
Яшел Үзән муниципаль
районы башлыгы

Татарстанның төньяк-көнбатышында, Иделнең сулъяк ярында урнашкан Яшел Үзәннән сәлам юллыйм сезгә! Рус, татар, чуаш, мари халкы бер гаилә булып яши бездә. Һәм һәркайсы туган Татарстаныбызның 100 еллык юбилеен лаеклы каршыларга әзерләнә. Яшел Үзән – Татарстанның Чуаш һәм Мари Республикаларының капкасы ул. Татарстан Республикасының куәтле икътисадый потенциалы. Суднолар төзү заводы, машина төзелеше, химия лабораторияләре өчен савыт-саба җитештерү, агач эшкәртү заводлары... Аларның продукциясе дөньяның күп илләренә экспортлана.

Кирәк булса, дөнья картасыннан
Кырык илне эзләп табармын.
Мин яшәгән Татарстан менә,
Күр, кайларга илтә товарын... – дип, шагыйрь Сибгат Хәким әйтерсең безнең турыда язган!

ТАССРның 100 еллык бәйрәменә бик күп кунаклар килер республикабызга. Без аларны Яшел Үзәндә дә көтәбез. Районыбызда урнашкан Зөя утрау-шәһәрчеге, Раифа монастыре, Идел-Кама дәүләт табигый тыюлыгы... Болар барысы да данлы Татарстаныбызның табигатенә, тарихына, архитектурасына уникаль һәйкәл!

